ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№7 (319) – ИЮЛЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

«Ярдәм» фонды: кояш нуры сүнгәндә

20 нче еллар: республика туганда

Дөньяга «Зөләйха» күзләре белән карасак...

– УКУЧЫЛАРЫМ БЕЛӘН ЗАМАНЧА АРАЛАШАМ

4 612750 670011

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Гадел Хәеров, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыктагы фото: шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе
Роберт Миңнуллин. Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 данә,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-1846
Басарга кул куелды: 25.07.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры: Гүзәл Подольская
Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Сату бүлеге белгече: Ренат Ихсанов
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

БӨЕК ЭШЛӘР ЭШЛӘНГӘНДӘ

«Татарстан» журналының бу номерында вакыт аралыгы буенча 100 ел аерып торган ике тема кисеште. Һәм бу очраклы да түгелдер, мөгаен. Соңгы көннәрнең иң яңа, иң киң колачлы вакыйгасы – 2018 елның Футбол буенча дөнья чемпионаты һәм узган гасырның 20 нче елларындагы масштаблы вакыйгалар турында сөйләүче проект. Әлбәттә, ике гасырның ике чигендә торган әлеге вакыйгаларны чагыштырып булмый. Берсе инде күптән тарихка әверелгән һәм үз эченә әллә ниләрне сыйдырган: Гражданнар сугышы, коллективлаштыру, электрлаштыру, НЭП... Тулаем алганда, ТАССР дип аталган яшь республиканың беренче адымнарын. Ә бу гасырның әле яңарак кына көн кадагында булган вакыйгасы – ул бәйрәм, тантана, горурлык билгесе, фейерверк хәтта. Әмма бүгенге көннең шушы тантанасы булсын өчен республиканың һәм илебезнең моңа кадәрге героик тарихы булу зарур иде.

Һәммәбез дә беләбез: Татарстан яңа гына бөтен илләрдән кунаклар кабул итте. Бөтен дөнья Россия һәм Татарстан кунакчыллыгына таң калды, сокланды. Россия бу мундиальдә үзенең дәрәҗәсен, колачын һәм сыйфатын күрсәтте. Ә кайчан да булса башкача булганы бармы әллә?! Тарихтан беләбез: кыенлыклар да, чикләрне җимерүе дә булган, бик авыр көннәрне, айларны, елларны кичәргә дә туры килгән. Әмма бу юл, ничек кенә сикәлтәле булмасын, дөрес булган. Юкса безгә бүген килгән һәркем соклануын яшерә алмый кайтып китәр идемени?! Без бит һаман да беркемгә дә охшамаган һәм берәүне дә кабатламый торган булып кала бирәбез.

Бөекләр фикерен кабатлап, күпләр өчен остаз, укытучы булган Ошо гыйбарәсенә тукталыйк әле: «Тирәюнеңдәге тормышны матур һәм ямьле ит. Һәм юлыңда очраган һәр кеше сине очратуның зур бәхет икәнлеген аңласын».

Алар моны аңлап кайтып киттеләр. Бәхетне тоеп.

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзүм Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **900 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Иллюстрация: Александр Виноградов, Владимир Дубосарский «Земля – Чемпион!» 2004 ел.

ИЮЛЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Чулман ярындагы кала өчен – $38 миллион.
Ул аның формасын һәм эчтәлеген ничек үзгәртер

8. Инсульттан соңгы тормыш.
Табиблар авыруларны үлемнән ничек йолып кала

12. «Ярдәм» фонды.
Кояш нуры сүнгәндә нишләргә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18. Туп артыннан килүчеләр.
Аларга мундиаль нәрсә бирде

24. Редакция кухнясы.
Кура җиләгеннән пирог

28. Федераль Сабантуй.
Чуваш җирендә татар бәйрәме

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

38. Республика туганда.
Йөз елга якын элек

42. Яңа икътисадый сәясәт еллары.
Соңгы талпыныш

46. Тәмугка тиң ике ел.
Миллионлаган корбан китергән афәт

50. Шәкүр карак маҗаралары.
«Татар чегәне» атлар белән уртак телне ничек тапкан

56. Милли театр.
Ренессанстан – репрессияләргә

60. «Зөләйха» Татарстанга кайта.
Ни өчен Чулманны Ангарага әйләндерәләр

64. Роберт Миңнуллин:
«Мине халык яратты...»

68. Тарихи сәхифәләр.
Алтын Урда ханнары

84. Авылларыбыз.
Баржыны сыендырган Кичкетаң

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

07.07

Джанни Инфантино, ФИФА президенты, – Казанда, мэриядәге киңәшмәдә:

– Сез дөньядагы иң бай тарихлы һәм гүзәл мәдәниятле шәһәрләренең берсендә яшисез һәм эшлисез. Борынгы бабаларыгызга бәһасез мәдәни мирас калдырганнары өчен рәхмәт һәм бу мирасны саклавыгыз өчен сезгә рәхмәт. Бу Россия өчен генә яхшы үрнәк түгел, ә бөтен дөнья өчен Россия үрнәге дә. Без нәрсә эшләргә һәм ничек яшәргә тиеш икәнлекнең күрсәткече! Шәһәр кешеләре, футбол һәм дөнья хакына эшләгәннәрегезнең барысы өчен дә рәхмәт!

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

07.07

Дидье Рейндерс, Бельгиянең тышкы эшләр министры, – Бельгия җыелма командасы җиңгәннән соң, «Казан Арена»да:

– Мин чын-чынлап шаккаттым! Казан – бик матур шәһәр. Бу – бик яхшы инфраструктуралы урын, һәм сүз спорт объектлары турында гына бармый. Без уенны нәкъ менә Казанда отуыбызга бик шат, чөнки бу шәһәр үзенең спорт буенча активлыгы белән билгеле. Һәм мин Бельгия җыелмасы өчен җан аткан күп татарстанлыларны күрдем.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

05.07

Томер Савойя, Бразилиянең иң күренекле җанатары, – Татарстан журналистларына биргән интервьюсында:

– Сезнең командагыз откан чакта мин русларның моны ничек кабул итүләрен күрдем. Әйе, сез ышанмаган идегез. Сез: «Бу – гаҗәеп!» – дидегез, әмма дәртләнеп сөендегез. Бу зур бәйрәм булды! Шуңа күрә мин сезне яратам. Шуңа күрә дә Россия – искиткеч!

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Искелеккә **НИЧЕК** яңа кыса ясарга

Табиблар авыруларны үлемнән **НИЧЕК** йолып кала

Кояш нуры сүнгәндә **НИШЛӘРГӘ**

Казан урамын яңарту проекты, Алабуга шәһәре.

ҮЗГӘРЕРГӘ ВАКЫТ

Казан яхшырганда, матурланганда, Татарстанның башка шәһәрләре дә аннан калышмаска тырыша. Кайберләре менә-менә яңа төс-кыяфәткә генә түгел, ә яңа эчтәлеккә дә ия булачак.

Автор:
Ксения Сёмина

ҮЗӘК МӘЙДАН

Быел Алабуга Кече шәһәрләрне үстерү фонды уздырган федераль конкурста җиңү яулады: үзәк мәйданны торгызу, җанландыру буенча эшләнгән проектлары «Тарихи бистәләр» номинациясендә иң яхшысы дип танылды. Әлеге проектны тормышка ашырыр өчен шәһәргә 50 млн сум бүлеп биреләчәк. Ләкин җиңүгә юл бик сикәлтәле булып чыга...

Җирле халык Алабуганың төп мәйданы нинди исем йөртергә тиешлеге турында инде берничә ел бәхәс куерта. Кайберәүләр совет заманындагыча Ленин исеме калсын, дигән карашта тора. Каршы як исә революциягә кадәр бу урынның «Хлебная» мәйданы дип аталуын искә төшерә. Әйтергә кирәк, шул чордан бирле сакланып калган, туристларны җәлеп иткән барлык архитектура корылмалары да шул исем белән аваздаш. Мәскәүнең «Оркестр» архитектура бюросы вәкилләренең алабугалыларны да чакырып оештырган проект семинарларында, ниһаять, ике арада килешүгә ирешәләр. Мәйданга «Хлебная» исеме кайтарыла, ә андагы төзекләндерелгән сквер Ленин исемен йөртәчәк, дип тәгаенләнә...

– Мәскәүдәге проектлау осталарының тәкъдимнәребезне исәпкә алуы безнең өчен бик күңелле. Әгәр алар тормышка ашса, без чын мәгънәсендә шәһәребезнең йөзен үзгәртүдә үз ролебезне башкардык, дип горурлана алачакбыз. Архитекторлар алдында шактый катлаулы бурыч тора. Бер яктан, бөтен мәйданның функциональлеген тәэмин итү сорала, чөнки бу урын – каладагы төрле эш-хәрәкәтләрнең кисешү ноктасы, – дип аңлата шәһәр тарихы музее мөдире Екатерина Кашапова. – Монда балалар белән дә йөриләр, туристлар автобуслары да еш килә. Шул ук вакытта ул – көн саен бик күп кеше узып китә торган транзит зона да. Бу мәйдан, асылда, шәһәрнең йөзе. Кала белән танышу шуннан башлана. Һәм ул тарихи сәхифәләребезнең барысын да бер-берсе белән ярашлы рәвештә берләштерергә тиеш. Беренчедән, Алабуганың сәүдә үзәге булган революциягә кадәрге чорын. Бу мәйданнан башланып киткән урамда миллионер сәүдәгәрләр яшәгән. Икенчедән, революция һәм Гражданнар сугышы елларын. Һәм, ниһаять, бүгенге чорны да. Ел саен 300 мең туристны җәлеп иткән музей-тыюлык хезмәткәрләре буларак, әлеге мәйданның тарихи кыйммәтен саклау безгә аеруча мөһим. Миңа калса, проектлаучылар барысына да ирешкән кебек.

– Алабуганы тотып торган нигез ташлар берничә: ярминкә каласы, завод каласы, нефть чыгару үзәге. Моношәһәр статусы тарих тарафыннан билгеләп куелган. Ул калага билгеле бер тышаулар сала, ә без Алабуганы заманча, тиз үзгәрергә сәләтле шәһәр итеп күрергә теләр идек, – дип сөйли Алабуга районы башлыгы урынбасары Зөлфия Сөнгатуллина. – Шәһәр үссен, яхшырсын өчен, төрле федераль һәм төбәк конкурсларында катнашып, инвестицияләр җәлеп итәргә тырышабыз.

Быел Алабуга тәүге тапкыр Россиядәге моношәһәрләрнең беренче унлыгында икенче урын алды. РФ Кече шәһәрләрне үстерү фонды тарафыннан оештырылган конкурска барлыгы 319 гариза кергән булган. Бәяләүнең иң төп шартларыннан берсе – монопрофильлекне тагын да тирәнәйтмәс өчен, шәһәр өчен төп юнәлеш булмаган предприятиеләрдә яңа эш урыннары булдыру иде. Конкурс 2017–2018 елларга 1200 яңа эш урыны оештыруны максат итеп куйганда, «Алабуга» МИЗ резидентлары –

Фото Алабуга муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды



Алабуга халкы шәһәрнең үзәк мәйданын реконструкцияләү проекты буенча фикер алышуда катнашты.

«Кастамону» һәм «Хәят Кимья» предприятиеләрендә инде җәйгә үк 1248 эш урыны булдырыла. Мондый югары технологияле заводлар өчен квалификацияле белгечләрне ресурс үзәге – җирле политехника көллияте базасында әзерлиләр.

Бәйгенең тагын бер шарты – «Төзекләндерүнең 5 адымы» программасын гамәлгә ашыру. Алабуга монда да үзен күрсәтте: таләп ителгән 36 балл урынына 48не җыеп, шәһәр программаны арттырып үтәде. «Бүген үзәктә» дип исемләнгән беренче «адым» Хәтер мәйданын һәм Шишкин һәйкәлен төзекләндерү, яңартуны көз уңында тота иде. «Киләчәк бар ул» исемле икенчесе –«Иске мәйдан» дигән территорияне заманча «Гуляй-парк»ка әйләндерүдән гыйбарәт булды. Өченче «адым» – «Үткәнне тап һәм аның белән горурлан» Олы Покров урамындагы скверны үзгәртеп корырга мөмкинлек бирде. «Игътибар фокусында – социаль объект» дигән дүртенчесендә Спас ярминкәсе һәм Чаң кагу фестивале уздырыла торган шәһәр соборы тирәсендә ял зонасы булдырылды. Янәшәдәге Шишкин күзгәзмә залына күптән көтелгән төзекләндерү эшләре башкарылды. «Ташланган чүпчарны ал» дип аталган бишенче «адым» – Нечаев исемендәге сквер – шул тирәдәге бистәнең беренче паркын төзүдән гыйбарәт иде. Проект өчен федераль үзәк финанслары 37,5 млн сум тәшкил итте, республика казнасыннан 66 млн сум чамасы акча алынды. Тагын 4 млн сум җирле бюджеттан бүлеп бирелде.

Алабуганың моношәһәрләр рейтингында статусы никадәр югарырак булса, «Алабуга» МИЗ резидентларының инвестиция мөрәҗәгатьләренә уңай җавап алыну мөмкинлеге дә шулкадәр күбрәк. Әйтик, 2017 елда Моношәһәрләрнең үсешенә булышлык күрсәтү фонды МИЗның ике предприятие-резидентына ташламалы финанслауга рөхсәт бирде: «Данафлекс Алабуга» һәм «Татнефть» Алабуга пыяла сүс» 941,5 млн сум күләмендә займ алды. Быел исә «Интэко Тюбинг» ҖЧҖ мөрәҗәгате хуплау тапты. Моннан тыш, «Айджиэс Агро», «Данафлекс Алабуга», «ТИС» һәм «Интэко Тюбинг» ҖЧҖ Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорациядән 1,67 млрд сумга якын ташламалы кредит алуга ирешә.

– Шәһәрне һәм МИЗны үстерү процессы бер-берсеннән аерып карала алмый. Алабуга никадәр матуррак һәм мавыктыргычрак калага әйләнсә, «Алабуга» МИЗ тәҗрибәле белгечләр өчен эшкә урнашу мәсьәләсендә шулкадәр кызыгырлык урын булачак, – ди Зөлфия Сөнгатуллина. – Әлбәттә, миграция дигән нәрсә бездә дә бар. Якында гына – Чаллы алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе. Кече һәм урта эшмәкәрлекне кызыктыруда безгә аның белән ярышу авыр. Шул ук вакытта МИЗда хезмәт куючыларның өч меңе – Менделеевск районыннан, Удмуртиядән һәм башка күрше район һәм төбәкләрдән. Районыбыздагы халык саны гел артып тора. Шулай булгач, без башка «тартылу нокталары» белән көндәшлек итәргә түгел, ә алар белән кластер принцибында хезмәттәшлек корырга ниятлибез. Мондый бәйләнешләр булдыру җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирә.

Гөлзада Руденко, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгының генераль директоры:

– «Хлебная» дип аталган мәйдан XIX гасыр башыннан борынгы Алабуганың мәдәни, сәүдә һәм территориаль үзәге булган. Алабугалыларның дистәләгән буыны очрашу турында сүз куешканда, элек тә һәм хәзер дә: «Мәйданда күрешербез!» – ди. XXI гасырда ул шәһәрдәге тарихи өлешнең, тыюлык зонасының үзәге булып калды, ләкин, ни кызганыч, әүвәлге күркәмлеген һәм күпмаксатлы кулланылу мөмкинлеген җуйды. Шулай да бүген бу мәйдан Алабугадагы туристлар уза торган барлык маршрутларының башлангыч ноктасы булып тора. Монда туристлар өчен мәгълүмат үзәге урнашкан, шәһәр белән танышу шушы мәйданнан башлана. Аның янәшәсендәге музейлы тарихи квартал чикләрендә – яңарту-төзекләндерү программасына кергән Казан, Гассар һәм Говоров урамнарында шәһәр мирасханәләренең күбесе, социаль инфраструктура учреждениеләре, һөнәри уку йортлары, сәүдә һәм сувенир лавкалары урын тапкан. Бөтенроссия Спас ярминкәсе һәм барлык шәһәркүләм бәйрәмнәр уздырыла торган атаклы Шишкин буалары да биредә. Җәмәгатьчелек белән очрашуларда түбәндәге тезис әнә шул сәбәпле формалаша: заманча җәмәгать урыннары, уңайлы шәһәр мохите хәзерге кварталларда гына түгел, үзәге Ленин мәйданыннан гыйбарәт тарихи бистә чикләрендә дә булдырылырга тиеш. Җәяүле ял зоналары һәм җәмәгать активлыгы урыннарын булдыру тирә-яктагы мәдәни мирас объектларын төзекләндерү һәм аларның тышкы фасадын реставрацияләү белән бергә барырга тиеш. Үзәктәге тарихи объектларының төп өлеше 1850–1870 нче елларга караган Алабуга архитектура һәйкәлләрен тиешле хәлдә саклап-тәрбияләп тотуда җитди авырлыклар кичерә. Борынгылык һәм заманчалыкны берләштереп, Ленин мәйданы символик рәвештә төрле буын вәкилләрен, кызыксынулары, белем дәрәҗәләре төрле булган кешеләрне үзара бәйли, һәм һәркемне үзенә җәлеп иткән, тартып китергән урын булып тора. Әлеге генетик бәйләнешне саклап кына калмыйча, мәйданны кала халкы өчен максималь уңайлы урынга әйләндерү дә бик мөһим. Эстетик һәм мәдәни таләпләрне канәгатьләндерү генә түгел, актив эшчәнлек планын да күздә тоту сорала. Монда һәркемнең җанына якын шөгыль таба алуы әһәмиятле.

Сәүдәгәр Подуруев утарында хәзерге вакытта Шәһәр тарихы музее урнашкан, киләчәктә сәүдәгәрләр көнкүрешен яктырткан экспозиция әзерләү күздә тотыла (Чистай ш., Карл Маркс ур., 8).



Эвакуация вакытында Борис Пастернак яшәгән йорт. Бүгенге көндә шагыйрьнең музее (Чистай ш., Ленин ур., 81).

ТАРИХ ӨЧЕН МАХСУС КЫСА

Чистай каласы искиткеч шәп бэкграундка ия. Урта гасырлардагы Җүкәтау халкы, инкыйлабка кадәрге Россиянең атаклы сәүдәгәрләре һәм сәнәгатьчеләре, галимнәр һәм инженерлар, дөньякүләм билгеле әдипләр, дин, иҗат, идарә өлкәсендә бу төбәкнең якты шәхесләре – болар барысы да, монда озак еллар яки кыска гына вакыт яшәп, шундый зур документаль мирас калдырган, башкаладагы теләсә кайсы музей көнләшер иде. Ләкин мәдәни-тарихи байлык ягыннан Казан, Болгар, Зөя, Алабуга һәм күрше төбәкләрдәге төрле популяр калалар белән көнләшерлек Чистай инде күп еллар үзенең туристлык потенциалын тормышка ашыру юлларын эзли.

Мәдәни мирас объектларын реставрацияләү һәм үзгәртеп кору белән бер үк вакытта музейларны һәм туристлык инфраструктурасын үстерүне күздә тоткан комплекслы программа беренче тапкыр 2012 елда әзерләнә. 2015 елда Чистай Россиянең башка шәһәрләре арасында «Кече тарихи шәһәрләрне һәм бистәләрне саклау һәм үстерү» конкурсында җиңү яулады, әлеге бәйге Бөтендөнья үсеш банкы аша финанслана иде. Чистай проекты аның үзәк өлешен торгызу һәм үзгәртеп коруга акча бүлеп бирүне күздә тота иде. Ләкин бу эшкә санкцияләр комачаулады. Янә инвестор эзләргә керештеләр. Һәм менә, ниһаять, бу елның май аенда БРИКС илләренең Яңа үсеш банкы президенты Кундапур Ваман Каматх Шанхайдагы очрашу вакытында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка сөенечле хәбәр җиткерде: кече тарихи бистәләрнең территориясен һәм инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Россия тарафыннан тәкъдим ителгән һәм банк финанславы буенча хупланган тугыз проект арасына Чистайныкы да кергән. Россия мөрәҗәгате буенча проектларга бүлеп биреләчәк 220 млн долларның 38 млн долларын Чистай алачак.

«Туризмны үстерүдән кала, Чистайда башка «таяныр нокталар» бар икәнен күрәбез... Мондый комплексны тормышка ашыру кулланылганда, синергия эффекты тәэмин ителә. Бер яктан, ул Россия туристлары санын арттырачак, икенче яктан, параллель рәвештә җирле халыкның керемнәре дә үсүгә барачак, ә алар исә, үз чиратында, шәһәр инфраструктурасы үсеше өчен күбрәк акча тота башлаячаклар», – дип, үз фикере белән уртаклашты Яңа үсеш банкының Россия буенча белгече Тянь Хе март аенда Чистайга сәфәре вакытында.

Акча бүлеп бирүнең бер шарты – финанслауга проектны тормышка ашыручыларның да өлеше кертелү. Мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән сумманың 25 проценты күләмендә акча таләп ителә. Чистай очрагында бу федераль үзәк һәм республика акчалары булачак. Әйтик, бер проектны тормышка ашыруны – пассажир пристанен үзгәртеп кору эшен Татарстан тулысынча үз кулына ала.

– Яңа үсеш банкы акчалары, беренче чиратта, ун музей корылмасын реставрацияләүгә юнәлтеләчәк. Әлеге музейларның кайберләре XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башларына караган биналарда урнашкан. Реконструкциягә капиталь төзекләндерү, эшләп килгән һәм яңа ачылган музейларны заманча интерактив җиһазлар белән тәэмин итү керә, – дип сөйли Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәбият музей-тыюлыгы директоры Александр Печёнкин. – «Укытучы йорты» әдәби-мемориаль музееның һәм Борис Пастернак мемориаль музееның гамәлдәге экспозицияләрен төптән яңарту планлаштырыла. Шәһәр тарихы музее сәүдәгәр Чукашевлар йортында (әле күптән түгел генә анда Чистай педагогика училищесы эшли иде) урын алачак.

Хәзер Шәһәр тарихы музее Карл Маркс урамында, I гильдия сәүдәгәре Алексей Подуруев йортында эшләп килә. Анда сәүдәгәр көнкүрешенә багышланган тулы бер күргәзмә булдыру планлаштырыла. Музейда шул чорга «алып кереп китә торган» интерактив программаны инде хәзер үк тәкъдим итәләр. «Чистайда сәүдәгәр якшәмбесе» проекты кысаларында сәүдәгәр һәм аның хатыны кунакларны каршы ала, аларны залларга озата бара. Анда исә сәүдәгәр йорты мохитенә «чумарга», эш, йокы бүлмәләрен күрергә, йорт хуҗасы лотерея уйната торган сәүдә лавкасын карарга, мүк җиләге төнәтмәсен авыз итәргә мөмкин...

Казанда һәм Биләрдә атаклы галим, органик матдәләрнең химик төзелеше теориясенә нигез салучы Александр Бутлеровның музей-бүлмәләре ачылган. Ә менә Александр Михайловичның туган ягы Чистайда аңа багышланган музей әлегә юк. Ләкин булачак! Һәм гади музей гына түгел! Анда чып-чын химия лабораториясе урын алачак, химия дәресләре, тематик лекцияләр һәм укулар узачак.

Бөек Ватан сугышы елларында башка әдипләр белән бергә Мәскәүдән эвакуацияләнгән язучы Леонид Леонов Карл Маркс урамындагы (22 нче йорт) флигельгә (элекке куас кайнату бинасы) урнаша. Әлеге бина асылда келәтне хәтерләтә, язучы-

Фотолар Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-тыюлыгыннан, chistopol.ru; photoplaneta.com; vsedomarossii.ru сайтларыннан алынды

Карл Маркс ур., 1 адресы буенча урнашкан йортта Сәяси репрессия корбаннары музеен ачу планлаштырыла (Чистай ш.).



Эвакуация вакытында язучы Леонид Леонов яшәгән флигель (Чистай ш., Карл Маркс ур., 22).

га аны рәтләп, кеше яшәрлек хәлгә китерергә туры килә. Шундый кысынкы, аскетик шартларда Леонид Леонов «Ябырылу» пьесасын иҗат итә, Мәскәү һәм Ленинградтан эвакуацияләнгән актерлар аны Чистай шәһәр театрында куя. Автор бу пьесасы өчен Сталин премиясенә лаек була һәм бүләкнең акчалата өлешен тулысынча фронт ихтыяҗларына тотарга бирә... Шул ук йортта драматург һәм хәрби корреспондент Илья Сельвинскийның гаиләсе эвакуациядә яши. Драматург үзе дә кыска вакытлы ялларда Чистайга сугыла... Проект буенча, Карл Маркс урамындагы зур булмаган бер катлы йорт Леонов һәм Сельвинскийларның Мемориаль музеена әвереләчәк.

Ә шул ук урамдагы 1 нче санлы йортта Сәяси репрессияләр корбаннары һәм диссидентлык музее ачу планлаштырыла. Билгеле булганча, XIX гасыр уртасыннан башлап, Чистай төрмәсе хөкүмәткә каршы восстаниеләрдә катнашучыларны, оппозиционерларны, интернированиегә дучар ителгән хәрбиләрне, сәяси тоткыннарны сыендырган. XX гасырның 30 нчы елларында Чистай төрмәсендә «халык дошманы» ярлыгы тагылган шәхесләр тотылган. XX гасырның 70–80 нче елларында бу зинданда мәшһүр галим Михаил Казачков (СССРның соңгы сәяси тоткыны), Натан Щаранский (соңыннан Израильнең вице-премьеры була), язучы диссидент Анатолий Марченко (ачлык игълан итүенең 117 нче көнендә үлә) һәм башка бик күп күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре тоткынлыкта була... Музей экспозициясенең нигезен архив документлары, тоткыннарның һәм аларның гаилә әгъзаларының истәлекләре тәшкил итәчәк.

Проект кысаларында Күргәзмә залы булдыру да ниятләнә. Ул музей-тыюлыкка үз фондларындагы, башка мирасханә фондлары һәм шәхси тупланмалардагы ядкәрләрдән тематик күргәзмәләр оештыру өчен кирәк. Шунысы игътибарга лаек: музей һәм күргәзмә объектлары бер-берсеннән бик якын, берничә адымлык ераклыкта гына урнашкан һәм тарихи мәркәзнең бердәм фрагментына тупланган. Чистай дәүләт музей-тыюлыгы биналарыннан кала, проектта расланган фрагменттагы башка мәдәни мирас биналарында да өлешчә реставрация эшләре башкарылачак.

«Шәһәрнең төп урамындагы бульвар» дип исемләнгән Чистай проекты Кече шәһәрләрдә һәм тарихи бистәләрдә шәһәр мохите булдыру проектлары конкурсында грант яулады. Бу проект Карл Маркс урамында инфраструктураны яңарту һәм шәһәр халкы өчен яңа ял зонасы булдыруга багышланган. Әлеге ниятләрне тормышка ашыру өчен якын көннәрдә Чистай 100 млн сум алачак.

– Яңа үсеш банкына тәкъдим ителгән план буенча, беренчә этапта (музейлар төзекләндерелүгә билгеле бер чират буенча ябылып, әзерләре ачыла торырга тиеш) алып барылачак барлык эшләрне 2024 елда тәгәлләү каралган, – дип ачыклык кертә Александр Печёнкин. Бу вакытка инде проектка кече һәм урта эшмәкәрлек вәкилләре дә җәлеп ителер дип уйлыйм. Ләкин шундый киң колачлы реконструкциянең Чистайга нинди зур мөмкинлекләр ачачагын инде хәзер үк күзалларга мөмкин.

СҮЗ УҢАЕННАН

Кече шәһәрләрдә һәм тарихи бистәләрдә шәһәр мохите булдыру проектларының 2018 елгы Бөтенроссия конкурсында җиңүчеләр 30 млн нан 100 млн сумга кадәр субсидия алачак. Татарстаннан әлеге бәйге финалына 23 проект узды, шуларның 14е җиңүче дип табылды. Республика конкурс бюджетында каралган 5 млрд сумның 920 млн сумын яулап алуга ирешә.

«10 меңнән 20 меңгә кадәр кеше яши торган кече шәһәрләр» номинациясендә Россиянең төрле төбәкләреннән 15 проект җиңү яулады. Алар арасында – Татарстаннан: Минзәләдә Минзәлә елгасының яр буе, Тәтештә шәһәр буасы, Әгерҗедә «Орешник» паркы, Кукмарада бертуган Комаровлар йорты проектлары. Боларны тормышка ашыруга 50шәр млн сум акча биреләчәк.

«Тарихи бистәләр» номинациясендә җиңүчеләр исемлегендә – Алабугадагы Ленин мәйданын төзекләндерү (1 нче урын) һәм Биләрдә «Изге чишмә»не һәм авыл күлен тәртипкә салу проектлары. Җиңүчеләр 50шәр млн сум алачак.

«50 меңнән 100 меңгә кадәр кеше яши торган кече шәһәрләр» номинациясендә Бөгелмә (шәһәр үзәген активлаштыру), Лениногорск (Горький исемендәге мәдәният һәм ял паркы) һәм Чистай (Карл Маркс урамы буйлап бульвар) призлы урыннар алды. Бу шәһәрләргә 100әр млн сум бүлеп биреләчәк.

«10 меңгә кадәр кеше яши торган кече шәһәрләр» номинациясендә Болгар (Пионер урамындагы мәйдан) һәм Лаеш (Чулман елгасы яр буе) 30ар млн сумлык бүләккә лаек булды.

«20 меңнән 50 меңгә кадәр кеше яши торган кече шәһәрләр» номинациясендә Баулы («Нефтьче» паркы), Нурлат (Карл Маркс урамы) һәм Азнакай (Сөембикә урамы) проектлары билгеләп үтелде – бу шәһәрләр төзекләндерү эшләре өчен 80шәр млн сум алачак.

«ШАРТЛАУ»ГА ХӘТЛЕ ҺӘМ АННАН **СОҢ**

Ел саен 450 мең инсульт очрагы – илебездәге аяныч статистика әнә шундый. Бу кешеләрнең 50 проценты шунда ук вафат була яки бер ел эчендә үлә. Нәкъ бер ел элек Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы бу авыру белән көрәш ысулын тамырдан үзгәртергә карар кылды, һәм республикада 18 кан тамырлары үзәге ачылды. Табибларның кешеләрне үлем кочагыннан ничек йолып алганын үз күзебез белән күрер өчен, без шул үзәкләрнең берсенә юл тоттык.

Автор:
Ольга Туманская

Карават өстендәге монитор саннар һәм графиклар белән чуарланган. Күпсанлы чыбыклар һәм көпшәләр кеше гәүдәсенә тоташкан, аның гомере әнә шул символларның тәртипле тезмәсенә яшеренгән. Бәла һич көтмәгәндә китереп суга: бу ханымның башында гигант аневризма туры мәгънәсендә шартлаган дияргә мөмкин. Тормышка өметне сүндерерлек бик катлаулы очрак була ул, ә Республика клиник хастаханәсенең Инсульт үзәге табиблары әлеге хатынны яңадан дөньяга кайтара.

– Безне монда чын-чынлап коткаралар, – ди авыруның кызы Анна. – Әни инде күзләрен ача башлады. Безнең хәлдә бу – бик зур алга китеш...

Без интенсив терапия палатасына – Инсульт үзәгенең «йөрәгенә» узабыз. Хастаханәгә эләгүләренең беренче тәүлегендә, хәленең ни дәрәҗәдә авыр булуына карамастан, барлык пациентлар да шушында яткырыла. Хәер, «җиңел» авырулар булмый да монда – «Ашыгыч ярдәм» инсульт билгеләре белән алып килгән хасталар гына. Заманча җиһазландырылган алты ятак буш тормый диярлек.

– Кайчандыр мондый хасталарның 90 проценты һәм аннан да күбрәге авыру башлануның беренче өч көнендә үлә иде, – дип сөйли Инсульт үзәге җитәкчесе, Татарстанның атказанган табибы, утыз елдан артык эш тәҗрибәсенә ия невролог Халид Ибад оглы Мамедов. – Хәзер Россия буенча үлем очракларының саны 22 процент тирәсе. 15 проценттан ким булганда, бу инде шактый яхшы нәтиҗә санала. Без исә әлеге санны 10га кадәр төшерә алдык.

Әлеге Инсульт үзәге Республика клиник хастаханәсе структурасына керсә дә, үзенә бер аерым бүлекчә булып тора. Ул мультидисциплинар эш йөртү алымын куллана: биредә кабул итү бүлегеннән тернәкләндерү үзәгенә кадәр – бөтен нәрсә дә бар. Татарстанда бүген шундый 18 медицина хезмәте эшли. Республика пилот проектны уңышлы тормышка ашырды һәм инсультны дәвалау өлкәсендә алдынгы тәҗрибә зонасына әйләнде. Моның

Фото: Александр Ефремов

Тормышка өметне сүндерерлек бик катлаулы очракта да РКХ Инсульт үзәге табиблары авыруга яңадан гомер бүләк итә.

РКХ Инсульт үзәге табиблары. Әлеге Инсульт үзәге Республика клиник хастаханәсе структурасына керсә дә, үзенә бер аерым бүлекчә булып тора. Бирелә кабул итү бүлегеннән тернәкләндерү үзәгенә кадәр – бөтен нәрсә дә бар. Татарстанда бүген шундый 18 медицина хезмәте эшли.

нәтиҗәсе – коткарып калынган меңләгән гомер, гариплек һәм үлем очраклары санының шактый кимүе.

Интенсив терапия палатасы эше белән бик тәҗрибәле реаниматолог җитәкчелек итә. Аның фамилиясе дә (Образцов!) бу эшкә бик килешеп тора, чөнки кеше гомерләре нәкъ менә аның карамагына ышанып тапшырылган медперсонал гамәлләренең дөреслегенә бәйле. Александр Федоровичтан табиблык карьерасындагы иң катлаулы очракны искә төшерүен үтенәм. «Андый хәл булганда, соңыннан бернәрсә турында да сөйләшәсе килми, бөтенләй искә төшермәвең хәерлерәк!» – ди ул арыган бер елмаю белән. Хәер, мисал эзләп ерак барасы да түгел: караватларның берсе буш, тик әле бер сәгать элек кенә анда авырлы хатын ята иде.

– Йөклелек фонында баш миенә кан саву – сирәк күренеш түгел, – дип сөйли Халид Мамедов. – Кеше үзен сәламәт дип хис иткән вакытта мондый куркынычны фаразлау мөмкин түгел диярлек. Менә бу хаста хатынның баш мие кан тамырында аневризма шартлаган иде. Аңа эндоваскуляр операция ясадык – бот кан тамыры буенча авыру урынга кереп, ул урынны кан әйләнешеннән өздек. Шөкер, өлгердек!

БӘЛА ЯКЫН ЙӨРМӘСЕН ӨЧЕН

Хастаханә коридорын тиз генә үтеп китеп булмады.

– Әссәламегаләйкем! – дип сәламли Халид әфәндене хезмәттәше. – Сез сурәтләрне карадыгызмы?

– Исәнмесез! Сезнең белән киңәшергә теләгән идем… – бер минут та үтми, аны инде башка табиб туктата…

Халид Ибад оглы – һәркемгә кирәкле кеше. Шуңа да карамастан, ул безгә вакыт таба, бөтен бүлмәләрне күрсәтеп йөри, хезмәткәрләр белән таныштыра, Үзәкнең эше турында җентекләп сөйли… Ниндидер бер мизгелдә, аны матбугат вәкилләре белән аралашуга караганда күпкә мөһимрәк эшләрдән аерганым өчен миңа уңайсыз булып китә.

– Юкка борчыласыз – хезмәтегез бик кирәкле һәм файдалы! – дип шик-шөбһәләремне шунда ук тарата ул. – Инсультның беренче билгеләре турында халыкка мәгълүмат җиткерү безнең үзебез өчен дә бик мөһим. Чөнки күп очракта үлемнән дә, гариплектән дә котылып калып була!

ГОМЕР МИНУТЛАРЫ

Инсультның нинди билгеләрен һәркем белергә тиеш?

– Үз-үзеңә диагноз куюның гап-гади алгоритмы бар, – дип аңлата Халид Мамедов. – Ул FAST дип атала, инглиз телендәге face, arm, speech һәм time, ягъни йөз, кул, сөйләм һәм вакыт дигән сүзләрдән.

Кинәт сөйләшә алмый башласагыз яки сөйләмдә бераз гына булса да авырлыклар килеп чыкса, кичекмәстән «Ашыгыч ярдәм» чакырыгыз. Бу – инсультның бер билгесе.

Йөзегез кыйшайдымы, елмая алмыйсызмы? Тизрәк 03 номерын җыегыз!

Кулыгызны күтәрә алмыйсызмы, гәүдәгезнең башка бер өлеше катып калдымы, хәрәкәтләнми торган хәлгә килдеме? Озакка сузмагыз, бу инсульт булырга бик мөмкин.

Һәм соңгысы – вакыт. Табиблар өчен ул шактый чикләнгән – нибары 4,5 сәгать кенә. Ләкин югарыда санап кителгән билгеләрнең берсен булса да үзегездә сизүгә, ярты сәгать эчендә табиблар кулына эләксәгез, үлем янаган халәттән өзлегүләрсез генә котылу мөмкинлеге шактый арта дигән сүз.

1. Татарстанның атказанган табибы, утыз елдан артык эш тәҗрибәсенә ия невролог Халид Мамедов. Чын мәгънәсендә үрнәк алырлык зат.

Без кабул итү бүлегенә якынлашабыз, төгәлрәк әйткәндә, экстрен диагностика зонасына. Инсульт кичергән кешеләр савыгуга озын юлларын шушыннан башлый. Үзәк елына барлыгы 750 хастаны кабул итә ала. Аларның һәрберсе хакында «Ашыгыч ярдәм»дәге хезмәттәшләре табибларга алдан шалтыратып хәбәр сала, шуңа күрә хастаханә территориясенә кереп барган машинаны табиблар бригадасы тулы әзерлектә каршы ала.

– Ишектән алып кереп, энә кадаганчыга кадәр табибларга бер сәгать вакыт бирелә – үзәкнең принцибы шундый. Аңлашыла инде, шуңа да чират дигән төшенчә юк! Авыру кеше шул бер сәгать эчендә инде интенсив терапия палатасында ятарга тиеш, – дип сөйли Халид Ибад оглы. Мондый медицина логистикасын аңлау кыен түгел – аны идәндәге уклар бик яхшы күрсәтеп бирә. Шулар кушкан юнәлештә барып, компьютер томографиясе бүлмәсенә элгәбез. Баш мие нейровизуализациясе табибларга патологияне үз күзләре белән күрергә, инсультның кеше сәламәтлегенә китереп өлгергән зыян дәрәҗәсен билгеләргә, алга таба дәвалау тәртибе турында карар кабул итәргә мөмкинлек бирә. Барысы да энәсеннән-җебенә кадәр тәртипкә салынган һәм яхшы аңлаешлы кебек тоела, ләкин чынлыкта эшләр алай җиңел вә гади генә түгел.

Эш шунда ки, кайбер очракларда инсультны томографиядә хәтта алты сәгать дәвамында да күреп булмый – аның ишемия учагы формалашырга өлгермәгән була. Ләкин минутларга кадәр санаулы – тиешле карарны кичекмәстән кабул итәргә кирәк. Һәм менә шул вакытта табибларга магнит-резонанс томографиясенең махсус режимы ярдәмгә килә. Анда исә инсультны башлангыч ноктасыннан соң 10–15 секунд узгач ук күреп була. Бу исә авыруга тромболитик препаратлар – кан куерыкларын (тромбларны) эретә торган дарулар кадау турында карар кабул итү һәм шул рәвешле кан әйләнешен торгызу өчен мөһим. Мондый дарулар беренче 4,5 сәгатьтә генә нәтиҗәле, бу вакыт аралыгын табиблар «терапевтик тәрәзә» дип атый. «Тәрәзә» ябылганда, инде соң булачак...

Хәер, Республика клиник хастаханәсенең Инсульт үзәге табиблары вакытны кирегә борырга өйрәнгән. Әле күптән түгел генә алар «терапевтик тәрәзә»не озайтырга сәләтле тромбоэкстракция хирургия процедурасын куллана башлаган.

– Бер атна элек безгә бик авыр инсультлы авыру эләкте, – дип сөйли Халид Мамедов. – Ул биш сәгатьтән дә артык вакытка соңрак китерелде. Бу очракта тромболитик препаратлар нәтиҗәле түгел, әмма авыруга ярдәм итәргә кирәк иде бит! Аны коткару эшенә рентгенангиохирурглар кушылды, алар бот артериясе аша тромбны алды һәм кан әйләнешен торгызуга иреште. Бу катлаулы, ләкин бик нәтиҗәле гамәл. Безнең функциональ бурычларыбыз исемлегенә кермәсә дә, андый операцияләр уздыру өчен кирәкле бөтен ресурсларыбыз бар! Бу исә безнең үзәкнең эшен киңәйтү мөмкинлеге турында сүз алып баруга юл ача.

ЭВЕРЕСТНЫ ЯУЛАУ

Гап-гади мәктәп тактасында акбур белән таблица сызылган: һәр фамилия каршында – нульдән унга кадәр баллар. Бу – кешенең мөстәкыйльлек дәрәҗәсен билгеләргә мөмкинлек бирә торган мобильлек шкаласы. Аның саннарында – табибларның, авыруларның, аларның туган-тумачасының уртак эш нәтиҗәсе. Без хәзер Инсульт үзәгенең тернәкләндерү бүлегендә. Инсульт кичергән авыруларның иң беренчел тернәкләнү процессы шушында башкарыла.

– Төп максатыбыз – кешене, ким дигәндә, ун метр ярдәмсезнисез атлап йөрергә өйрәтү, – дип сөйли табиб-реабилитолог Евгений Акишин. – Менә шул күнекмәне ныгыткач кына, хаста кеше алга таба тернәкләндерелүгә юл тота ала. Әлеге максатка таба акрынлап барабыз. Әүвәл утырырга, аннары кучеп утырырга, басып торырга һәм шуннан соң гына йөрергә өйрәнәбез.

Тернәкләндерү үзәге пациентларының күп өлеше яткан хәлдәге авырулар булганын исәпкә алганда, мондый максат аларга Эверестны яулау белән бер күренә. Кеше мөмкинлекләренең аръягына чыккан әлеге тырышлыкны кирәкле «таулар-га» таба юнәлтү өчен, тәҗрибә һәм йомшак мөгамәләдән кала, табиблар арсеналында тиешле күнекмәләрне ясау өчен махсус җиһазлар һәм гади хәрәкәтләрнең дөрес техникасын колачлаган методика бар.

– Ләкин шулай да тернәкләндерү процессы әңгәмәдән башлана, – дип аңлата Евгений Михайлович. – Тегe яки бу кешенең көнкүрешендәге бөтен нечкәлекләрне игътибарга алабыз. Үз-үзенә хезмәт күрсәтү кебек бик гади, вак нәрсәләр турында сөйләшәбез. Мөстәкыйль рәвештә юыну,

киенү, ашау турында... Без кешенең мобильлек шкаласына карап, бары тик чынга ашырырлык максатлар гына куябыз. Ягъни ул башкарырга теләгән түгел, аның хәзер хәленнән килерлек гамәл-хәрәкәтләргә омтылабыз.

Ни кызганыч, еш кына табибларга авыруларны күктән җиргә төшерергә туры килә. Хасталарның кайберләре үзәктән чыкканда, хәтта кибетләргә дә йөри алырбыз дип, ихлас ышана. Ләкин кеше үзенең табанын яки аягының баш бармагын тоймый икән, ничек шулай йөри алсын, ди? Статистика күрсәткәнчә, инсульт кичергән кешеләрнең 39 проценты хастаханәдә егыла, 73 проценты – өйдә... Уртача алганда, егылу куркынычы ярты ел чамасы саклана әле.

– Яхшы нәтиҗә докторларның эш-гамәлләреннән генә тормый, – дип аңлата Халид әфәнде. – Бу мәсьәләдә халыкка белем таратуның да, авыруны тиешенчә тәрбияләү һәм табиб киңәшләрен йөз процент үтәүнең дә әһәмияте зур. Бергә эш йөрткәндә генә бу компонентлар авыруның актив тормышка кайтуыннан гыйбарәт уңышлы дәвалану мөмкинлеген берничә тапкыр арттыра!

Дөньякүләм актуаль тенденцияләр куркыныч тудыручы факторларны өйрәнүгә һәм инсультны башланганчы ук дәвалауга көннән-көн күбрәк басым ясый, дип ассызыклый Халид Мамедов. Сәламәт тормыш рәвешенә күчегез: артык авырлыкка, югары кан басымына, шикәр чиренә, йөрәк авыруларына һәм холестерин күтәрелүгә китерә торган зарарлы гадәтләрдән арыныгыз – шул вакытта бәладән котылып булачак. Ләкин кайчак кеше һичничек үз-үзен йөгәнли, сәламәтлегенә зыян китерүдән туктый алмый – бу очракта туганнарына нишләргә?

– «Үлемгә барасың бит! Яшисең килә икән, тукта, тыел!», – әнә шулай турыдан-туры әйтеп, тукый-тукый аңлатырга кирәк, – дип киңәш бирә Халид Мамедов. – Диета, җәяү йөрү, канда шикәр, холестерин күләмен даими тикшереп тору – хәтта менә шундый гади генә ысуллар да инсульт барлыкка килү куркынычын киметергә сәләтле.

Бүген республика хастаханәсендә махсус Инсульт мәктәбе эшли. Бу – халыкка белем бирү эшенә кан тамырлары үзәгенең кертән өлеше. Әлеге мәктәпне авырулар һәм аларның туганнары гына түгел, хезмәт юлында тәүге адымнарын ясаучы табиблар да уза.

– Кешене паралич суккан икән, ул әле һаман да, бәлки, үтеп китәр, дип уйлый. Әлеге саксызлык, наданнарча фикер йөртү нәтиҗәсендә ашыгыч ярдәм чакыруны соңарталар! Минемчә, хәтта балаларга да бу хакта аңлатырга кирәк, – дип басым ясый Халид Мамедов.

ҺӨНӘРИ КУАНЫЧ

Халид Мамедовның озынозак тәҗрибәсендәге аеруча игътибарга лаеклы мизгелләр, мөгаен, инсульт белән хәтта бәйле дә түгелдер. Кайчак бу чиргә хас билгеләрдән гыйбарәт битлек артында бөтенләй башка халәт яшеренергә мөмкин. Күптән түгел Республика клиник хастаханәсенең кан тамырлары үзәгенә әнә шундый авыруны алып киләләр. Чирне ачыклауда нигездә аппаратура түгел, ә табибларның эш тәҗрибәсе булыша. Бу ир-атта паралич түгел, ә мускуллар хәлсезлеге буларак билгеле миастения авыруының катлаулы формасы икән. Инсульт вакытында уңышлы кулланыла торган кан тамырлары терапиясе андый халәттә үлемгә китерергә мөмкин.

Сүз уңаеннан, мондый хәлләр теләсә кайчан һәм теләсә кайда булырга мөмкин. Шуңа күрә тәҗрибәле табиблар инсульт үзәгендәге яшь хезмәттәшләренә генә түгел, башка хастаханәләрдәге табибларга да киңәшләрен җиткерә. Монда исә аларга телемедицина ярдәм кулы суза – Республика клиник хастаханәсе базасында технологик ситуация үзәге оештырылган, аның белән республиканың барлык медицина учреждениеләре диярлек элемтәдә тора. Рәсем-сурәтләрнең электрон архивы да эшне җиңеләйтә, шуның бәрабәренә табиблар хәтта чит шәһәрдәге авыруларның да медицина тикшеренүе нәтиҗәләрен бик тиз карый ала.

– Тәүлегенә 24 сәгать дәвамында эш процессыннан аерылмау... Каян шулкадәр көч аласыз? – дип сорыйм Халид әфәндедән.

– Безнең дә үз һөнәри шатлыккуанычларыбыз бар, – дип елмая ул. – Уңышлы тромболизис операциясеннән соң – әле энә кадалган килеш – авыруның параличы беткәндә була ул. «Кулыгызны күтәрегез әле», – дисең аңа, һәм кулы хәрәкәткә килә, югары күтәрелә. Ярты сәгатьтән соң: «Аягыгызны күтәрегез», – дип сүз катасың. Анысы да селкенә. Бу – без көткән нәтиҗә һәм эшебездән иң зур канәгатьлек алган мизгелләр. ■

2. Табиб-реабилитолог Евгений Акишин: «Төп максатыбыз – кешене, ким дигәндә, ун метр ярдәмсезнисез атлап йөрергә өйрәтү».

3. Ишектән алып кереп, энә керткәнчегә кадәр табибларга бер сәгать вакыт бирелә – үзәкнең принцибы шундый. Аңлашыла инде, шуңа да чират дигән төшенчә юк.

PRESSA

КОЯШ НУРЫ СҮНГӘНДӘ...

Көн саен якыннарыңны, кояшны, яшәгән җиреңне күрү бәхетме? Бәхет, тик без бу турыда уйламыйбыз. Кем әйтмешли, көндәлек мәшәкатьләр баштан ашкан. Ә бит кайберәүләр өчен менә шушы гадәти күренешләр дә – чынга ашмаслык хыял...

Сукыр калганыңны белгәч, гаҗизләнтән, яшәргә теләмичә, тәрәзәдән сикерәм дигәндә, үзеңне кулга алырга нәрсә этәрә? Кара болыт каплаган дөньяда яшәү ничек була?

Автор:
Руфия Фазылова

ХАЛЫК ЗУР КӨЧ КУЙДЫ...

Татарстанда сукырлар белән эшләүче бердәнбер оешма – «Ярдәм» милли ислам хәйрия фонды бар. Алар күрү бәхетеннән мәхрүм булган кешеләргә матди һәм рухи яктан ярдәм итәләр. «Ярдәм» фондының башлангычы 2000 нче елларга барып тоташа. Ул вакытта бүгенге кебек хәйрия фондлары, хәйрия чаралары юк дәрәҗәсендә. Казанның Левченко бистәсендә урнашкан «Ярдәм» мәчете иң беренчеләрдән булып авыруларга, фәкыйрьләргә булыша башлый.

– Хәтерлим, мөселман балаларына җәйге лагерь оештырган идек, – ди «Ярдәм» фондының укыту-тернәкләндерү үзәге директоры Мәликә ханым Гыйльметдинова. – Урамнан узып баручы бер әни: «И, сау балаларга теләсә кая барырга була, менә безнекеләр генә өйдә ята», – диде. «Соң, сез дә балагызны алып килегез», – дидем. Баксаң, бу апаның баласы чукрак икән, тагын башка чирләре дә бар. Ә безнең ишетмәүчеләр белән эшләү тәҗрибәсе юк, сурдотәрҗемәче эзләп киттем...»

– Мондый зур күләмле грантка беренче тапкыр ия булдык, – диде Мәликә ханым Гыйльметдинова.

Тиз арада Мәликә ханым «чукраклар телен» өйрәнә. Ни өчен дигәндә, Казанда, дин сабакларын аңлатырлык сурдотәрҗемәче булмый. Ишетмәүче балалар белән эш шулай башлана. Ул да түгел, начар күрә торган яки бөтенләй күрмәүче кешеләр дә мәчеткә килә башлый. «Безне дә гарәпчә укырга өйрәтмәссезме?» – диләр. Баксаң, Луи Брайль системасы буенча Татарстанда беркайда да Коръән укырга өйрәтмиләр икән. Мәликә ханым монысына да алына. Хәтта күрмәүчеләр белән эшләү методикасы яза, аны соңрак китап итеп бастыралар.

2003 елда «Ярдәм» мәчете кысаларында хәйрия фонды оеша. Юк, ул әле рәсми рәвештә теркәлми. Ә димәк, дәүләт программалары кысаларында оештырыла торган грантларда да катнаша алмый. Фонд оешуның әлеге этабында аны башлап йөрүчеләр ярдәм кирәк булган кешеләрнең исемлеген теркәү, шуларга ярдәм итүчеләрне эзләү кебек бурычлар белән генә чикләнә.

Фото: Лилиана Вәлитова

«Ярдәм» мәчете башлаган социаль эшләр турындагы хәбәр тиз таралды, – ди Мәликә ханым. – Күрмәүчеләрдән соң, гариплләр арбасында йөрүчеләр мөрәҗәгать итте. Төрле гозер белән киләләр: кемнеңдер ислам нигезләрен өйрәнәсе килә, кайсынадыр ортопедия матрасы, башка шуның ише нәрсәләр кирәк. Ә бит Левченко бистәсендәге мәчет кечкенә генә. Барлык теләгән кешегә дә дин сабаклары укыту да хәлебездән килерлек түгел иде. «Эх, шәһәр үзәгендә зур мәчет төзеп, шунда авыруларга ярдәм итү үзәге булдырсаң иде!» – дип еш хыялландык. Күрәсең, Аллаһның «Амин!» дигән чагына туры килгәнбездер. 2013 елда Мәскәү районының Серов урамында бик зур бина – «Ярдәм» мәчете сафка басты. Аны төзүдә республика җитәкчелеге дә, гади халык та зур көч куйды.

Компьютер классында дәресләр бара.

10 МИЛЛИОН – УЛ АЗМЫ, КҮПМЕ?

Бүген «Ярдәм» мәчете гыйбадәт урыны гына түгел, ә үзенә күрә бер социаль үзәк тә. Күрмәүче, ишетмәүче, аягында йөри алмаучы авыру кешеләр (мөселманнар, димим, чөнки бирегә башка дин вәкилләре дә килә), чиратлап килеп, бер ай яшәп китәләр. Нәкъ шифаханәне хәтерләтә ул. Аерма шунда гына – биредә тән белән бергә җанны да дәвалыйлар.

Инде изгелек, миһербанлык төшенчәләреннән конкрет саннарга килик. Әйткәнемчә, ел әйләнәсе үзәктән кеше өзелми. Ә димәк, аларны дүрт-биш тапкыр ашатырга, аерым белгечләргә хезмәт хакы түләргә, төрле экскурсияләр оештырырга акча кирәк. «Ярдәм» фонды унбиш ел эчендә бары хәйриячеләр акчасына гына яшәгән. Дөрес, фонд үзе дә азмы-күпме эшләргә тырыша. Мисал өчен «Ярдәм» мәчете бинасы белән янәшә никах залы хезмәт күрсәтә, биредә ашау-эчү, кәләш күлмәкләре сату – барысы да каралган. Тагын аерым типографияләре бар. Моннан шулай ук «акмаса да тама» дигәндәй. Ел әйләнәсе авыруларны укыту, яшәтү, дәвалау өчен якынча 3 миллион сум акча кирәк икән. Көндәлек кирәк-яракларны каплау турында сүз бара. Аннан тыш, компьютер, башка кирәк-яраклардан торган техник базаны яңартып торырга кирәк бит. Ниһаять, дип әйтергә кирәктер, «Ярдәм» милли ислам хәйрия фонды җиңел сулап куйган: Россия Президентының граждан җәмгыятен үстерүгә юнәлтелгән грантына ия булганнар. Суммасы – 10 миллион сум. Татарстаннан тәкъдим ителгән 58 проект арасында җиңеп чыкканнар.

– Мондый зур күләмле грантка беренче тапкыр ия булдык, – диде Мәликә ханым. – Дөресен әйтим, Президент грантын алу бер дә җиңел түгел. Берничә ел рәттән гариза биреп карадык. План-проектларыбызны тәфсилләп язып, бик күп документ тупладык. Аллага шөкер, теләкләр кабул булды. Инде ниятләрне тормышка ашырырга кирәк.

«Йөрәк белән күрәбез һәм ишетәбез» дип аталган грант проекты бер елга каралган. Аның кысаларында 2019 елның сентябренә кадәр 5 төркем туплап, 225 кешегә белем бирү һәм тернәкләндерү курсларын оештыру күздә тотыла. Проектның максаты – күрмәүче һәм начар күрүче кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту, аларны психологик һәм медицина ярдәме белән тәэмин итү. Авыруларны җәмгыятькә җайлашырга, кешеләр белән аралашырга өйрәтү. Ә моның өчен аерым белгечләргә (табиб, юрист, психолог һ.б) мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Үзәктә көн саен Луи Брайль системасы буенча укырга өйрәнәләр.

10 миллион сум грант – күпме, азмы? Бер карасаң, шактый зур акча кебек. Тик, халык әйтмешли, ашаган белми, тураган белә. Алда әйтелгәнчә, беренчедән, 225 кешегә тернәкләндерү курслары оештырылачак. Икенчедән, дистә ел эчендә үзәкнең техник базасы нык искергән, грант акчасына шуны яңартырга уйлыйлар. Өченчедән, Казан шәһәренә баннерлар урнаштырырга ниятлиләр. Бу җәмгыятьнең үзаңын үзгәртү өчен кирәк. Кызганыч, күпләр әйләнә-тирәбездә ярдәмгә мохтаҗ кешеләр барлыгын күрми дә, белми дә. Үзәктәге берничә кешедән мондыйрак сүзләр ишеттем: «Кибеткә кергәч, без еш кына теге яки бу әйберне алып бирүләрен сорыйбыз. Ә кешеләр дорфа гына: «Болай да ашыгам» яки: «Булдыра алмагач, кибеткә йөрмә», – дип кистереп салалар. Бар, әлбәттә, юл чыгарга булышкан, кибеттә ярдәм кулы сузган миһербанлы бәндәләр дә. Ләкин алар күп түгел...»

«КАМЫР РИЗЫКЛАРЫ ПЕШЕРӘМ»

Грант акчасына тернәкләндерү узачак беренче төркем «Ярдәм» мәчетенә 1 июльдән килгән. Барлыгы 45 кеше. География киң: Самара, Иркутск, Ставрополь, Ульяновск, Киров, Оренбург, Омск өлкәләре, Пермь, Краснодар крайлары, Татарстан, Башкортостан, Мари Эл, Удмуртия, Дагыстан, Чечня республикалары. Сентябрьдә икенче төркем киләчәк. Төп шарт – грант кысаларында бер тапкыр килгән кеше инде икенче юлы тәкъдим ителергә тиеш түгел. Гади итеп әйткәндә, әлегә кадәр начар яки бөтенләй күрмәүчеләр бирегә елга ике тапкыр килгән. Хәзер алай тиеш булмаячак.

– 2019 елның сентябреннән соң гына килә алачаксыз, дип аңлаттылар безгә, – диде Ульяновск өлкәсенең Иске Кулатка районыннан килгән Рәхилә апа Мәулетова. – Мин инде монда 2014 елдан бирле йөрим. Казанга барасы бар, дип, көннәрне санап торам. Бик рәхәт биредә, әйтеп бетерә алмыйм. Луи Брайль системасы буенча Коръән укырга да өйрәндем. Һәр көн җыелышып төрле җырларга барабыз, үзем кебек күрмәүчеләр белән аралашам...

Рәхилә апага 65 яшь. Кырык ел аш-су остасы булып эшләгән. Тормыш иптәше белән ике ул үстергән. Ун ел элек гомер иткән ире йөрәк өянәгеннән үлеп киткән. Санаулы көннәрдән соң, тол хатын сукырайган.

– Минем күздә глаукома иде, – ди Рәхилә апа. – Иремне югалткач, бик күп еладым. Күрәсең, күзләремә шул ярамады. Караңгылык дөньясына ияләнә алмыйча бик озак газапландым.Ниләр кичергәнемне үзем генә беләм. Кеше белән аралашудан туктадым. Балаларга йөк булудан тагын да кыенсындым. Тик нишләмәк кирәк...

– Шөкер итәргә өйрәндем, – ди Рәхилә апа Мәулетова.

Көн саен таң ата, димәк, яшәргә кирәк. Акрынлап өй буенча тотынып йөри башладым. Чәй куярга өйрәндем, аннан җиңелчә ризыклар пешереп карадым. Бүген инде бар ризыкны әзерлим: камыр да куям, пилмән дә бөгәм, токмач та кисәм.

Рәхилә апа боларны елмаеп, зарланмыйча сөйли. Мин исә аның бу халәтенә сокланып, керфек тә какмый тыңлап торам: «Гомер буе пешекче булып эшләгәч, куллар бар эшне дә хәтерли, – ди Рәхилә апа. – Аңа күз кирәкми икән... «Ярдәм» мәчетенә килгәч, намаз укырга өйрәндем, Коръән сүрәләрен яттан беләм. Һәм бу миңа җиңеллек бирә. Авырлыкларны сынау итеп кабул итәм. Бу тормышта һәркемнең капчыгы тулы, балам».

Рәхилә апа бик фәлсәфи фикер йөртә. Караңгы дөньяда яшәүнең үз уңай якларын тапкан. (Куркыныч яңгырый, әйеме?!) «Югыйсә дингә килмәгән булыр идем. Шөкер итәргә өйрәндем», – ди. Рәхилә апа өендә тавыклар да асрый икән. Иртән чыгып кош-кортларга азык бирә, көндез күкәй җыя. Үзәктә дә тик утырмый – сәйләннән төрле бизәкләр ясый, гимнастика белән шөгыльләнә. Күзсез калып, үзенә урын тапмаган кешеләр белән сөйләшә, аларга рухи яктан булыша.

«СИКЕРӘМ, ДИП, ТӘРӘЗӘНЕ АЧТЫМ ДА...»

Үзәктә тагын берәү – Чечняның Грозный шәһәреннән килгән Шаһит Бириев белән дә сөйләшеп утырдык. Шаһит абый 50 яшендә сукыр калган. Бүген аңа 61 яшь. Шул дәвер эчендә яңадан яшәргә өйрәнгән.

– Күзнең басымы югары булган икән, мин белмәдем дә, – диде ул. – Дөресен генә әйткәндә, сау вакытта сәламәтлегемне дә, гаиләмне дә кайгыртмадым. Ничек яшисем, кая барасым килсә, шулай эшләдем. Хәзер үкенәм. Тормышны яңадан башлап булса, күп нәрсәләрне үзгәртер идем. Эгоист булганмын, дип, үземне әрлим.

Шаһит абыйга Чечняда дәүләт программасы нигезендә бер бүлмәле фатир биргәннәр. Ул бүген шунда ялгызы яши. Дөрес, хатыны, кызы килеп йөри. Ашарга әзерли, керен юа, дигәндәй.

– Сукыр калгач, бик күп уйландым, – ди әңгәмәдәшем. – Исән вакытта гаилә дип яшәмәдем. Сукырайгач исә: «Ә ни өчен алар минем белән хәзер җәфаланырга тиеш?» – дип уйладым. Өйдә кеше булмаганда, тәрәзәдән сикерергә карар кылдым. Бишенче катта яши идек. Шулвакыт искә төште: беренче катта ишекнең

– Өченче ел рәттән Ураза аенда Казанда яшәдем, – ди Шаһит абый Бириев.

өсте күтәртелеп ясалган. Әгәр шунда төшсәм, исән калырга мөмкинмен. Сукыр булу өстенә, гарип тә калсаң, якыннарыма тагын да авыр булачак. Бу яхшы ният булмады, дип, тәрәзәне яптым. Һәм өйдән чыгып киттем. Гаиләмә өстәмә бер йөк буласым килмәде.

Шаһит абый күпмедер вакыт туганнарында, әнисе янында яши. Аннан, социаль яклау бүлегенә йөри торгач, торак алу бәхетенә ирешә. Бик аралашучан үзе. Сукырайгач та, үзе кебек язмышка дучар булган кешеләр белән таныша. Берсеннән Казанда «Ярдәм» фонды оештырган үзәк турында ишетеп ала.

– Өченче ел рәттән Ураза аенда Казанда яшәдем, – ди Шаһит абый. – Беренчедән, сездә һава шартлары ураза тоту өчен уңайлырак. Икенчедән, сәхәр, ифтарга ризык әзерләнгән була. Мөселманнар белән бергә ураза тоту күпкә җиңелрәк.

– Грозный шәһәрендә күрмәүчеләргә карата җәмгыять нинди караштa? – дим.

– Бик яхшы, һәрвакыт ярдәм итәргә торалар. Хәер, Казанда да бары уңай мөнәсәбәт кенә тоям. Әмма «Ярдәм» мәчете кебек үзәкләр бездә юк. Шуңа да монда килергә гел ашкынып торам. Юл бәяләрен дә үзәк үзе түли, бик уңайлы. Ай буе яшәп, физик яктан да, рухи яктан да сәламәтләнеп кайтып китәм. Безгә шундый шартлар тудырган җитәкчеләргә бик зур рәхмәт әйтәсем килә.

...Коридор буйлап стенага тотынып күрмәүчеләр килә. Алар хәлен аңлар өчен нибары бер минутка күзне йомып карау да җитә... Куркыныч бит. Кемдер гомере буе шул караңгылыкта яшәргә мәҗбүр. Әле ярый тормышларына аз булса да нур өстәүчеләр бар. Караңгылыкта япа-ялгыз калсаң, нишләмәк кирәк?!

Президент грантының максаты – сукыраеп, күңел төшенкелегенә бирелгән ир-атлар, хатын-кызларга ярдәм итү. Тәҗрибәдән күренгәнчә, мондый үзәктә алар тормышка тизрәк җайлаша икән. Иртән җыелып, бергә намаз укыйлар, аннан күнегүләр ясарга урамга – спорт мәйданына чыгалар. Ашап-эчкәннән соң, аерым классларга таралалар. Кемдер – массаж бүлмәсенә, кемдер – компьютер классына. Аннан янә намазга җыелалар, төшке, кичке ашларга... Һәр минутлары бүленгән.

Шуңа аптырадым: «Ярдәм» фонды оештырган үзәктә яшәүчеләрнең ник берсе зарланып карасын! Һәркайсы үз фаҗигасен күкләр биргән сынау итеп кабул итә. Ә бит аларның күбесеннән туганнары, якыннары баш тарткан. Тик алар бу хакта берәүгә дә сөйләргә яратмый. Якыннарын да гаепләми. Караңгы тормышларын яктыртып, үзләрендә яшәргә көч табалар.

«Ярдәм» милли ислам хәйрия фондының соңгы 10 ел эчендәге эшчәнлеге – саннарда:

- 221 миллион сум иганәчелек эшләренә тотылган;
- 180 миллион сум мәчет һәм башка оешмаларга бирелгән;
- мөмкинлеге чикле 14 мең 500 кеше ярдәм алган;
- мөмкинлеге чикле кешеләр өчен 6 тернәкләндерү үзәге шефлыкка алынган;
- 45 күрмәүче Хаҗга җибәрелгән;
- Брайль системасы буенча 1 мең китап, 2 мең аудиокитап чыгарылган;
- 197 мең кешегә ризыклата ярдәм күрсәтелгән;
- Рамазан аенда 135 мең кешегә сәхәр, ифтар ашы үткәрелгән;
- Корбан бәйрәмендә 62 мең кешегә ит бирелгән;
- 20 мең кеше укытылган;
- 4600 кешегә Ислам кануннары өйрәтелгән, 750 кеше Коръәнне ятлаган, 8 хафиз (Коръәнне яттан белүче) әзерләнгән;
- 1080 бала мөселман лагерьларына йөргән;
- 150 кеше булачак ата-аналар курсларын тәмамлаган;
- авыр тормыш хәлендә калган 3 мең кешегә ярдәм күрсәтелгән;
- аз керемле 2 мең гаилә даими рәвештә ярдәм алган һәм ала (кием-салым, азык-төлек);
- аз керемле 18 ялгыз анага (балалар саны 4тән 8 гә кадәр) торак бирелгән;
- 120 наркоман тернәкләндерү узган;
- Татарстан төрмәләрендәге 600 тоткынга даими рәвештә азык-төлек җибәрелә һ.б.

КАМИЛЛӘШТЕРЕЛГӘН
КЛАССИКА

Июль башында Казан авиация заводы «КАПО-Композит» үзенең биш еллык юбилеен билгеләп үтте. Бу Берләштерелгән композит юнәлешле авиатөзелеш корпорациясенең беренче компетенцияләр үзәге, ул 2013 елда МС-21 проектына кушылды. Нәкъ менә Казан заводы мәйданында яңа һава судносы өчен полимер композицион материаллардан панельләр һәм башка комплектлаучы әйберләр җитештерелә, монда механизация һәм идарә итү элементларын (закрылкаларны, һава тормозларын, интерцепторларны, биеклек рульләрен дә кертеп) әзерләү һәм җыю да керә. Бер уйласаң, биш ел – әллә ни озак вакыт та түгел, әмма предприятие белгечләре беренче киң күләмле нәтиҗәләрен ясый ала инде. Яңа МС-21-300 самолёты, беренче очышын ясап, очыш сынаулары программасын дәвам итәр өчен Иркутскидан Жуковскийга (Мәскәү өлкәсе) очып өлгерүгә, инде икенче очу борты биеклекне уңышлы үзләштерә.

«КАПО-Композит» заводы – уникаль мәйдан. Югары технологияле җиһазлар һәм җитештерү процессына махсус таләпләр куелган заманча җитештерү 3 гектар мәйданда урнашкан.

Проектның башлангыч этабында җитештерү үзенчәлеге булып классик автоклав технология торган. Әмма эшләрне алга алып барган саен, завод белгечләре бер урында гына торып калмаган һәм «классик ысул»ны тагын да камилләштергән.

Алексей Слободинский, КАПО-Композит» АҖ генераль директоры:

– Безнең белгечләр процессны камилләштерә алдылар. Хәзерге вакытта безнең заводта композит эшләнмәне әзерләү ике технологик цикл эчендә башкарыла, әлеге технологияне кулланучы башка предприятиеләрдә исә – өч циклда. Бу безгә продукция җитештергәндә сизелерлек дәрәҗәдә экономиягә ирешергә мөмкинлек бирә.

Эшләнмәне чыгару процессы заманча җитештерүнең үзәгендә – «чиста бүлмә» эчендә башкарыла. Аның үзенчәлеге нидә соң? Барыннан да элек, сыйфатлы продукт әзерләргә мөмкин булган аерым шартларда. Бу төп углерод материалы – препрегның яшәү эшчәнлеге өчен уңайлы шартлары дигән сүз. Аның белән эшләү «адекват» характерга ия булырга тиеш. Температура режимы сикергәндә, материал яки ябышкакка әверелә, яки ул гомумән ябышмый башлый. Аның эластик халәтен саклар өчен оптималь коридор булдырырга кирәк. Параметрлар физик юл белән, приборлар ярдәмендә дә, автоматлаштырылган җиһазлар кулланып та контрольдә тотыла. Белгечләрнең махсус киеме һәм мәйданны күп тапкырлар җыештырып тору дисперслы кисәкчекләр, тузан эләгүне булдырмаска мөмкинлек бирә.

Бу таләпләр белән исәпләшмәү миллион сумнар торган эшләнмәне бракка чыгарырга мөмкин.

Детальне формалаштырганнан соң, килеп чыккан әзерләмә технологик материаллар һәм вакуумлы капчык белән каплана, аннан соң автоклавта термик эшкәртү үткәрелә.

Алексей Слободинский, КАПО-Композит» АҖ генераль директоры:

– Без үзебез куллана торган технологияләрнең һәм технологик культурага карата булган мөнәсәбәтебезнең бары тик камилләшергә һәм алга барырга гына мөмкинлек бирәчәгенә өметләнәбез. Безне алга таба серияләп җитештерү көтә. Бүгенге көнебезгә без ышаныч белән карыйбыз һәм «без әзер!» дибез.

Хәзер заводта Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе өчен дә, шулай ук башка оешмалар өчен дә шактый санда яңа эшләнмәләр җитештерү тәртипкә салынган.

Фотоны «КАПО-Композит» АҖ матбугат хезмәте тәкъдим итте.

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76

Махсус проектлар бүлеге:

тел: (843) 222-06-05

Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Туп артыннан безгә **КЕМНӘР** килде

Кура җиләгеннән **НӘРСӘЛӘР** пешерергә була

Федераль Сабантуй **КАЙДА** үтте

ТУП АРТЫННАН **КИЛГӘННӘР**

Берсеннән-берсе зур спорт ярышларын уздыру тәҗрибәсе Татарстан башкаласы өчен инде гадәти күренешкә әверелеп килә иде, югыйсә. Ләкин футбол буенча дөнья чемпионаты көннәрендә шәһәр урамнарындагы гаҗәеп тамаша шәһәребезгә беренче килүчеләр өчен дә, казанлыларның үзләренә дә яңалык булды.



Автор:
Ксения Сёмина

«Бу кәеф күтәренкелеген озак-карак сузасы килә», – җанатарларның Казан Кремленә сәяхәт кылуларына шаһит булган музей-тыюлык директоры Зилә Вәлиева әнә шулай диде. Бәхеткә, бу җәһәттән Инстаграм – чып-чын вакыт машинасы, ул тылсымлы мизгелләрне теләсә кайчан кире кайтарырга сәләтле.

КРЕМЛЬ СЕЛФИЛАРЫ

«Әгәр бу татлы төш булса, минем уянасым килми», – Кол Шәриф мәчете фонында Россия флагын тотып төшкән Бразилия җанатары фото астына әнә шундый сүзләр язып куйган. Тайницкая манарасы янында бихисап халык белән төшкән фотосына исә бер Казан кызы мондый ачыклама биргән: «Һиндстан, Мексика һәм Кытай Россиядә очрашканда». «Казан – Россиянең милли-дини мәдәният төрлелеге белән тулы мөһим тарихи-мәдәни үзәге», – дип хәбәр сала Кытай кунагы. Ул Кремльнең ап-ак диварлары, ямь-яшел үләннәре һәм бу көннәрдә суперпопуляр «KAZAN» хәрефләре фонында басып төшкән.

Ә Германия һәм Корея җыелма командалары матчы узган көндә Кремль Вьетнам туристлары белән тулган иде.

– Без Германия командасына көч биреп торырга телибез. Гомумән, безгә ике команда да ошый, ләкин шулай да Германиянең җиңүгә мөмкинлекләре күбрәк, дип сөйли Вьетнам кызы Мин Эн. Алар матчны карар өчен гаиләләре белән Ханойдан ук килгән.

– Мин Мәскәүдә яшим. Казанга беренче тапкыр килүем. Дустым белән бүгенге уенга барырга җыенабыз. Монда бик-бик шәп, тик эссе. Нәрсәне аеруча ошаттыкмы? Әлбәттә, Кремльне. Шундый матур бит! – дип сөйли Хи Ен исемле егет.

Милли символикалы кызыл футболкалар кигән вьетнам дусларның тагын бер төркемен Кремль янында очраттым.

– Күбебез Россиядә, Кировта эшли. Моннан ерак түгел ул. Кечкенә генә җанатар клубыбыз бар. Казанда без беренче тапкыр гына, килгәнебезгә сөенеп туя алмыйбыз! – дип барган шәпкә сөйләп алды бу төркемдәге бер егет. Фотога төшерер өчен аны чак туктатып тора алдым. Саубуллашканда, алтын йолдыз төшерелгән кызыл әләмнәрен болгап алдылар.

ҖАНАТАР ҖАВАБЫ

«Яңарыш» фондының башкарма директоры Татьяна Ларионова әйтүенчә, чемпионат старт алган

Фото: Александр Ефремов

көннән июль башына кадәр Зөя утрау-каласына 17 мең турист килгән (ягъни Казан Кремленә килүчеләр санының якынча уннан бер өлеше). 24 июньдә Колумбия белән Польша командалары арасында узган матчка бер көн кала утрау-калада ике команда җанатарларын да очратырга була иде, ди ул. Утрау рухы күңел түренә үтеп, тәмам биләп алганмы, алар монда үзләрен Казандагыдан күпкә тынычрак тотканнар, имеш. Ә бәлки, матч алдыннан көчне юкка-барга сарыф итмик, дигәннәрдер. Константин һәм Елена чиркәвендә өч егет, бер кызның шәм куеп йола үтәвен күзәтә-күзәтә, басынкы гына тавыш белән икона турында гәп куерта иде. Барысы да урамга чыккач, бу өч дусның кайсы ил вәкилләре булуы белән кызыксынырга җөрьәт иттем. Кичә иртән Варшава белән Краковтан килгәннәр икән.



– Кайларга барырга өлгердегез инде?

Михаил, Лукас һәм Павелның инде Зәңгәр күлгә барып кайтырга җитешкәнен белдек. Туристлык порталы һәм шәһәр волонтерлары киңәшен тыңлап, алар шунда юл тоткан. Менә ул – гадәти булмаган туристлык маршрутлары чыганагы.

Кунакларның милли ризыклардан ни дә булса татып караганмы, юкмы икәнен ачыкларга маташтым.

– Әйтик, өчпочмак ашадыгызмы? Ул шундый итле, бәрәңгеле сумса кебегрәк.

– Ә-ә-ә... Әйе, иртәнге ашны ашаганда шулар белән сыйланган идек. Тик без аның милли ризык икәнен белмәдек тә, – дип, барысы өчен дә җавап бирде Михаил. Гомумән алганда, Польша кунаклары һәрнәрсәне ошаткан.

– Сездә хәтта таксистлар да бик «фрэндли», – диде Лукас.

Поляк җанатарлары бәйрәм кәефле Казан һәм карнавал рухлы колумбиялеләр каршында бурычлы булып калмады. Матч башланыр алдыннан, поляклар гөрләп-җырлап торган төз колоннага тезелделәр дә, Бауман урамы буйлап марш атладылар. Явызлык дигәннең әсәре дә юк, бар тирә-якны күмеп киткән соклану һәм энергия генә...

РОССИЯНЕ КҮРСӘТЕРГӘ...

«Мине Татарстан тарихына сәяхәткә алганыгыз өчен рәхмәт!» – дип язып калдырды Татарстан Милли музееның кунаклар китабында япон принцессасы Хисако Такамадо. Япония милли футбол ассоциациясе рәисе сыйфатында принцесса үз иленең җыелма командасы катнашкан барлык чемпионатларга да килә. Саранскида Колумбиягә каршы уенда Япония командасы өчен җан атканнан соң, хөрмәтле кунак Казанга юл тотты. Чемпионат вакытында японнарның төп әзерлек базасы итеп Татарстан сайланган иде. Тарих һәм мәдәният – принцессаның төп кызыксынуларыннан икән. Казанда ул үзенең бу шөгыленә тулы ирек бирде: Кремльдә һәм Милли музейда галиҗәнап кунакның сокланулы карашы төшмәгән бер экспонат та калмагандыр, ахры. Ислам мәдәнияте музеендагы экспонат – Коръәннең 1934 елда Токиода дөнья күргән Казан басмасы (Япониядә тулысынча оригинал телдә басылган тәүге Коръән) аны аеруча тәэсирләндерде. Милли музейда япон

принцессасының экскурсия маршруты 3,5 км дан артып китте. Ул татарларның чәй эчү йоласыннан, кырпы балыгы карачкысыннан һәм шулай ук «Казан Арена» стадионы макетыннан биһуш калды.

Сүз уңаеннан, Милли музей принцессаны гына түгел, ә татар йолалары белән якыннан танышырга теләгән һәркемне чәй белән сыйлады. Җанатарларның футбол тонендә монда лекцияләр һәм осталык дәресләреннән алып, җирле «Минхаузен» төркеменең каверпрограммасына кадәр – һәрнәрсә бар иде.

– Боларны ничек ошатмаска була? – дип белдерә Әстерханнан килгән Сабир, казанлылар башкаруында Карлос Сантананың популяр җырына ут яндырып биегәннән соң, бераз гына тын алгач. Музейда оныгы белән берничә сәгать уздырган ул. Әле тагын да озаккарак калган булырлар иде, тик программа тәмамланган.

Иранлылар, колумбиялеләр һәм инде эңгер-меңгер аркасында каян икәнен чамалап та булмаган башка җанатарлар белән тулы Кремль тирәсендәге мәйданга киң колачлы ишарә ясап:

– Болар барысы да Россияне танытыр өчен, – ди Сабир, – гел колакчынлы бүрек, киез итек киеп йөрмәгәнлегебезне, безнең аю түгел икәнне күрсәтер өчен кирәк. 90 нчы елларда булганнар белән хәзерге заман – җир белән күк аермасы ул...

БАШКА ИЛ

Сүз уңаеннан, җир белән күк турында. Дөресрәге, су хакында. Утыз градуслы эсседә Казандагы елга-күл яр буйлары искиткеч популяр урынга әйләнде. Күптән түгел генә хайтек стилендә яңартылган Кабан күле яр буе әле яшел, әле сары, әле зәңгәр, әле кызыл төсләргә чумды.

– Миңа монда Мәскәүгә караганда да күбрәк ошый, – ди поляк Томаш. – Анда тавыш, пычрак томан, 17 миллион халык... Бу бик күп. Ә монда матур, иркен – сулыклар, чәчәкләр күп, яшьләр бихисап, мөлаем, яшәү көче балкып торган йөзләргә карарга да рәхәт...

– Без инде ике көн монда. Күзебезгә ташланган иң беренче нәрсә – һәркемнең якты йөзле булуы, кунакчыллыгы. Кешеләрнең үзара хәбәрләшеп эш итүе күренә. Без Россиядә 5 ел элек



тә булдык, бу бөтенләй башка ил иде, – дип сөйли колумбияле Кейла. Аны фотога төшерергә җыенганда, яныбызга бер өер Колумбия җанатары килә. Аннары казанлылар җыела... Шунысы сәер – төрледән-төрле йөзләрдән гыйбарәт бу зур төркемдә һәркем бәхетле.

– Казан – матур, заманча шәһәр. Бик яшел, бик чиста, – дип сөйли миңа Чай Минг Да исемле кытай егете. Кытайның иң борынгы (3 мең ел элек салынган) калаларыннан берсе – Сианьнән ул. – Бездә дә кайбер үсемлекләр культ дәрәҗәсендә үстерелә, мәсәлән, бамбук – кешенең авырлыкларны җиңәргә һәм тормышны дәвам итәргә омтылышы символы.

– Мин Россия буйлап күп йөрим, бу илдә сәяхәт кылу миңа ошый. Шәһәрләрегез һәркайсы шундый төрле, һәркем үз зәвыгына туры килгәнен таба ала: Калифорния кебек җылы Сочи; гел нидер булып торган, эшлекле, өлгер Мәскәү; музейлы, гаҗәеп архитектуралы Санкт-Петербург; матур, ямьле Казан, – дип сөйли Мануэль Фет, Канададагы Викториядән килгән спорт журналисты. – Казанга инде бишенчеме-алтынчымы килүем. Монда гел эшләргә туры килә диярлек, әмма шәһәр гизеп йөрү миңа бик ошый. Казансу елгасының яр буйларын үз итәм. Паркыгыз ошый. Теге, мөселман паркы, тәмле ризыклар сатыла торган...

Мин аптырап калам. Мануэль, тиз арада «гугл»га кереп, миңа... Горький исемендәге паркны күрсәтә. Аннары Бразилия җанатарлары төркеменә ымлый:

– Аларга ялгышканнарын әйтегез әле. Командалары бүген Мәскәүдә уйный бит...



– Без билетларга бронь ясаганда, команданың кайда уйнаячагы билгеле түгел иде әле. Шулай итеп Казанга килеп чыктык. **Ләкин без Корея белән Германия җыелма командалары арасындагы матчны да бик рәхәтләнеп, бик теләп караячакбыз, ә иртәгә Сочига юл тотабыз... – ди Марселу. Ул 11 ел Мәскәүдә яшәгән һәм дуслары Майкл белән Луисны мундиальга барырга күндергән.** Хәзер исә алар, иртәме-соңмы үз җыелма командаларының матчына туры килү өмете белән, чемпионат уза торган шәһәрләрнең берсеннән-берсенә күчеп йөриләр. Һәм шуннан бик зур канәгатьлек алалар...

ҖАНАТАР ЙӨРӘГЕНӘ ЮЛ – АШКАЗАНЫ АША

Футбол белән янып йөргән арада Казан кунаклары милли ризыклар белән танышырга да онытмады – Татарстанның туризм буенча дәүләт комитеты белдергәнчә, чемпионатның 20 көнендә 20 меңнән артык өчпочмак ашалган...

Германиянең Кассель шәһәреннән килгән өлкән яшьтәге пар – Биргитта белән Михаллекны тимер юл вокзалы янындагы җәяүлеләр кичүендә очраттым.

– Без иртәгә Мәскәүгә, Испания белән Россия матчына китәбез. Испаниянең командасы шәп, ләкин руслар бик көчле уен күрсәтте. Соңгы ике матчны карагач, гаҗәпкә калдым, – дип аңлата Михаллек. Без ашыкмый гына шәһәр үзегенә таба атлыйбыз – немецлар Бауман урамына ничек барырга күрсәтүемне үтенде. – Мин – «Вольфсбург» клубы фанаты. Берничә ел элек Казан

стадионында «Рубин» белән Вольфсбург» арасында уен узды... Шундый кызыклы хатирәләр... Биргитта җанатар түгел, әмма аның Казанны бик күрәсе килде.

Юл уңаенда мин Казан тарихында Кремльнең мөһим роле турында сөйлим. Немецлар баш селкеп тыңлап бара. Биргиттаның зәңгәрле-аклы язулар



белән янып торган супермаркетка күзе төшә.

– Монда милли камыр ризыклары сатып алырга мөмкин, – дип уйламыйчарак әйтеп ташлавым булды, немецлар шунда ук диярлек минем белән саубуллашу ягын карады.

– Без маринадланган гөмбә, кыяр һәм башка яшелчәләрне ашап карадык, – дип сөйләде миңа соңрак колумбияле Джениффер. Алар ире һәм ахирәтләре белән дус кызыма тукталганнар иде. Дустым әлеге зур компанияне Казан буйлап көне буе йөрткән дә, кичләре төн уртасына кадәр сузылган шау-шулы мәҗлес белән ялганып киткән.

– Һич онытылмаслык булды ул! – дип ярып сала, хисләргә бирелеп, Джениффер. Аның ягыннан кемдер тавышланмыйчарак сөйләшүебезне үтенде кебек.

– Юк әле, милли ризыкларны татып карарга өлгермәдем, – ди Бангладеш башкаласы Даккадан килгән Дейб. Мин аны чемпионатның IT-паркта урнашкан Казан матбугат үзәгендә очраттым. Дейб һич тик тормый: биш минут эчендә ул хезмәттәшләремнән Бельгия белән Бразилия арасындагы матчка фаразлары турында (әлбәттә, барысы да Бразилияне мактый) өч әңгәмә алырга, берике бөккән белән тамак ялгарга өлгерә. Шул арада Казаннан бер хезмәттәшенең киңәше белән кулына агач кашыклар тотарга да онытмый. Бу кашыклар исә Татарстан фольклор музыкасы ансамбле артистлары чыгышына әзерләп куелган иде.

– Менә бу супер! – ди Дейб, кашыкларны шакылдатып.

ЭПИЛОГ УРЫНЫНА

«Мондый нәрсә башка кабатланмаячак!» – дип яза Россия халкы социаль челтәрләрдә. Төрле телләрдә сөйләшә торган, төрле мәдәният вәкилләре булган меңләгән кеше илебез киңлекләрендә ай буе шатланды, кайгырды, көлде һәм елады. Әлеге хистойгылар ташкынын таратып, бер-берсе белән дә уртаклашты. Казанга бәхет елмайды: иң мавыктыргыч, иң шәп уеннарның күбесе безнең стадионда узды. Ә никадәр яңа футбол җанатары барлыкка килде – тирә-якта һәрнәрсә бары тик футбол белән генә яши кебек тоелганда, ничек инде бу чирне йоктырмыйсың, ди. Россия җыелма командасы уйнаган көннәрдә Казан «Фанфесты» (Fifa FanFest) шыгрым тула иде: футболчыларыбыз узган лаеклы юлда без алар өчен ут йотып тордык... Башка ил кунаклары да безнең белән бергә Россия командасы өчен җан атты. Болар барысы да могҗиза, балачак иленнән килгән матур бәйрәм кебек тоела иде! Ләкин вакыйганың икенче ягы да бар. Кешеләр соңгы ике елдагы үзгәрешләрне артык югары бәяләп, ун еллыкта булган үзгәрешләрне тиешенчә күреп бетерми, дип әйткән кайчандыр Билл Гейтс. Менә шулай, соңгы ун елда без бик үзгәрдек. Чемпионат безгә үзебезнең яңа халәтебезгә бөтен дөнья күзләре белән карарга мөмкинлек бирде... Баксаң, без искиткеч матур да, күтәренке күңелле дә, кунакчыл, дустанә дә икәнбез лабаса – карап-карап тордык та ошаттык бу күренешне! Менә монысы инде – чын җиңү!

Реклама 16+

Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная
Кухня

КУРАДАН ҖӘЙГЕ ПИРОГ

«Эх, җиләкле җәйләре» дип җырлыйбыз. Чынлап та, җәй ул яңа чабылган печән, хуш исле чәчәкләр һәм кып-кызыл булып тулышып пешкән җиләкләре белән күз алдына килә. Каен җиләгенең вакыты инде узды, җир җиләгенең дә ваклары гына калды. Ә менә урманда кура җиләгенең нәкъ өлгергән чоры. Шуңа да бу санда әлеге татлы нигъмәттән пирог ясарга булдык.

Автор:
Руфия Фазылова

«ШАЙТАНЛЫ»ГА – КУРАГА

Кура җиләге бөтен җирдә дә үсми. Нигездә, ул катнаш урманнарда була. Кура җиләге кояш, яктылык ярата. Урманда агачларны кисеп, аланлык пәйда булды исә, санаулы еллар эчендә анда куралык барлыкка килә. Хәтерлим, кечкенә чакта урманга баргач, кояш нурлары төшкән ачык урын эзләп йөри идек. Яктылык күрәсең икән, димәк, анда кура җиләге бар. Апас районы Олы Бакырчы авылында чын җиләкчеләр гаиләсе яши – Кәлимуллиннар. Мәхмүт абый белән Рузалия апа өч бала тәрбияләп үстерде. Кайчан карасаң да, урманда алар: җиләк, печән, гөмбә, чикләвек җыялар. Мәхмүт абыйның «Урал» машинасы арбасына «төялеп», без, бер көтү бала-чага да, өлкәннәргә ияреп урманга барабыз. (Безнең якта кура җиләгенә «Шайтанлы» урманына йөриләр). Көтү кайтып, сыерлар савылгач яки таң белән, иртәнге дүрт-бишләрдә була торган иде ул. Мәхмүт абый машинасын гадәттә иң җиләкле урынга алып керә, чөнки еш кына утын кисеп ташыганга, урманны яхшы белә. Арбадан коелып төшәбез дә таралышабыз. Алай да олылардан читкә китмисең – адашуың бар. Ара-тирә үзара тавыш бирешеп тә алабыз: «Аууу! Сез мондамы?»

РУЗАЛИЯ КӘЛИМУЛЛИНАДАН ҖИЛӘКЛЕ ПИРОГ РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак:
1. Сөт – 1 литр
2. Йомырка – 5 данә
3. Шикәр комы – 1 стакан
4. Сыек май – 1 стакан
5. Он – 1 кг
6. Юеш чүпрә – 50 г
7. Тоз – тәменчә

Эчлек:
1. Кура җиләге – 0,5 кг
2. Шикәр комы – 0,5 стакан

Фото: Айгөл Абдрахманова

Редакция кухнясы

Эилек

1. Изәбез!

2. Салабыз!

Җиләк җыюның тагын бер кагыйдәсе бар: кеше бер куаклык таптап киткән икән, син инде аның янына бара алмыйсың. Чөнки аны ул тапкан. Әле остарак, батыррак җиләкчеләр, мул уңышка тап булса, чиләк тутырмыйча, шул урыннан чыкмый да. Хәзер уйлыйм: безне, балаларны, ничек елан чакмаган икән? Ә бит олылар кара еланга тап булгалыйлар иде.

Рузалия апа белән күңел түрендәге әнә шул хатирәләрне яңарттык.

– Яшьлек, – ди Рузалия апа. – Уртанчы кызыбыз Рузиләгә алты ай гына, юрганга төрәм дә «Урал»га чыгып утырам. Бөтен урам җиләк җыйганда минем генә өйдә утырасы килми бит. Олы кызыбыз Раиләгә җиде тулмаган. Аны Рузилә янында калдырабыз да җиләк җыярга кереп китәбез. Сеңлесе уянгач, Раилә урманны яңгыратып кычкыра: «Әни, кил, бәби елый...» Йөгереп барам да баланы имезәм. Азрак селкеткәч, Рузиләбез яңадан йокыга китә. Мин тагын җиләк җыям. Ул елларда утыз өчәр литр кайнатма ясый торган идем.

Хәзер авылда элеккеге кебек кура җиләге җыймыйбыз инде. Күпләрнең бакчасында үсә ул. Аннан утыз өчәр литр кайнатманы да ашаучы юк хәзер.

КАМЫРЫҢ «ТАВЫШЛАНСЫН»!

Рузалия апа шәп җиләкче генә түгел, авылның камыр пешерү остасы да. Ашлар, мәҗлесләр үткәргәндә, табын әзерләргә еш чакыралар аны. «Татарстан» журналы өчен кура җиләге пирогы пешерергә булды. «Кайнатма, желе да ясый алам», – дигән иде, тик камыр пешерү остасыннан пирог әзерләтәсе килде.

– Нигездә бөтен камырның үз рецепты бер инде, – ди Рузалия апа. – Сөт, йомырка, май, тоз, шикәр комы, кайвакыт каймак өстибез. Нәрсә пешерүеңә карап. Аерма камырга салынасы ризыкларның күләмендә генә. Мисал өчен, юка камырына ярты литр сөт, ярты литр су, каймак салам. Ә пирогны сөткә генә ясыйм. Камыр алай йомшак була.

Рузалия апа башта йомыркаларны туглады. Күбек халәтенә килгәч, өстенә шикәр комы, тоз салды. Алар эрегәч, кәстрүлгә җылы сөт агызды. Шуннан чүпрә өстәде. Һәм барысын бергә яхшылап болгатты. Янә он салып, йомшак кына итеп камыр басты. Аннан сыек май салды һәм басуын дәвам итте.

– Камыр әзер булгач, бармак арасыннан «тавыш» чыгара башлый, – ди Рузалия апа. – «Тавышлана» башлады, булды, ахры. Мәрхүм кайнанам да аш-су остасы иде. «Арка тирләп чыгып, кулның хәле беткәнче басылган камыр уңа», – дип әйтүе хәтердә.

Рузалия апа камырны, төреп, җылы урынга куйды:

– Юеш чүпрә белән кырык минутта кабара ул. Мин күптән коры чүпрә кулланмыйм, – диде.

Ул арада аш-су остасы җиләкләрне әзерләргә кереште.

– Быел җиләккә бардык, – ди Рузалия апа. – Каен җиләге бик файдалы бит, аны җыймыйча калмыйбыз. Җир җиләген дә туңдыргычка катырып куйдым. Ә кура җиләге ал бакчада күп. Мәрхүм кайнатам утыртып калдырган иде, аның истәлеге. Уңышы мул була, ремонтант төре дә бар. Ул көзен дә җиләк бирә. Корыган ботакларны гына кисеп торабыз. Кура җиләге бик талымлы куак түгел, яктылык җитсә, теләсә кайда үсә ала. Кар көрте кышын ботакларын сындырмасын дип, көзен куакларны бәйләп куябыз.

«КАЙНАНАМА РӘХМӘТ!»

Рузалия апа Олы Бакырчыга килен булып килгәнгә 27 ел вакыт узган. Күрше Кызыл Тау авылы кызы ул. 21 яшендә кияүгә чыккан. Ишле гаиләгә, төп йортка килен булып төшү бүген ничектер гаҗәп тоела. Ул заманда кияүгә чыгып килен булып төшсәң, димәк, син иртән торып сыерын да савасың, көтүен дә куасың, басуда гектар ярым чөгендерен дә кәтмәнлисең, кул белән керен дә юасың, йорт тулы халыкка ризык та әзерлисең...

– Яшь тә булгансың бит, Рузалия апа, шулкадәр эштән курыкмадыңмы? – дим.

– Ул вакытта бу гадәти күренеш иде, – ди әңгәмәдәшем. – Олы Бакырчыга килен булып төшкәндә, авылда утызлап яшь гаилә бар иде. Барыбыз да бер чорда өйләнештек. Күбесе читтән килгән киленнәр, кайнана, кайната белән яшәдек. Җигелеп тормыш тарттык. Шулай тиеш кебек булган инде ул.

– Бар эшне дә белә идеңме? – дим.

– Мал-туар карау, бакча эшләрен белә идем. Ә менә камыр пешерү, банкалар ябу кебек хезмәтләрне белми идем. Без гаиләдә дүрт кыз, бер малай үстек. Мин иң кечесе. Апалар булгач, әни мине камыр эшләренә кушмаган, күрәсең. Ә тормыш барысына да өйрәтә ул. Кайнанама рәхмәт, бик ипле, тыныч холыклы иде. Камыр ризыклары пешерергә ул өйрәтте. Кызганыч, өч ел гына бергә яшәп калдык, дөнья куйды.

Ә менә кайнатасы белән Рузалия апа 18 ел яшәде. Вәли абый соңгы елларда урын өстендә булды, яшь бала урынына җилкәсендә күтәреп йөртте ул бабайны.

– Мәхмүтнең апалары: «Әтине үзебезгә алып китеп торыйк», – дигәннәр иде, бирмәдем, – ди Рузалия апа. – Картлык көнендә үз нигезендә яшәсен дидек. Мәхмүт тә: «Мин төпчек малай, төп нигездә яшибез, үзебез карыйбыз», – диде. Әле ярый караганбыз, дим. Балаларга үрнәк күрсәттек. Яшь чакта уйламыйсың гына. Картлык ул барыбызга да килә...

Карау дигәннән, Рузалия апа үз әнисен дә тәрбияләп соңгы юлга озатты.

«МУЛЛА БЕЛӘГЕ» – НИ УЛ?!

Рузалия апа кура җиләкләрен блендер белән болгатты.

– Бер пирогны катлы итеп ясарбыз, – диде. – Ә гадәттә мин кура җиләген камырга тезеп кенә чыгам, изеп тормыйм. Өстенә азрак шикәр комы сибеп җибәрәм дә, булды.

Рузалия апаның миче дә бар. Ул аны махсус юка, кабартма пешерү өчен калдырган. Бәйрәмнәрдә мич коймагы да пешерә. Тик пирогны ул газ мичендә генә әзерләде.

– Җәй көне бик мич ягып булмыйбыз, өй эсселәнә, – ди.

Камыр тиз кабарды.

– Моннан дүрт пирог чыга, – диде Рузалия апа. – Бер төрле генә ризык ясарга яратмыйм. Шуның өчен, мәк сибеп, «мулла беләге» дә ясармын...

«Мулла беләге» дигән ризык аерым якларда гына бар. Шуңа да аңлатып китәргә кирәктер: камырдан түгәрәк җәймә җәелә. Шуның өстенә коры корт, мәк яисә эремчек салып, түгәрәкләп баралар. Рулет инде ул, тик татарча. «Мулла белә-

ген» табага тезеп куялар. Ябышмас өчен, араларын майлыйлар.

– Тик кура җиләгеннән «мулла беләге» әзерләп булмас, агып чыгар ул, – ди Рузалия апа.

Хуҗабикә камырларны табактан алгач, һәр пирог өчен аерып куеп, җәймә өстенә тезә икән.

– Кабартмаларны да шулай бер ун минут күпертеп тотам, – диде Рузалия апа.

Һәм газ мичен җылытырга куйды.

– Мич ашларын еш пешерәсеңме? – дим.

– Дөресен генә әйткәндә, хәзер сирәк пешерелә. Балалар үскәндә көн аралаш камыр куя идем. Ашалып та бетә иде. Хәзер, пешергәч, бер утырып ашыйбыз да, аннан шулай йөри. Кайнатмалар да шул килеш утыра, ашаучы юк. Элек кырыклап банка компот кына яба идем, кыш буе эчелеп бетә иде. Соңгы елларда эшне җайладым – туңдыргычка төрле-төрле җиләк-җимеш катырып куям да, шуннан алып морс ясап эчебез. Ялкаулана халык...

Ялкау сүзе Рузалия апага килешми. Дистә баш мөгезле эре терлек асраган хатын-кыз ялкау була алмый. Әле бит шулкадәр сыерны үзе генә кул белән сава да.

– Ни өчен саву аппараты алмыйсыз?-дим Рузалия апага.

– Алай күп сыер асрарбыз дип уйламаган идек. Малларны соңгы ике елда гына шулай үрчеттек. Инде моның кадәр сыер кирәкмәс тә, икесе җитәр, дибез. Ашатырга да күп кирәк, яшь тә бар бит. Ни дисәң дә, илле яшь аз түгел!

Рузалия апаның җәймәгә алып куйган түгәрәкләре тулышты. Хуҗабикә аларны алып, җәлт кенә җәймәләр җәйде. Аннан табаларга салды. Бер пирогка блендер белән болгаткан җиләк массасы агызды. Һәм өстенә манный сипте. Катлы пирог булсын өчен, җиләкне янә бер кат җәймә белән каплады, тагын җиләк массасы салды. Һәм, өстен томалап, кырыйларын бөреп куйды.

Икенче пирогны Рузалия апа җиңел генә ясады. Җәймә өстенә җиләкләр генә тезде. Каплады да, роза чәчәге ясап, газ миченә пешерергә куйды.

«БАШТА – АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ, АННАН – ИРЕМ»

Рузалия апа «мулла беләге» ясаган арада Мәхмүт абый кайтып керде. Хуҗабикәнең йөзе кояш кебек яктырды:

– Хәзер, әтисе, ашатам үзеңне, яме.

– Хатын журналга чыга дип, бүген көне буе ашамаган әле, – дип елмайды Мәхмүт абый.

– Тавык шулпасы пешердем, аша, җаныем, – ди Рузалия апа.

– Ярар, эшегезне бетерегез, соңрак керермен, – дип, Мәхмүт абый аш бүлмәсеннән чыгып китте.

– Сез бер-берегез белән һаман шаяртып сөйләшәсез, ахры? – дим Рузалия апага.

– Ирдән бик уңдым, әйтергә дә куркам. Аннан да якын беркемем дә юк. Башта – Аллаһы Тәгалә, аннан – ирем. Мәхмүт гомергә таянычым булды. Теләсә кайсы очракта мине яклады. Бер тамчы аракы эчкән, тәмәке тарткан, сүгенгән ир түгел ул. Берни юк заманнарда да сумка-сумка ризык ташыды, җәяү йөртмәде. Исән генә булсын, Ходай тигезлектән аермасын. Ул булмаса, мин беркем түгел!

Без, журналистлар, төрле гаиләләрдә булабыз. Ирләре зур дәрәҗәләргә ирешкән ханымнар: «Иремне мин кеше иттем», – дип әйтергә мөмкиннәр. Ә Рузалия апа, киресенчә, ир бәһасен күтәрә. Югыйсә кулыннан бар эш тә килүче, уңган, чиста-пөхтә, сөйкемле хатын бит. Ә бер җырлап җибәрсә, бөтен кешене авызына карата. Кая барса да, мәҗлесләрнең түрендә ул. Әмма... «Мәхмүт булмаса, мин беркем түгел», – ди.

– Рузалия апа, син үз бәяңне белеп бетермисең кебек. Әнә бит, тәрбияле, акыллы балалар үстергәнсең. Мәхмүт абый гел эштә булды, балаларның уңышларында синең өлешең күбрәк төсле, – дип, сүземне бирмәскә тырышам.

– Балалар Мәхмүттән туганга шулай булган. Ул акыллы. Кызларның башлы икәнен күреп тора идем. Рузиләбез мәктәпне дә, Казан сәүдә техникумын да гел «5» билгеләренә генә бетерде. Хәзер апасы кебек үк КХТИда белем ала. «Укыгыз, балалар. Укыган кеше югалмый ул», – дип тордым.

...Пироглар пешеп чыкты. Рузалия апа җырлый-җырлый (бу гаиләдә җырламый тормыйлар!) аларны кисеп, табынга куйды. Пироглары гадәттәгечә авызда эреп китте. Әллә кулы «тәмле», әллә күңеле якты булганга. Пирогны кайнар килеш кистек: җиләкнең сулары агып чыкты. Тик ул ризыкка аерым бер ямь өстәде – пирогыбыз кызарды, өлгергән җиләкнең нәкъ үзен хәтерләтте.

Камыр

1. Ватабыз!

2. Салабыз!

3. Өстибез!

4. Кушабыз!

5. Болгатабыз!

6. Басабыз!

7. Алабыз!

8. Җәябез!

9. Салабыз!

10. Куябыз!

11. Янә җәябез!

12. Сибәбез!

13. Ясыйбыз!

14. Майлыйбыз!

Фото: Расих Фәсхетдинов, «Татар-информ» Мәгълүмат агентлыгыннан алынды

ЧУВАШ ҖИРЕНДӘ ТАТАР БӘЙРӘМЕ

Россиянең төрле төбәкләрендә Федераль Сабантуйлар 2001 елдан бирле оештырылып килә. Әлеге бәйрәмнәрне уздыруда Татарстан Республикасының өлеше зур. Быелгы Россия күләмендәге Сабантуй Чувашия башкаласы Чебоксарда узды. Сабантуй булыр да узар, дигәндәй. Ә менә без әле тагын кайчан Чебоксарга барып, анда халыкның ничек яшәгәнен күрербез. Шуңа көн үзәгендә торган темадан читкәрәк тайпылып, аларның «искерми» торганнарына тукталырга булдым.

Автор:
Руфия Фазылова

ТАМЫРЛАРЫ – УРМАЙДА...

Чувашиядә 37 меңгә якын татар яши. Шуларның 7 меңгә якыны Чебоксар һәм Яңа Чебоксар шәһәрләрендә көн итә. Ни кызганыч, шәһәрдә татар мохите бик сизелми. Халык, шул исәптән татарлар да, нигездә, рус телендә аралаша икән. Моның төп сәбәбен болай аңлаттылар: совет заманында татарларны күпләп Чебоксар заводларына (атаклы трикотаж цехы, трактор заводы һ.б) эшкә җибәргәннәр. Тик алар, җирле халык белән аңлашыр һәм алардан әллә ни аерылып тормас өчен, рус телендә сөйләшүгә күчкән. Шул рәвешле телне генә түгел, гореф-гадәтләрне дә бик саклый алмаганнар. Биредә катнаш никахлар да күп икән. Ә татарлар башлыча Чувашиянең көньягында – Комсомол, Батыр, Яльчик, Шомырша районнарында яши. Нигездә алар күмәкләшеп утырган, зур авыллар булып урнашкан.

Чебоксарга барып, андагы милләттәшләр белән аралашканчы ук, чуваш татарларының яшәеше, гореф-гадәтләре турында яхшы гына белә идем. Әтиемнең әтисе – Назыйм Рәхмәтуллин Комсомол районының Урмай авылыннан. Яшьли ятим калып, бер әбидә тәрбияләнә ул. Язмыш кушуы булгандыр, көтү көтәргә дип, Апас районының Олы Бакырчы авылына килә. Шунда дәү әнием Хәтимә белән танышып, гаилә коралар. Апас районы Чувашиягә орынып ук тора. 1980 нче елларда ук дәү әтиебез Канашка ат арбасына утын төяп барып сата торган булган, өйгә каз, көнбагыш алып кайтып саткан. Заманына күрә бер дигән итеп йортын, каралты-курасын, мунчасын җиткергән.

Картаймыш көнендә Олы Бакырчыда торса да, туган ягын – Урмаен сагынып яшәде. Дәү әти инде арабызда булмаса да, мишәр туганнарыбыз белән элемтәне югалтмадык. Туйларда, мәҗлесләрдә очрашабыз, кунакка йөрешәбез.

Урмай татарлар гына яши торган авыл. Ике катлы йортлар, асфальт юллар, төрле күңел ачу үзәкләре – алар чын мәгънәсендә шәһәрчә, үзләренә бер мөстәкыйль дәүләт булып яшәп яталар. Монда күбесенең үз эше бар. Чувашия авылларындагы тагын бер үзенчәлек: сала мәхәлләләргә бүленгән. Һәр мәхәллә теге яки бу проблеманы үз өстенә ала: юлны карау, аерым кешегә ярдәм итү, башка проблема булсынмы, мәхәллә җитәкчесенә килләр. Халыкта бердәмлек көчле.

«ЯШИ БЕЛӘБЕЗ!»

Чувашия татарларының милли-мөхтәрият рәисе, Татарстан һәм Чувашиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Фәрит Гыйбатдинов белән күрше республикада яшәүче милләтләшләребез турында сөйләштек.

– Бер карасаң, 37 мең күп тә түгел, ләкин аларның татар дөньясында бәһаләре зур, – диде рәис. – Бездә халык актив, нигезләре көчле. Бәлки ул мишәрлек белән бәйледер, бәлки Татарстаннан читтә яшәү белән дә. Мактанып әйтү түгел, безнең татарлар яши белә. Халык бер-берсен уздырып йортлар сала, тырышып эшли...

Урмайдан кала, Шыгырдан, Тукай авылларында да булганым бар. Шуңа игътибар итәм: һәммәсе дә рәхәтләнеп үз телендә сөйләшә. Бала-чага күбрәк әби-бабай тәрбиясендә үсә, ә димәк, буыннан-буынга күчкән гореф-гадәтләр, ана теленә булган мәхәббәт тә кечкенәдән тәрбияләнә.

– Еш күзәтәм, – ди Фәрит абый. – Өч татар очрашып, дүртенчесе рус булса, сез русча сөйләшә баш-

лыйсыз. Ә без алай түгел. Без үзебезнең милләт кешесе белән бары туган телдә генә аралашабыз. Әби-бабайлар да шулай эшләгән. Ә бит дөрес юл шушы: рус кешесенә дә татар телен өйрәнү өчен бер диган стимул. Мин үзем чуваш телен яхшы беләм, гәрчә мәктәптә укымаган булсам да. Гомер буе чувашлар белән яшәп, җирле телне өйрәнмичә булмый. Мисал өчен, нәрсәнедер сатарга, алырга барсаң да, аларча сөйләшсәң, сине үзләренеке кебек кабул итәләр. Кул биреп күрешеп, аркадан сөеп озатып калалар. Бу үзара хөрмәт дигәнне аңлата. Кем белән яшисең, шуның телен, мәдәниятен бел, динен хөрмәт ит. Без аны махсус, кемгәдер ярар өчен эшләмибез. Бу – традиция, гадәт. Чувашлар безнең хакта: «Сез булдырасыз, бик тату яшисез. Безгә сездән, татарлардан, өйрәнергә кирәк», – диләр...

Үрнәк дигәннән, Чебоксарда узган Федераль Сабантуйда Чувашия Республикасы Президенты Михаил Игнатьев та җыелган халык алдында: «Чувашиянең татар авылларына барган саен татарларның тырышлыгына сокланып, энергия алып кайтам. Алар балаларын кулланучы итеп түгел, ә кечкенәдән эш сөючән итеп тәрбияли», – диде. Җитәкче бу сүзләрне юктан гына әйтмәгәндер: татарлар күпләп яшәгән төбәкләр Чувашиянең алдынгы, төзек район-авылларыннан санала.

Чувашия татарларының милли мөхтәрият рәисе белән мәктәпләрдә татар телен укыту турында да сөйләштек. Бактың исә, бер ел элек туган телләр белән бәйле вазгыять, аларга киресенчә уңай тәэсир иткән.

– Безнең мәктәпләрдә татар теленең саны кимемәде, ә киресенчә артты, – диде Фәрит абый. – Ана теле буларак элек балалар атнасына өч сәгать татар теле укыса, хәзер биш сәгать. Дәүләт теле – чуваш теле урынына балалар ике сәгать татар телен укый.

Фәрит Гыйбатдинов Урмай авылында туып-үскән. Бүген дә шунда гомер итә. Дистә еллар элек Урмайда «Мишәр» фольклор ансамбле оештырган. Үзе дә барабанда уйный. «Мишәр» ансамбле егет-кызларыннан башка Чувашиядә бер генә бәйрәм дә узмый икән. Федераль Сабантуйда да егет-кызлар сәхнәне ду китерде.

– Урмайда сәнгать мәктәбе эшли, – диде Фәрит абый – Дүрт ел укыганнан соң, остарак, сәләтлерәк егет-кызларны «Мишәр» ансамбленә алабыз. Безне дөньяның төрле почмакларында беләләр. Кайларда гына чыгыш ясамадык. Төркиянең Халыкара Әнкара яшьләр фестивале, «Җиде йолдыз» Халыкара телевизион фестиваль, «Идел–Урал арасында» Бөтенроссия бәйгесе, Төмәндә узган Бөтенроссия татар фольклор фестивалендә һәм башка бәйгеләрдә җиңүгә ирештек. Дагыстан мөселманнары белән дуслыгыбыз зур. Соңгы вакытта кунакка йөрешәбез. Зур-зур чараларда ике як республика мөселманнары бик актив катнаша.

> **– Кем белән яшисең, шуның телен, мәдәниятен бел, динен хөрмәт ит.**

ӘСТЕРХАН ТӘҖРИБӘСЕ

Узган елда Федераль Сабантуй Әстерханда узды. Быел әстерханлылар, кырык кешелек делегация белән, җыйнаулашып, Чебоксарга килгән иде. Карап, чагыштырып йөрергә, дигәндәй... «1400 чакрым ара сизелмәде дә. 400 чакрым узган саен туктап, 2 самовар чәй эчеп, ял итеп, җырлап-биеп килдек», – диделәр.

Әстерханда татарлар, халык саны буенча руслардан һәм казахлардан калышып, өченче урында тора. Биредә алтмыш меңнән артык милләттәшебез гомер кичерә. Дөрес, кемдер үзен Казан татары дип атый, кемдер Әстерханныкы, ди, кемдер ногай дип йөртә. Ләкин аерма, нигездә, сөйләм телендә генә. Бөтен җирдәге уртак бер проблема бар тагын: Әстерханда да яшьләр, балалар ана телен начар белә. Ә татар авылларында әле тел саклана икән.

«Дуслык» татар җәмгыяте барлыкка килгәнгә – утыз ел. Татар мәктәбен ачуга ирешкәннәр, милли җыр-биюләр белән чыгыш ясаучы «Ялкын» ансамблен бөтен халыкка танытканнар. «Идел» газетасы чыгып килә. Үзләре әйткәнчә, хәлдән килгәнчә татарлыкны сакларга тырышалар.

– Иң зур горурлыгыбыз – Әстерханда Габдулла Тукай скверы булдыру, – диде «Дуслык» татар җәмгыяте җитәкчесе Әнвәр Алмаев. – Сынны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов эшләтте, безгә бүләк итеп бирде. Сквер янәшәсендә генә 74нче мәктәп бар. Анда 1200 укучы белем ала. Шуның кырык проценты татар баласы. «Тукта әле, бу мәктәпкә Тукай исеме кирәк бит!» – дип уйлаштык. Шуннан директор белән кереп сөйләштем. «Сездә татар балалары укый, янәшәдә – Тукай скверы. Белем йортына Габдулла Тукай исемен бирик. Мәктәпне үз канат астыбызга алырбыз», – дидем. Шактый катлаулы эш булып чыкты: мәктәп директорының гына сүзе җитми бу очракта. Укытучылар коллективы, ата-аналар, шәһәр администрациясе – барысының да ризалыгы кирәк. Һәркайсы белән аерым сөйләшеп, «кәгазь боткасын» ерып чыкканнан соң, 74 нче мәктәптә

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Чувашия Республикасы Президенты Михаил Игнатьев Федераль Сабантуй ачылу тантанасында. 7 июль, 2018 ел.

татар сыйныфлары ачтык. Дүрт ел элек булды ул. Башта беренче сыйныфка бер татар төркеме җыелса, киләсе елларда икешәр төркем тупланды. Бу сыйныфларда төп фәннәр рус телендә укытыла, ә ана теле буларак атнасына өч сәгать татар теле керә.

Бүген 74 нче мәктәпнең үз автобусы бар. Аны Рөстәм Миңнеханов бүләк иткән.

– Ел саен Федераль Сабантуй үткәргән төбәккә Татарстан Президенты автобус бирә, – диде Әнвәр Алмаев. – Бүләкне әлеге мәктәпкә булсын дидек. «Дуслык» татар җәмгыятенең автобусы бар, ә мәктәпнеке юк иде. Сабантуйда бар халык алдында Тукай исемен йөрткән мәктәп директорына Рөстәм Миңнеханов автобус ачкычын бүләк итте. Башка мәктәпләр алдында дәрәҗә, үзенә күрә бер кызыксындыру чарасы булды ул. Әле менә балалар бакчасы җитәкчесе килгән иде. «Безгә дә бер автобус табып бирмәссезме», – дип үтенде. «Бакчагызда татар төркемнәре булдырыгыз, аннан күз күрер», – дидем.

Әстерханның «Дуслык» татар җәмгыяте җитәкчесеннән Чебоксарда узган Сабантуй турында сорашам. «Сезне уздырдыларме?» – дип төрттергән булам.

– Чебоксар Сабантуе бик матур урында үтте, бездә мондый күркәм урын юк, – диде Әнвәр Алмаев. – Тик, миңа калса, оештыру ягыннан бераз гына кытыршылыклар бар. Әйтик, делегат булып килгән кунакларны кафеларда түгел, Сабантуй мәйданында чатырлар корып сыйлыйсы иде. Бу бердәмлекне дә арттырыр, кәефне дә күтәрергә мөмкин, минемчә. Без, мәсәлән, узган ел Сабантуй мәйданында тирмәләр ясадык. Һәр килгән кунакка аерым районнар беркеттек. Һәм, артларыннан калмый, чабып йөрдек. Әстерханга килгән кешеләр бик канәгать булып китте. Яңадан шалтыратучылар, рәхмәтләр белдерүчеләр дә күп булды.

– Федераль Сабантуйның «кухнясы» турында сөйләгез әле? Аңлашыла, Татарстан көрәштә төп батырга – машина, җирле татарларга автобус бүләк итә. Зур концерт программасы әзерли... Ә Сабантуй үткәргән төбәккә нинди бурычлар куела? – дим.

– Без, «Дуслык» татар җәмгыяте, кунакларны ашату, күңелен күрүне үз өстебезгә алдык. Әстерханда яшәүче татар эшмәкәрләре белән сөйләшеп, уртак фикергә килеп, бөтен халыкка зур бәйрәм ясадык. Ә республика, өлкә бюджетына гына өмет итү бик үк дөрес түгел, дип саныйм. Татар халкы гомер-гомергә кунакчыл булган. Без бары шушы традициягә тугры калырга тырыштык. Биредә дә бәйрәм бик әйбәт оештырылган. Тик безне уздыра алмадылар, дип уйлыйм. Без кунакларны шул дәрәҗәдә сыйладык ки, хәтта халык качып китә башлады. (*Көлә.*)

– Мондый масштабтагы Сабантуйлар уздыру кирәкме? Халыкка нәрсә бирә алар сезнеңчә?

– Федераль Сабантуй бик кирәк. Төрле өлкәләрдә яшәгән татарлар бергә җыелып, ана телләрендә аралашсын, күңел ачсын өчен генә булса да кирәк.

ТУЙ ҮПКӘСЕЗ БУЛМЫЙ

Сүз башы бит Чебоксарда узган Федераль Сабантуй иде. Чынлап та шәһәрнең иң матур урынында – үзәктә, Идел ярында узды ул. Шәһәрнең үз «Бауман» урамы да бар икән, «Кызыл мәйдан» дип атала ул. Анда музейлар, кафелар тезелеп киткән. Миңа иң ошаган урын – Чуваш академиясе театры яныннан «Яклаучы ана» һәйкәленә таба сузылган җәяүлеләр күпере булды. Идел елгасы өстеннән салынган әлеге күпернең озынлыгы 350 метр. Сабантуйга күпернең бер ягын – Татарстан, икенче ягын Чувашия әләмнәре белән бизәгәннәр иде. Аннан узуы гына да үзе бер бәйрәм булды!

Кунаклар күп иде. Җирле халык белән бергә 41 төбәктән килгән 500 татар көн буена күңел ачты. Ләкин арада канәгатьсезлек белдерүчеләр дә табылды. Мисал өчен, кемгәдер Сабантуй мәйданының төрле җирләргә урнашкан булуы ошамады. Көрәш мәйданы белән уен, утарлар урнашкан мәйдан, чынлап та, ике ярда иде. (Җәяүлеләр күпере аша чыгасы – авт.). Тик, миңа калса, моның әллә ни авырлыгы сизелмәде. Бары тик мәйданга җыелган халыкның күпме икәнен генә чамалап булмады. Кунаклар таралып йөргәнгә күрә, алдагы елларда узган Федераль Сабантуйларга караганда кеше азрак кебек тоелды. Ә Чебоксар җитәкчелеге әлеге урынны махсус сайлаган: әйтүләренчә, шәһәрнең иң матур урыны бу.

Көрәш башланганчы ук, «төп бүләк Чебоксар көрәшчесенә булачак» дигән сүзләр йөрде. Шулай килеп чыкты да: автомобиль хуҗасын төрле авырлыкта көрәшеп җиңү яулаган алты батыр арасында җирәбә салып билгеләделәр. Бәхет Чувашиянең Шыгырдан егете, 80 кг га кадәр көрәшүчеләр арасында батыр калган Ранис Саттаровка елмайды. Ә абсолют батыр, ягъни Мари Элнең Бәрәңге районы Яңавыл егете Муса Галләмовка (ул

120 кг га кадәргеләр авырлыгында көрәшә) килгәндә, ул бүләк тәкәсен Сабантуй мәйданында калдырып китте. Үпкәләү булдымы, әллә инде егет тәкәләр алып туйган шунда… Ник дигәндә, Муса Галләмовның Сабантуйларда беренче генә мәртәбә төп батыр булып калуы түгел. Машина да, тәкә дә, башка кыйммәтле бүләкләре җитәрлек булган, күрәсең.

Сабантуйдан соң Чувашия татарларының милли-мөхтәрият рәисе Фәрит Гыйбатдинов белән янә сөйләштек.

– Мондый масштабтагы бәйрәмне оештыру бик авыр икән, – диде ул. – Рәхмәт үзенә, әле дә ярый оештыру, матди яктан тәэмин итәлеш буенча ярдәмгә Чувашиянең Президенты кушылды. Ул булмаса, белмим, үзебез генә ничек ерып чыгар идек. Халыкта, оешмаларда ул кадәр акча юк. Ә мондый бәйрәмне акчасыз оештырып булмый. Теләк кенә җитми, матди ресурс та бик кирәк. Чувашия Татарстанга якын булгач, башка өлкәләрдә узган Федераль Сабантуйлар белән чыгыштырганда, безгә килүчеләрнең исәбе берничә мәртәбә артык булды. Ә җыелган халыкны урнаштырырга, кунак итәргә кирәк. Шуңа күрә үпкәләүчеләр булмасын иде, ашаган белми, тураган белә…

…Әйе, туй үпкәсез булмый. Моның кадәр зур чараларда бигрәк тә төрле җитешсезлекләр булырга мөмкин. Кем әйтмешли, теләк булганда гаеп табарга була ул. Мин исә Чебоксарда узган Сабантуйдан яхшы кәеф, сөенеч белән кайттым. Кәефләндем, чөнки көне буе үзебезнең милли җырларны, биюләрне тамаша кылдым. Сөендем, чөнки мондый мәҗлестән соң Чувашиядә яшәүче милләттәшләребезнең дәрәҗәсе, күршеләре алдына янә бер баскычка үсте. Татарларның затлы, тырыш, моңлы халык икәнен тагын бер кат башка милләт вәкилләре дә күрде, инанды. ■

ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ УЗГАН ШӘҺӘРЛӘР:

УҢЫШКА ЙӨЗ ТОТЫП...

Раифа җирлегендә урнашкан әлеге училище педагогларының шәкертләре гадәти түгел, үзенчәлекле. Ләкин биредә аларга үткәндә ясаган хаталары турында исләренә төшермиләр, ә малайлардан чын ир-ат тәрбияләргә тырышалар. 85 ел дәвамында «Ябык типтагы 1 нче санлы Раифа махсус һөнәри училищесы» девиант тотышлы балалар һәм үсмерләрнең Федераль дәүләт махсус укыту-тәрбияләү учреждениесе Россиянең дистәләгән төбәгеннән меңнәрчә үсмергә тормышка юллама бирә.

Надежда Кисиль – югары категорияле җитәкче, халык мәгарифе отличнигы, училищега унберенче ел җитәкчелек итә. Аның тормышы – биредә тәрбияләнүче балалар өчен көн саен көрәш ул:

– Әйе, уңыш һәр очракта да безнең яклы булып бетми. Ләкин бер факт бәяләп бетергесез: безнең училищены тәмамлаганнарның яртысыннан күбесе алга таба укуын дәвам иттерә, һәм бу тенденция үсешкә таба бара. Ябык типтагы учреждениедә тәрбияләнгән үсмернең моннан чыгып киткәндә хөкемгә тартылуы рәсми рәвештә алынган була. Безнең миссия гади, ләкин гадәттән тыш авыр – аларга мөмкин кадәр күбрәк игелек күрсәтергә, кайгыртырга, ә иң мөһиме – тормыш юлыннан тайпылмаска өйрәтергә, ярдәм итәргә. Без егетләргә тормышның башка төрле дә булу мөмкинлеген, аның кызыклы, төрле төсләр белән балкуын аңлатабыз! Бүген бездә эшләүче команда белән бу максатка ирешеп була, – ди Надежда Петровна.

Фото: Алёна Кутыркина; «Ябык типтагы 1нче номерлы Раифа махсус һөнәри белем бирү училищесы» администрациясе архивыннан.

Мондый учреждениенең хезмәткәре булу – «иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр» дигән стандарт график белән чикләнмәгән эш. Асылда, аларның хезмәте – шәхси вакыт белән исәпләшмичә, тәрбия һәм укыту процессына чумып эшләү, чөнки анда тәрбияләнүчеләргә «аякка басарга» ярдәм итү өчен эш сәгатен тутыру гына аз, мөмкин булган барлык вакытны алар белән янәшә уздырырга кирәк. Шуңа да биредә үз һөнәренә башы-аягы белән бирелгән кешеләр генә эшли ала. Һәм андыйлар күп – гаиләләр, хәтта династияләр бар. Бүген училищеда 9 гаилә хезмәт куя: Агафоновлар, Галиуллиннар, Гришаниннар, Кононенко, Хорт, Столяр, Лебедевлар, Роговойлар, Ефимовлар. Күз алдына да китерерлек түгел, әмма Ефимов-Пласковлар гаиләсенең гомуми педагогик стажы, мисал өчен, 520 ел!

Рәзим Шиһапов, тәрбияче; Марина Петрашева, укытучы; Әлфия Мөхәммәтшина, укытучы; Александр Дьяков, җитештерү буенча укыту мастеры; Бибинур Шәңгәрәева, укытучы һәм профсоюз комитеты рәисе; Елена Мангушева, махсус дисциплиналар укытучысы; Наталья Гыймадетдинова, өлкән мастер; Владимир Хорт, баш энергетик; Светлана Хорт, пешекче; Венера Мостафина, режим буенча кизү торучы.

1933 елның сентябре. Совет халык комиссары һәм Берләштерелгән дәүләт сәяси идарәсенең ТАССР буенча вәкаләтле вәкиленең «Раифада ОГПУның хезмәт коммунасын оештыру турында» карары чыга. Шушы көннән Раифа махсус һөнәри училищесының тарихы башлана.

1941–1945 еллар. Коммуна хезмәткәрләре һәм анда тәрбияләнүчеләр «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» шигаре астында хезмәт итә. Цехларда тәрбияләнүчеләр плащпалаткалар, санитар һәм телефон сумкалары, фляга футлярлары, кисетлар, аяк киемнәре тегә. 50дән артык хезмәткәр фронттан әйләнеп кайтмый, ә тылда хезмәт иткән 70тән артык кеше «1941–1945 елгы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнә.

1965 ел. Учреждениедә тәрбияләнүчеләр һәм хезмәткәрләр көче белән үзәктән куучы насослар эшләп чыгарыла башлый. Аларны җитештергән өчен 1979 елда хезмәткәрләрнең бер төркеме ВДНХның бронза медальләре белән бүләкләнә. 1967 елның маеннан 1985 елның августына кадәр училище коллективына халык мәгарифе отличнигы, һөнәри техник белем бирү буенча атказанган укытучы Илһамия Колчурина җитәкчелек итә. Һөнәри белем бирү үсешенә керткән саллы өлеше өчен ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан юбилей медаленә лаек була.

2000 ел. Училище тарихы музее ачыла, аңа укытучы, хезмәт ветераны Анна Володягина нигез сала.

2008 ел. Учреждениедә хәрби-патриотик тәрбия һәм кадет белем бирү программасы гамәлгә ашырыла. Училище укучылары Бөек Ватан сугышында вафат булганнарның исемнәрен мәңгеләштерү буенча Республика эзтабар отрядына кабул ителә. «Раифа» хәрби-патриотик клубы барлыкка килә, анда училище укучылары йөри.

2010 ел. Раифа махсус укыту-тәрбия училищесының эш нәтиҗәләрелеге, аның эшлекле репутациясе Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең «Сыйфат өчен» премиясе белән билгеләнә.

2016 ел. Училищеда тәрбияләнүчеләр «Юнармия» хәрби-патриотик хәрәкәтенә кушылалар.

2017 ел. Училище базасында «Раифский Витязь» кадетлар корпусы ачыла.

2018 ел. Училищеның яшь армиячеләре Бөтенроссия хәрби-патриотик балалар-үсмерләр иҗтимагый хәрәкәтенең «Җиңү көнендә хәрби парадта катнашкан өчен» медальләре белән бүләкләнә. Ел саен үткәрелә торган «Әтиәниләр кәне» акциясе Россия Федерациясенең 16 төбәгеннән 73 атаананы (законлы вәкилне) кабул итә.

ҺӘРВАКЫТ ЯШЬ

Җитәкче әйткәннәрнең хаклыгына без училище ветераннары – укытучылар, тәрбиячеләр, җитештерү буенча укыту мастерлары белән таныша башлагач инандык. Яшь, матур хатын-кызлар һәм ир-атларга күз ташлауга, аларның «ветеранлыгы» сизелми дә. Җавап итеп елмаялар гына. Һәм аңлаешлы итеп: «Без бит яшьләр белән эшлибез. Үткәннәрне сагынып утырырга вакыт юк. Һәрвакыт тонуста булу зарур», – диләр. Чыннан да! Бу кешеләр киләчәкне хәтта ашыктыралар да әле. Компьютер технологияләрен үзләштерәләр, Интернет киңлекләренә чыгалар, үзләренең тәрбияләнүчеләре белән сәяхәт итәләр. Һаман да яңалыкка омтылалар, һөнәрләре буенча камилләшәләр, тормышны һәм даими рәвештә укучыларын яратырга өйрәнәләр. Әйтергә кирәк, монда йөргәндә без бер тапкыр да рәсми яңгырашлы «укучылар» сүзен ишетмәдек. Бары тик – «тәрбияләнүчеләр», «егетләр», «малайлар» дигәнне генә...

Бибинур Шәңгәрәева – педагоглар династиясе вәкиле. Математика укытучысының хезмәт кенәгәсендә бер генә язу бар: 45 ел элек училищега эшкә алыну турындагы.

Хезмәттәшләре аның әдәплелегенә, сизгерлегенә һәм зыялылыгына сокланып туя алмый:

– Биредә минем абыем һәм аның хатыны эшләгән. Ә барысы да әле аңа кадәр үк – әтидән башланган. Ул фронтта контузия алган, һәм аны хәрби комиссариат аша режим буенча өлкән уктыучы итеп күчергәннәр. Педагогика институтын тәмамлагач, билгеле, мин үзенчәлекле урынга эшкә килүемне аңлый идем. Мәктәптә менә 17 ел инде кызым Гөлфия тарих укыта. Беләсезме, шундый акыллы малайлар эләгә! Училищены тәмамлаганнан соң, бик күпләр яза, шалтырата. Күпләренең балалары, оныклары бар инде. Менә шулай, компьютер белән эш буенча дуслашырга туры килсә, смартфонны бездән чыгып киткәннәрнең фотоларын һәм хатларын карап барыр өчен алдым. Юкса, алар минем иске «кәттә» телефонымнан «унынчы айфон» дип көләләр иде. Ул еллар ничектер бик тиз үтте. Һәм мин шушы юлны сайлавыма бер дә үкенмим. Мондагы эшемне тормышымнан аерып карап булмый...

Алмаз Галиуллин, җитештерү буенча укыту мастеры; Ренат Гафиятуллин, җитештерү буенча укыту мастеры; Ирина Шемякина, тәрбияче; Александр Агафонов, җитештерү буенча укыту мастеры.



Наталья Гыймадетдинова. Җитештерү буенча укыту вазыйфасын башкарган әлеге өлкән мастерның хезмәт кенәгәсендә шулай ук бер генә язу. Ул да 38 ел элек – Наталья Казан индустриаль-педагогик техникумын тәмамлауга теркәлгән:

– Миндә ирекле диплом иде, ә минә иптәшемне шушында билгеләделәр. Башта куркып калдык, закон буенча тиешле 3 елны эшлибез дә китәбез, дип уйладык. Аннан соң балабыз туды, тормыш башланды. Шунысы яхшы булды: яшь белгечләргә шунда ук бүлмә бирделәр. Тагын бер балабыз туды. Шулай итеп, өч ел дигәнебез кырыкка әйләнеп килә инде.

Җитештерү буенча укыту төркемнәрендә без ремонтлау-төзелеш эшләре осталарын, механика-җыю эшләре слесарьларын, токарьлар, слесарьлар, агач һәм туз уюу осталарын әзерлибез. Алар арасында алтын куллы егетләр дә аз түгел. Бу яшь осталар башкарган хезмәтләр даими рәвештә Казан ярминкәләрендә катнаша.

Минем өчен училище ул… туган йортым кебек. Хәтта үз гаиләмә дә вакытымны шулкадәр бүлмәвем өчен оят та…

Александр Дьяков, механика-җыю эшләре слесарьларын әзерләү буенча мастер. Казан индустриаль-педагогика техникумының кызыл дипломлы белгече хезмәт кенәгәсендә дә 1979 елның 1 июлендә язылган бер генә язу:

– Шуннан бирле эшлибез. Мин бирегә дустым белән килдем. Мондагы табигатьне, күлне күрдем дә хәл иттем: шәһәргә башка кайтмаячакмын. Гаиләмне дә алып килдем. Хатыным да монда башта тәрбияче, аннан җитештерү буенча укыту мастеры булып эшләде. Хәзер пенсиядә, оныгыбызны карый. Шушы еллар эчендә мин 600 гә якын егеткә һөнәр өйрәттем. Аларның күбесе белән бүген дә элемтәдә торам. Беләсезме, башта чәнечкеләрен тырпайта, беренче тапкырдан сүзне тыңламый торган малайлар да була. Ахыр чиктә минә дигән бала икәнлеге ачыклана. Күпмедер вакыт узгач, рәхмәт әйтәләр. Мастер өчен бу бик мөһим. Миңа малайлар белән эшләү һәрвакыт кызыклы булды.

Һөнәргә мәхәббәт ничек тәрбияләнәме? Бу яңгыравык сүздер, мөгаен. Эшлисе килү, кирәклегеңне тою әһәмиятлерәк. Берни дә аңламый торган бала килә синең янга, ә бер ел, ел ярымнан соң үз куллары белән катлаулы эшләнмәләр эшли башлый инде. Аңа да рәхәт, миңа исә – икеләтә. Мин аларга һәрвакыт: «Мастер канәгать булсын, дисәң, аннан яхшырак итеп эшлә, мин сиңа рәхмәтле генә булырмын», – дип әйтәм. Миңа алардан өйрәнү дә ошый, үзем өйрәтү генә түгел. Минем өчен училище… Нәрсә дип әйтим инде, гомер шушында узды.

Елена Мангушева, эстетика укытучысы, училищедагы педагогик стажы – 41 ел:

– Ел саен, методист буларак, мин мастерларны махсус укытутәрбия бирү учреждениеләренең «Ел укытучысы» бәйгесенә әзерлим. Һәм ел саен без анда алдынгы урыннарны яулыйбыз, ә быел исә безнең ике мастерыбыз да ике беренче урынга лаек булды! Димәк, без һәрвакытта да биеклектә. Мин еш кына укучылар белән төрле бәйгеләргә барам. Без Бөтенроссия күләмендәге бәйгеләрдә грантлар отабыз. Әлеге вакытта «Киләчәккә адым: чикләүләрсез һөнәр» гранты гамәлгә куелу барышында.

Әти-әниләр көннәре вакытында балалар «Һөнәргә бер адым» фестивалендә, «Осталар шәһәренә сәяхәт» квестында катнашты. Гомумән алганда, эш башланды! Кызганыч, без «Вордскиллс»та катнаша алмыйбыз. Әмма директорыбыз Надежда Петровна Кисиль белән кайчан да булса катнашырбыз, дип уйлыйм. Шанслар бар.

Училищеда эшли башлаганда, әти дә педагог иде, озак еллар мәктәп директоры булып эшләде ул. Баштарак әллә ни илһамландырмады. Әйе, җиңел түгел иде. Аеруча психолог булып эшләгән 13 елым катлаулы булды. Эшкә иртәнге 8дә китәм дә кичке 10да кайта идем. Әмма монда башкача була да алмый. Монда даими хәрәкәт! Ләкин безнең эш тәрбияләнүчеләргә ярдәм итә икән, ышана аласыз, димәк, хезмәтебез заяга үтмәгән…

Әлфия Мөхәммәтшина, математика һәм информатика укытучысы, училищеда 40 ел укыта:

– Безнең балалар үзенчәлекле. Без монда алар белән яшибез, диярга дә була. «Мин укытучы гына, сәгатьләремне укыттым да кайтып киттем», – дип бүлгәләп булмый. Яңа хезмәткәр яки педагог килгәндә, без: «Дәрес бирүче генә булмасын», –

Фото: Алёна Кутыркина; «Ябык типтагы 1нче номерлы Раифа махсус һөнәри белем бирү училищесы» администрациясе архивыннан.

“ – Кыен тәрбияле балалар өчен махсуслашкан Раифа училищесының 85 ел эшләү дәверендә иң зур традиция барлыкка килде: без үзебездә тәрбияләнүче балалар белән бергә кичкән гомер белән горурланабыз. Аларга тормыш юлын аңлы рәвештә сайлау мөмкинлеге бирәбез.

дибез. Безнең шартларда бу мөмкин түгел: дәрес үткәрдең дә шуның белән бетте, имеш. Һичшиксез, хәзерге балалар башка төрле. Алар ирекләрәк, үз фикерләрен әйтә белә. Күп беләләр, хәтта кайчак аларның сорауларыннан аптырап та каласың. Шул рәвешле, без бергә укыйбыз, бергә өйрәнәбез. Безгә мәктәпкә дә, дәресләргә дә бик шатланып тормаган балалар килүен аңларга кирәк. Кайберләре бигрәк тә зур игътибар таләп итә. Әйтик, 9 нчы сыйныфка бер үсмер килә, ә укый белми. Димәк, мәсьәлә дә чишә белми. Алар арасында талантлылары да бик күп! Карыйсың да тел шартлатасың: «Акыллым, син монда нишлисең соң? Син бит берәр гимназиядә яки лицейдә укырга тиеш!» Шунысы үкенечле: үз мәктәпләрендә аларны исемлектән сызганнар инде. Бәлки, әти-әниләренең, укытучыларының аз гына сабырлыгы, кайгыртуы җитеп бетмәгәндер. Без кыска вакыт эчендә шушы бушлыкны тутырырга мәҗбүр булабыз. Моның өчен, безнең җитәкче әйтүенчә, без «уңыш вазгыяте» тудырабыз да.

МОНДА ГАДИ ЯЗМЫШЛЫ БАЛАЛАР ЮК

Ефимов-Пласковлар гаиләсенең училищеда эшләгән гомуми стажы 520 ел диярлек!

Елена Ефимова, педагог, укытучылар династиясенең бер вәкиле:

– Шулай бервакыт Качалов исемендәге театрда миннән: «Ак күлмәкле, галстуклы әлеге итагатьле егетләр кайдан килгән? Хәзер андыйларны очрату кыен. Безгә яшьләр джинсыдан йөри», – дип сорадылар. Әйе, шундый алар безнекеләр! Мин һәрвакыт әйтә киләм: баланың һәр җинаятендә өлкәннәр гаепле! Иң мөһиме – аны аңлый белергә кирәк. Һәм каршында бик нечкә, ярады күңелле үсмер басып торуын күрергә. Билгеле, катгый рәвештә таләпләр куярга да була: «Син моны тиеш, син тегене тиеш!» Әйе, тиеш, әйе, мәҗбүр, чөнки ябык типтагы учреждениенең билгеле бер кагыйдәләре бар. Ләкин кайчак моны тыныч итеп, икәүдән икәү генә калып, баланың күзләренә карап, күңеленә үтеп әйтүең яхшырак. Нарасыйларны кайчак кочагыңа да кысасың, юатасың да. Монда гадәти язмышлы балалар юк. Кайчак аларның элеккеге тормышларын күз алдына китерү дә куркыныч. Алар яратуга мохтаҗ...

ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ҖИТӘКЧЕ

Раифа училищесы үсешенең яңа этабы Надежда Кисиль эшчәнлеге белән бәйле. Нәкъ менә аның башлангычы белән 2008 елдан башлап бирелә хәрби-патриотик тәрбия һәм кадет белем бирү программасы гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасында хәрби-патриотик хәрәкәтне үстерүгә керткән өлеше өчен ул «Ватанпәрвәрлек өчен» тамгасы һәм РФ Кораллы Көчләре Тәрбияви эш идарәсенең Мактау кәгазе белән бүләкләнгән.

Ул гаять үзенчәлекле җитәкче. Аның һәр эш көне – бер-бер артлы тезелеп киткән бихисап эшләрдән гыйбарәт: хезмәткәрләр һәм балалар белән аралашудан башлап, училищеның яшәвен тәэмин итүче мәсьәләләрне хәл итүгә кадәр:

– Безнең училищены тәмамлаганнарның күпчелеге ныклы гаилә кора, эштә үз юлын таба. Алар монда балалары белән килгәч, кайда яшәгәннәрен күрсәтәләр, без андый кунакларга һичшиксез экскурсияләр оештырабыз.

Кораллы Көчләр сафларында хезмәт иткән егетләребез – безнең аерым горурлык. Ватанга хезмәт итүне үзенең һөнәре итеп сайлаган балалар белән ничек горурланмыйсың! Алар – бүген бездә тәрбияләнүчеләр өчен менә дигән үрнәк!

Шушы еллар эчендә училищеда тулы бер укытучылар династиясе үсеп чыкты. Монда яшь белгеч булып килгәннәрнең күбесенең хезмәт кенәгәсендә бер генә язу бар. Алар, һичшиксез, коллективның умырткасын тәшкил итә. Шул ук вакытта безгә олы йөрәкле һәм креатив проектлар белән яшьләр дә килә. Учреждениедәге балалар янында лаеклы кешеләр булуына шик юк: 60 яшьлекләрнең дә, яшьләрнең дә күзләре янып тора. Учреждениенең үсештә булуы һәрвакыт ветераннарга да, яңа килгәннәргә дә эшкә иҗади якын килергә, төрле проектларны һәм программаларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә.

Кыен тәрбияле балалар өчен махсуслашкан Раифа училищесының 85 ел эшләү дәверендә иң зур традиция барлыкка килде: без үзебездә тәрбияләнүче балалар белән бергә кичкән гомер белән горурланабыз. Аларга тормыш юлын аңлы рәвештә сайлау мөмкинлеге бирәбез. Бердәнбер һәм дөрес булганын.

– Бүген училищеда 112 хезмәткәр эшли, шуларның 60ы – укытучы. Коллективның уртача яше – 42 яшь.

– Училищеда РФнең 39 төбәгеннән 11-18 яшьлек үсмерләр социаль реабилитация үтә һәм тәрбияләнә.

ЙОЛДЫЗГА КАГЫЛУ

«Казан Арена» стадионы трибуналары үз фаворитларын – Бельгия һәм Бразилия җыелма командалары йолдызларын көтү халәтендә туктаусыз гүли. Бер минут һәм кырга аларны... балалар алып чыга! «FIFA 2018 Дөнья чемпионатына Макдоналдс белән бергә!» дигән махсус программа ярдәме белән бу кечкенә җанатарларның хыялы тормышка ашкан.

«Оле-оле-оле! Россия, вперёд!» – дигән дәртле авазлар тарала. Казандагы төп вакыйга башланырга дүрт сәгать кала, «Макдоналдс» балалар җыелма командасы белән очрашу уза. Бәйрәмне алып баручы, яшь фанатларның тавышын көмәргә тырышып, тавышын өздерә. Әйе, мондый көчле яклау булганда, Бельгия – Бразилия матчында… Россия җиңәчәк!

«Макдоналдс» компаниясе, 1994 елдан башлап, футбол буенча дөнья чемпионатының рәсми спонсоры булып тора. Аның «Дөнья чемпионатына Макдоналдс белән бергә!» дигән программасы балаларга үз хыялларын тормышка ашырырга һәм, дөнья футболы йолдызы белән җитәкләшеп кырга чыгудан онытылмас эмоцияләр алырга мөмкинлек бирә. Һәм болар бөтенесе дә – чемпионатның төп матчларында! Мәсәлән, Казандагы Бельгия һәм Бразилия уенындагы кебек, ә аны спорт экспертлары ул башланганчы ук «ябык финал» дип атаганнар иде.

Быел мондый онытылмас эмоцияләр алу бәхете дөньяның төрле илләрендә яшәүче 1408 балага елмайган, аларның 1273е – россиялеләр. Алар арасында – балалар йортларында тәрбияләнүчеләр, баланы үзләренә кабул иткән яисә аз керемле күп балалы гаиләләр дә бар. «Казан Арена» кырына чыккан балалар арасында шулай ук «Роналд Макдоналд йорты»нда – озаклап БРКХда дәваланучы балаларның гаиләләрен сыендырган кунакханә карамагындагы балалар да бар. Моннан тыш, «Макдоналдс»ның балалар җыелмасына батырлык эшләгән өчен бүләкләнгән балалар да кергән. Әйтик, янгын вакытында батырлык күрсәткән Яр Чаллы малае Илназ Смирнов кебек.

Бельгия – Бразилия матчы алдыннан яшь җанатарларга кыюлык өстәргә су полосы буенча берничә тапкыр Олимпия уеннары призёры, футбол буенча FIFA 2018 Дөнья чемпионатына Казаннан илче булган Ирек Зиннуров, һәм «Мураками» төркеме солисткасы Диләрә Ваһапова килгән.

– Берзаман мин Олимпиада-80 дә безнең спортчылар өчен җан аттым, – диде танылган спортчы балаларга. – «Нинди кешеләр! Нинди уен!» – дип, сокланып әбиемә сөйләгән идем ул чакта. «Теләсәң, син үзең дә анда була аласың», – дигән иде ул миңа. Һәм менә минем хыялым чынга ашты. Ә сезнең хыялыгыз, легендага кагылганнан соң, бүген тормышка ашачак.

Фото: Дмитрий Дунин; ИТАР-ТАСС

Реклама

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

facebook.com/protatarstan

twitter.com/protatarstan

БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Республика **НИНДИ** шартларда туган

НЭП чоры **НИНДИ** мөмкинлекләр биргән

Атлар телен аңлаган «татар чегәне» **КЕМ** ул

Кичкетаңга аюлар **НИК** ияләшкән

РЕСПУБЛИКА. БЕРЕНЧЕ КӨН

1920 елның 25 июнендә иртәнге сәгать сигездә Казанның үзәгендә яңгыраган туп тавышы сизгер күңелле кайбер гүзәл затларның котын ала. Чөнки әле ике ел элек кенә булып узганнарның хатирәсе – шәһәрне аклар утка тоткан чаклар йөрәк янында сиздереп тора. Бу юлы артиллерия бернәрсәне дә җимерми. Киресенчә, әлеге ату тавышы казанлыларны төзелешкә, эшкә – Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү уңаеннан шимбә өмәсенә чакыра…

ТАССР оешу турындагы Декретны имзалау.

Рәссамнар: Л. Фәттахов, Х. Якупов, 1950 ел.

Дөресен әйткәндә, Казан губернасы башкарма комитеты хакимиятне рәсми рәвештә Татар республикасы Ревкомына тапшырырга тиешле көн җомгага туры килә. Ләкин әле кырып бетерелмәгән буржуйлар гына «субботник» буларак билгеле өмәнең һичшиксез шимбә көнне генә узарга тиешлеген расларга маташа ала. Яңаны төзүче революцион хезмәткә атнаның теләсә кайсы көнен багышлау да гөнаһ түгел! Казан губернасының башкарма комитеты рәисе Иосиф Ходоровский (френч, күн пальто, хром итекләр – барысы да үзендә!), бәлки, нәкъ әнә шулай, большевиклар рухында фикер йөрткәндер.

Кызганыч, әлегә яңаны кору, иҗат итү эше әллә ни уңышлы бармый. Патша хөкүмәтен – «явызлык дөньясы»н җимерү процессы барышында Казан бик тиз искерә һәм таушала. Гражданнар сугышы вакытында туктаган трамвайлар һаман йөреп китә алмый, күңелсез шәһәр читләре пычракка батып ята. Завод-фабрикаларның бер ише соңгы сулышын ала, башкалары бөтенләй эшләми. Хәтта берсеннән-берсе хөрмәтле кешеләр яшәгән, кайчандыр ялтырап торган, чиста-матур булган шәһәр үзәгендә, Дворяннар җыены бинасы тирәсендә, хәзер инде диварларга ябыштырып ясалган бизәкләр купкан, ишегалларында тау-тау чүп өемнәре, көек, төтен исе – анысы бу вакыйгадан өч атна әүвәл янган шәһәр театры харәбәләреннән килә.

Яңаны төзеп булмый икән, димәк, өр-яңадан башлап китәр өчен, бераз җыештырып, тәртипләп куйганда, булганы да ярап куяр. Өмәдә катнашучылар театр мәйданында җыела да, бик дәртләнеп, янгыннан калган кисәү башларын актара. Корым катыш тир гимнастёркаларда һич юылмас эзләр сала. Ул арада кемдер зарланып, сүгенеп куя: «Бу кыяфәттә банкетка ничек барасың, ди?!».

Әлеге мәҗлескә җаваплы партия хезмәткәрләрен көтәләр. Революцион хакимият фикеренчә, иң лаеклы башка иптәшләрне дә. Ходоровский үзе кул куйган чакыру кәгазьләрендә болай диелгән: «25 июнь, җомга көнне, көндезге сәгать 3 тә, Кызыл Армиячеләр сараенда



В пятницу, 25 июня, в 3 ч. дня, в Красноармейском Дворце устраивается банкет по случаю объявления Автономной Татарской Соц. Советской Республики, на каковой банкет Вы настоящим приглашаетесь.

Председатель Губисполкома Ходоровский.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү уңаеннан тантаналы мәҗлескә чакыру билеты. 1920 ел.

Фотолар ТАССРның 100 еллыгы сайтыннан (100.tatarstan.ru)

Сәхибгәрәй Сәетгалиев (1894–1939), ТАССР Халык комиссарлары Советының беренче рәисе.

Татар республикасының Оештыру съездында катнашучылар. Казан, 1920 ел.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү уңаеннан банкет оештырыла. Әлеге билет белән сез шул банкетка чакырыласыз».

Янгын урынын чистартучылар арасында бәйрәмгә чакырылганнары күп түгел. Өмә үзе дә бик тыйнак булды, дип әйтү хаклыкка якынрак. Соңыннан газеталар язганча, хезмәт бәйрәмендә 4161 кеше катнашкан. Бу исә халыкның өч процентган да азрагы дигән сүз. Нигездә, болар Запастагы армия солдатлары, эшчеләр һәм хезмәткәрләр була. Үз ирекләре беләнме? Әлбәттә! Гарнизон, хезмәт комитеты башлыклары, губерна башкарма комитеты президиумы тарафыннан бастырылган кырыс фәрманнарны үтәп...

ДӨНЬЯ УЛ – ТЕАТР

Әлеге тарихи көндә тагын бер мөһим вакыйга исә каланың татарлар яшәгән өлешендә була. Мондагы Юнысов мәйданында Мулланур Вахитов һәйкәленә нигез салына. Әлеге мизгелнең ни дәрәҗәдә тантаналы булганын кызыл комачтагы гарәп хәрефләре белән татарча язылган лозунг та раслый: «Татар пролетариаты яшь республиканың чәчәк атуы өчен бар көчен куярга ант итә!» Шул ук сүзләр кириллица белән русча да кабатлана.

Татар милли театры нигезенә беренче ташны салу тантанасы тагын да зурлабрак уздырыла. Халык җыены каршындагы балконга тулы бер президиум чыга: иптәш Ходоровский, Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты вәкиле, эчке эшләр буенча халык комиссары урынбасары Михаил Владимирский. Хәтта хөрмәтле чит ил кунагы да була. Сүз иптәш Фуад турында бара. Ул – төрек коммунистлар партиясе әгъзасы, баш күтәргән Кемаль паша хөкүмәте вәкиле. Революцион нотыклар яңгыраганмы? Билгеле инде!

– Шәһәр театры, Дворяннар җыены һәм башка шуның ишеләр безнең өчен ябык иде, – дип сөйли яхшы куелган яңгыравык тавышы белән актёр Камал (Габдулла Камалетдинов булса кирәк, тәхәллүсе Камал I. – Ред. иск.). – Андагы беренче рәтләрдә иң элек губернатор белән полицмейстер утыра иде. Республика безгә спектакльләребезне Казанның теләсә кайсы театрында куя гына түгел, үзебезнекен төзү мөмкинлеге дә бирә!

Оештыручыларның эшен билгеләп китик, чөнки митинг әллә ни озакка сузылмый. Көндезге бердә Иосиф Ходоровский театр мәйданында була инде. Тураеп басып, фуражкасына бармакларын тидереп ала– Казан гарнизоны гаскәрләре парадын сәламли. Беренче булып мәйданнан Казан хәрби курсларының кызыл командирлары һәм курсантлары уза. Алар артыннан, колонна-колонна булып – пехота, артиллерия һәм кавалерия частьлары. Кырыслык, таләпчәнлек тә, матурлык һәм ышаныч та бар монда. Бер ай гына элек солдатлар бунты булмаган да диярсең, ул чагында ярымач хәлләренә канәгатьсез хәрбиләр, кулга корал тотып, урамнарга чыга...

«ЧЫНГА АШМАСТАЙ» ИДЕЯ ЯШӘСЕН!

Бәйрәмнең иң якты, иң биек ноктасы, әлбәттә, Сөембикә манарасы. Аны бүген кияү куенына керәсе комиссар кыз кебек бизиләр. Күккә ашкан өске яруста – РСФСР-ның бик зур гербы. Җиргә якынрак катта аршындай эре хәрефләр белән: «Бөтен илләрнең пролетарийлары, берләшегез! 1552–1920 ел. 25 июнь – татар хезмәт халкының үзбилгеләнү акты тормышка ашу көне. Яшәсен автономияле ТАССР! Яшәсен РСФСР!» – дип язып куелган. Манараның бар катларында да – байраклар, байраклар, байраклар. Әле Сөембикә манарасын кич электр уты белән яктырткач ни булыр әле... Бөтен Казанга берике йөз лампочка, ә монда шундый зиннәтле байлык!

Манарадагы утлар Иосиф Ходоровский Кызыл Армиячеләр сараенда трибунага чыккан вакыттарак кабына. Монда хәзер иң төп вакыйга – хакимиятне тапшыру тантанасы узарга тиеш.

– Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан иткән 27 май акты пролетар революциянең үсешендә бик зур роль уйнарга тиеш, – губерна башкарма комитеты рәисе үз чыгышын большевикларча басым белән башлап җибәрә. Һәм һичкем кире кага алмаслык тонда дәвам итә. – Совет хакимиятенең яңа республика игълан итүе гаять уйланылган һәм аңлы, һичкем тарафыннан мәҗбүриләп тагылмаган карары булып тора. Эшче-крестьян хакимиятенең Татар республикасын ике ел элегрәк игълан итмәве тышкы шартларның бөтен игътибарны саклану тарафына юнәлтергә мәҗбүр ителүе белән генә аңлатыла. Менә хәзер генә, бераз хәл алырга һәм көчләрнең

1920 елның 28 маенда РОСТА (Россия телеграф агентлыгы) дөньяга хәбәр сала: «Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты президиумы 27 майда кичке сәгать 7 дә үзәге Казан шәһәре булган Татарстан Автономияле Социалистик Республикасы турында карарны раслады. Республика составына Казан губернасының көнчыгыш өлеше, Уфа губернасының Минзәлә өязе һәм Бөгелмә шәһәре белән бергә Самара губернасы Бөгелмә өязенең күп өлеше керә».

бер өлешен эчке төзелешкә юнәлтергә форсат табылгач кына, без татар хезмәтчәннәренә үзбилгеләнү мөмкинлеге бирә алдык!

Иптәш Ходоровскийның эчкерсезлеге һәм ныклы ышанычы Ревком белән губерна башкарма комитетының уртак утырышында катнашучыларның барысына да гипноз сыман тәэсир итә. Аңа аягүрә торып кул чабалар. Хәтта Иосиф Исаевичның әле күптән түгел генә Татар республикасын оештыру идеясенә нindирәк фикердә торганын белгән көрәштәшләре дә. (Соңрак үз истәлекләрендә Ходоровский таный булыр: «Татар республикасын оештыруга бернинди әзерлек адымнары да ясамадык. Ул гына да түгел, без хәтта бу мәсьәләне чын-чынлап карамадык та, чөнки Татар республикасын оештыру безгә шулкадәр кирәксез, зарарлы һәм чынга ашмастай идея булып тоела иде».)

Иптәш Иосиф үз фикерен бер сәгать эчендә үзгәрткән дип сөйлиләр – Мәскәүгә, Ленин янына келәмгә чакырылу белән. Ни дисәк тә, партиядә большевиклык дисциплинасы – искиткеч үтемле көч. Һәм менә хәзер иптәш Ходоровский, хакимият вәкаләтләрен тапшыру турында актны бик ышаныч белән, мыскал да шикләнмичә укый.

– Шушы сәгатьтән хакимият Татар республикасы революцион комитетыныкы! –Тамашачыларның алкышларына күмелеп, Иосиф Ходоровский республиканың беренче җитәкчесе, Ревком рәисе Сәхибгәрәй Сәетгалиев белән пролетарларча кул бирешә.

– Татар республикасының хезмәт массалары исеменнән, – дип игълан итә Сәхибгәрәй Сәетгалиев, – аның барлык хезмәт ияләренең тулы фикерен чагылдырып, Россия Республикасы Бөтенроссия Үзәк башкарма комитеты тарафыннан вәкаләтләндерелгән Ревком шушы сәгатьтән башлап, Казан губерна башкарма комитетыннан яңа республика белән идарә итү вәкаләтләрен үзенә кабул итеп ала. Шушы мизгелдән Ревком үз вазыйфаларын үтәүгә керешә. Бу чынга ашты!

ЛАНДРИН ТӘМЕ КИЛӘЧӘК КИЛӘЧӘК

Киләчәктә танылган рус шагыйрәсенә әвереләчәк Вероника Тушновага 1920 елда тугыз яшь тула. Зур популярлык яулаячак татар композиторы Сара Садыйковага – ундүрт яшь. Республика оешкан көнне алар икесе дә, башка Казан балалары кебек, революцион хакимияттән чын патшаларча бүләк – 1/8 фунт (илле граммнан бераз гына артыграк) ландрин ала. Тәме инде күптән онытылган татлы конфетны күргәч, эти-әниләрнең авыз сулары ага! 25 июнь республиканың яшь гражданнары өчен иң бәхетле көнгә әйләнә...

Татар республикасы оештырылу вакыйгасын халык ничек кабул иткән? Ул чактагы матбугат язмаларына ышансак – искиткеч энтузиазм белән. Менә «Хезмәт Байрагы» («Знамя Труда») газетасында Татар республикасын яклаган митингтан бер-берсенә игезәктәй охшаш ике мәкалә. Менә Казан дары заводы пролетарийлары республика булдыруны «Шәрыкта социалистик идеяләрне тарату чарасы, күп миллионлаган мөселман гавамының уянуына этәргеч» сыйфатында сәламли. Республика оештыруны хуплаулары хакында Бертуган Крестовниковлар заводы эшчеләре дә белдерү ясый. Һәм телеграммалар, телеграммалар... – республика исеменә котлауларны Минзәлә өязеннән, Арча, Мамадыш, Тәтештән яудыралар....

Асылда исә, мөгаен, барысы да җай гына бармагандыр. Бөтен халык бер мизгелдә һәм һич каршылыксыз ышаныч белдерсен өчен кулай вакыт түгел – республикадагы хәл артык киеренке һәм катлаулы. Чит ил интервенциясе, шпионнар һәм саботажникларның эчтән шартлату куркынычы аркасында, «16 майдан бөтен Казан губернасында хәрби хәл режимы кертелә, ә Аракчино заводы һәм дары заводы тирәләре камаулы хәлдә дип игълан ителә», – дип хәбәр итә «Хезмәт Байрагы» газетасы. Шәһәрдә хәрби коммунизмның барлык «шәп» яклары күзгә ташлана: ачлы-туклы тормыш, азыктөлеккә карточка системасы, кибетләрдә исә җил уйный. Авылларда хәлләр бөтенләй мөшкел: продотрядлар крестьяннарның бөтен ашлыгын, хәтта чәчүлек орлыкны да кырып-себереп тартып ала. Киреләнеп торудан файда юк: әле кайчан гына булган «сәнәк сугышлары»ның аяныч нәтиҗәләрен һәркем хәтерли. Ул чакта Минзәлә, Чистай, Бөгелмә өязләрендә продразвёрсткага каршы күтәрелергә җөрьәт иткән крестьяннарны гаскәр җибәреп бастыралар.

Казанда Татар республикасына каршы хәтта ачыктан-ачык каршы чыгучылар да табыла. Дөрес, 25 июньдә уздырылган карагруһчылар демонстрациясе әллә ни күп санлы булмый. Әмма шунысы мәгълүм: тиздән шәһәрдә янгыннар дөрли – 243 йорт көлгә әйләнә...

Мәскәү тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләргә ия автономияле Татар республикасын бу хәлдә оештыру татар зыялылары һәм милли хәрәкәт башлыкларында да сораулар уята. Өстәвенә, әүвәлрәк большевиклар «Идел-Урал» штаты, ә соңрак Татар-Башкорт республикасын оештыру идеясен бик уңышлы юк итә. Икенче яктан, белемле татар халкының зур өлеше аңлый: Татар республикасы дүрт йөз елга якын элек югалтылган дәүләтчелекне кире кайтаруга бер адым булып тора.

Хәер, татар зыялыларының фикеренә колак салырга мөмкиннәр, ләкин шуннан ары түгел. Урамда – пролетариат диктатурасы, дөресрәге, өч ел элек илдә хакимиятне яулап алган партия диктатурасы. Һәм милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы турында Ленин шигарен никадәр гадел тормышка ашырачагын бары тик партия үзе генә хәл итә.

100.tatarstan.ru сайтында тагын да күбрәк материаллар таба аласыз

Әскәр Сабиров **әзерләде**

БӨТЕНРОССИЯ ҮЗӘК БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҺӘМ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ 20 ЕЛНЫҢ 27 МАЕНДА КАРАР ЧЫГАРДЫ:

I

1) Россия Социалистик Федератив Совет Республикасының бер өлеше буларак Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасын төзергә һәм аның составына кертергә:

а) Казан губернасыннан: Казан, Чистай, Мамадыш, Зөя, Тәтеш, Лаеш һәм Спас өязләрен – Жидяев һәм Йортқул, Алабуга өязенең Черкас һәм Салавыч, Кызыл Кокшай өязенең Күлле Киме һәм Кышлау волостьларыннан башка;

б) Уфа губернасыннан: Минзәлә өязен;

в) Самара губернасыннан: Бөгелмә өязенең Азнакай, Александровка, Әлки, Әлмәт, Баулы, Богоявленское, Варварино, Югары Карамалы, Каратай, Кузайкино, Ивановка, Мәсәгут, Микулино, Мордовское Афонькино, Мордовская Ивановка, Мордовская Кармалка, Түбән Чыршылы, Яңа Писмән, Салих, Спас, Спиридоновка, Стәрлетамак, Сумароково, Тымытык, Урсалы һәм Чекан волостьларын;

г) Вятка губернасыннан: Малмыж өязенең Кошкино, Носы, Арбор, Янгул, Сәрдекбаш, Түбән Четай һәм Шода волостьларын;

д) Сембер губернасыннан: Сембер өязенең Сөендек, Олы Тархан һәм Зур Чынлы волостьларын, Буа өязенең Иске Суыксу, Янтуган, Шыгырдан, Яңа Кәкерле, Чүпрәле, Мәчәле, Борындык, Рунга, Тимбай, Үби һәм Городище волостьларын.

Искәрмә: Татарстан Социалистик Совет Республикасы составына Уфа губернасының Бәләбәй һәм Бөре өязләрен кертү мәсьәләсен әлеге өязләрнең хезмәт ияләре үз теләкләрен белдергәнгә кадәр ачык калдырырга.

II

2) Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт хакимияте аппараты, РСФСР Конституциясенә ярашлы рәвештә, җирле Депутатлар советларыннан, Үзәк Башкарма комитетыннан һәм Татарстан Совет Социалистик Республикасының Халык комиссарлары советыннан хасил була.

3) Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасының эшләре белән идарә итү өчен түбәндәге Халык комиссариатлары булдырыла: 1) эчке эшләр – почта һам телеграф белән идарә вәкаләте белән, 2) юстиция, 3) мәгариф, 4) сәламәтлек саклау, 5) социаль тәэминат, 6) игенчелек, 7) азык-төлек, 8) финанс, 9) Халык хуҗалыгы советы – хезмәт һәм элемтә юллары бүлекләре белән һәм 10) Эшче-крестьян инспекциясе.

Искәрмә: Чит ил эшләре һәм тышкы сәүдә тулаем РСФСРның Үзәк органнары карамагында кала. Хәрби эшләр белән турыдан-туры якындагы Округ хәрби комиссариатына буйсынган Татарстан хәрби комиссариаты шөгыльләнә. Контрреволюция белән көрәш Бөтенроссия Гадәттән тыш комиссиясе Татарстан Халык комиссарлары советы белән килештереп оештырган Бөтенроссия Гадәттән тыш комиссиясе органнары карамагында кала.

4) Республиканың барлык территориясендә РСФСР финанс һәм хуҗалык сәясәтенең бербөтенлеген саклап калу максатында, Татарстан Совет Социалистик Республикасының азык-төлек, финанс, халык комиссариатлары, Халык хуҗалыгы советы, хезмәт һәм элемтә юллары бүлекләре, эшче-крестьян инспекцияләре, эчке эшләр халык комиссариаты карамагындагы почта һәм телеграф идарәсе тиешле РСФСР Халык комиссариатларына турыдан-туры буйсынуда калалар, аларның фәрманнарын һәм инструкцияләрен үтәргә тиеш булалар.

5) Татарстан Совет Социалистик Республикасының эчке эшләр (почта һәм телеграф идарәсеннән башка), юстиция, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль тәэминат һәм игенчелек халык комиссариатлары үз эш-гамәлләрендә мөстәкыйльләр һәм турыдан-туры ТССР Үзәк Башкарма комитеты алдында җаваплы.

6) Казан Советы Рәисе Татарстан Халык комиссарлары советы составына хәлиткеч тавыш хокукы белән керә.

7) Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы бөтен кирәкле финанслар һәм техник чаралар белән РСФСРның уртак чаралары хисабына тәэмин ителә.

III

8) Татарстан Совет Социалистик Республикасының 1 нче съезды чакырылганга кадәр Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасында әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән чикләрдә хакимият бөтен тулылыгында Татарстан Совет Социалистик Республикасының Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан гамәлгә куелган Вакытлы революцион комитеты кулында була. Әлеге комитетның иң әүвәлге бурычы Татарстан Совет Социалистик Республикасының 1 нче Советлар съездын чакыру һәм революцион комитетның Татарстан Совет Социалистик Республикасының бу нигезләмәнең 3 нче пунктында күрсәтелгән Халык комиссариатларына тәңгәл килгән бүлекләрен оештырудан гыйбарәт.

9) Эчке эшләр Халык комиссариатына һәм Милләтләр эшләре Халык комиссариатына Татарстан Совет Социалистик Республикасының чикләрен җентекләп билгеләгәндә туарга мөмкин мәсьәләләрне хәл итү өчен катнаш комиссия оештыру йөкләнә.

Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты рәисе — М. КАЛИНИН.

Халык комиссарлары советы рәисе — В. УЛЬЯНОВ (ЛЕНИН).

НЭП ЧОРЫ: СОҢГЫ ТАЛПЫНЫШ

Казан. Егерменче еллар башы. Әнә, Гостиный дворның ерак бер почмагында, башка чүп-чарлар арасында, Азатлык бүләк иткән Александрның бронза фигурасы тузанга батып ята. Аның урынында, Кремль каршындагы мәрмәр «Александр постаментында» – иректе хезмәтне гәүдәләндерүче таза беләкле эшче һәйкәле. Тик гасырларга дип куелган гипс эшченең хәле генә мөшкел: ул күзгә күренеп таралып бара...

Автор:
Әскәр Сабиров

– Хәерлегә түгел, – дип пышылдлаша хорафатларга ышанучы кешеләр. – Чит постаментка куярга ярамый иде, гөнаһ бит ул...

Ә менә гади коммунистлар хорафатларга колак салмый. Тик аларның да, кайберләренең, билгеле, башларында – боламык. Гипсның судан һәм температура сикерешләреннән җимерелгәнен белеп торалар, югыйсә, әмма һәр начарлыкта нэмпаннарны гаепләргә атлыгып торалар. Пролетариат республикасында ниндидер кирәкмәгән эшләр кылына, дип исәплиләр. Әлмәтов һәм Үтәшевның Казандагы сабын кайнату заводларын элеккеге хуҗаларына арендага биргәннәр, мамык фабрикасын – шулай ук. Нәрсә өчен көрәштеләр? Ә яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр сыман ачыла торган вак фабрикалар, артельләр, кибетләр? Юкса болар барысы да шәхси затлар, эшче халыкны эксплуатацияләүчеләр ләбаса!!!

ХАЛЫККА – ПОРНОГРАФИЯ БӘЙЛӘМЕ

Хуҗалар үз предприятиеләрендә үзләре теләгәнчә эшли. Хуҗалар икмәк пешерә. Хуҗалар сата. Һәм оятсызларча, пролетарларга хас булмаганча, һәркайда үз көен көйләп, акча туздыра. Хәтта «Известия ТатЦИК» газетасының театр тәнкыйтьчесе дә коммунистларча үртәлүен яшереп кала алмый: «Казанда әле беркайчан да театрларның быелгы кебек күп булганы юк иде. Бөтен җирдә спектакльләр куялар. Әмма ниндиләрне бит? Арада заман рухына җавап бирүче пьеса исемнәре сирәк күзгә чалына. Октябрь көннәрендә, мәсәлән, Зур театр «Сполошный зык»ны, татар театры исә «Җирсезләр»не куйды, тик болары да бары тик Октябрь уңаеннан гына. Аңа кадәр һәм аннан соң куелганнар арасында менә ниләр бар: «Язгы ташкын», Арцыбашевның «Көнләшү»е һәм порнография тирәсендә әвәрә килүче башка чүп-чар...»

Гади большевиклар өчен нэпманнарның канкан биюе мыскыл итү кебек тоела. Ә бит социализм теләгәннәр иде, менә сиңа – шалкан мае... Партия җитәкчеләре җитди киеренкелектә: көне-төне кайнап чыгар дәрәҗәгә җитеп кызган башларын суыталар. Кабинетларда, кызыл почмакларда, җыелышларда бертуктаусыз ятланган җөмләләрен кабатлыйлар: НЭП – яңа икътисадый сәясәт. Бурычы – бөлгенлекфәкыйрьлекне һәм ачлыкны җиңү. Шуның өчен продразвёрстка азыктөлек салымы белән алыштырыла – крестьяннарның бөтен ашлыгын кырып-себереп алмыйча, чәчәргә һәм яшәргә (ашарга) калдырырга. Шуның өчен, элеккеге хуҗаларына булса да, предприятие һәм фабрикаларны арендага бирергә; Гражданнар сугышыннан бирле таланган һәм җимерелгән цехларны үз акчаларына кабат торгызсыннар. Шуның өчен дәүләт предприятиеләрендә хуҗалык исәп-хисабы, вак шәхси эшмәкәр өчен тулы ирек һәм сәүдә итү хокукы – барысын тигезләүдән һәм карточкалардан китү, товар-акча мөнәсәбәтләрен кабат торгызу өчен...

«СТЕНЬКА РАЗИН» ҖИЛКӘСЕ АША КАРАСАҢ...

– Димәк, кабат артка, капитализмга? Бәлки, ул чакта Крестовниковларны, Алафузовларны, Стахеевны кире кайтарырбыз, кабат аларга бил бөгәрбез? – дип, мыскыллы сорау бирә бер әзерлекле пролетарий.

– Ә менә анысына юл куймабыз! – дип йодрыгы белән өстәлгә китереп ора партия җитәкчесе. – Эре предприятиеләрне беркем дә революция дошманнарына бирмәячәк, аның өчен кан түкмәдек...

Һәм чыннан да Крестовниковларның сабын кайнату һәм шәм

заводы, Паратск мастерскойлары, дары заводы, Бондюг химия заводы һәм ул заманның башка сәнәгать гигантлары тора-бара дәүләт кулына күчә, трестларга берләшә... Яңа хакимияткә, социализм идеяләренә тугрылыгын киң күләмле идеологик акция дә расларга тиеш була: фабрика һәм завод исемнәреннән аларның элеккеге хуҗаларының фамилияләре юкка чыгарыла. «Күнчеләр союзы идарәсе Кожтрестка кертелгән һәм арендага тапшырылган дәүләт предприятиеләренең исемнәрен алыштыру кампаниясен тәгәлләде, – дип хәбәр итә халыкка газета. – Предприятиеләргә түбәндәге исемнәр бирелде: Алафузовлар заводына – Ленин исеме, «Поляр» фабрикасы хәзер «Спартак» дип йөртелә, Глинкинныкы – «Пугачёв», Шабановныкы – «Стенька Разин», Готлицерныкы – «Коммунист», Наумовныкы – «Освобождение труда», Сәлимҗановныкы – «Кызыл күнче». Шулай ук Крестовниковлар заводы да башка юк – Вахитов исемендәге завод кына бар.

Әмма ач карынга идеяләр начар эшкәртелә. Татарстан республикасында НЭП башланган вакытка хәлләр коточкыч авыр була. Сәнәгать предприятиеләренең 83 проценты тулысынча җимерек яки Гражданнар сугышыннан бирле яраксыз хәлгә килгән килеш тора. Сугышка кадәрге вакыт белән чагыштырганда, җитештерү күләме биш тапкырга кыскарган. Өстәвенә, коточкыч корылык булу сәбәпле, уңыш уңмаган 1921 елда ачлыктан һәм тифтан 218 меңнән артык кеше үлгән һәм бөтен мал-туар да диярлек суеп бетерелгән – боларын инде беләбез...

БЕРТУГАН ЖИГАЛОВЛАРДАН – КАПИТАЛИЗМ

Һәм менә Казанның нибары дүрт елдан соңгы хәле. Богоявленская чаң манарасы янәшәсендәге мәйдан хәзер Балык рәтләре дип аталмый, ул – Кооператив урамы! Әмма монда кооператорлар хуҗа түгел. Шәхси почмакларда, сәүдә киштәләрендә, ваклап сатучыларда – җаның теләгән һәр нәрсә бар. Такта чәй кирәкме – рәхим итегез! Тозлы балыкмы – алыгыз гына! Тәмәке, ситсы, крендельме? Теләгән кадәр алыгыз! Карагыз тагын – шикәр ватарга киләшчәләр, «Красный Октябрь» артеленнән трюмо, «Курдим»нан папирослар, Казанның «Кроль» фабрикасыннан мехлар да бар. Чын тормыш тантанасы!

Һәм бу тантананың төп хуҗалары – шәхси эшмәкәрләр. Шәхси сәүдә әйләнеше республика башкаласында да, кантоннарда да әле ике ел элек кенә дәүләт һәм кооператив сәүдәсе әйләнешеннән күпкә артыграк булган. Инде 1923 елда ук Татарстанда 15 меңнән артык һөнәрче эшләгән. 1927 елга аларның саны 57 меңнән артып киткән. Республикадагы барлык сәнәгать продукциясенең кырык процентына якын өлешен планнардан һәм идарә итүчеләрдән азат, әмма булдыклы һәм тырыш шушы кешеләр җитештергән!

Шәхси эшмәкәрләр, күрәсең, бар фронтларда җиңәргә сәләтле. Аларга арендага вак предприятиеләрне генә тапшыралар, эрерәкләрен – әллә нигә бер. Әмма аларның заводларында, кагыйдә буларак, җитештерүчәнлек югарырак. Ике күн эшкәртү заводын арендага алган бертуган Жигаловлар Таткожтресттагы дәүләти көндәшләреннән ачыктан-ачык көлә: нэпманнар ике тапкыр артыграк җитештерә, сыйфаты да – чагыштыра торган түгел. Большевиклар рөхсәте белән үзләренең элеккеге предприятиеләрен арендага алган Якобсон һәм Готлицерда да – шул ук тенденция. Нэпманнар Даутов, Латыйпов, Сәйдәшевта да – шулай.

Шәхси эшмәкәрләргә ташламалар каралганмы әллә? Каралган, ди! Бертуган Жигаловлар, Якоб-

сон һәм Готлицерлар белән арендага кун, сабын кайнату заводларын, тәмәке фабрикасын, «Труд» типографиясен, кирпеч заводын һәм бүтән предприятиеләрне алган башка шундый ук нэпманнар да кырыс килешүләргә кул куя. Беренчедән, юкка чыгарылган җитештерүне сафка бастырыр өчен алдан ук шактый акча кертергә тиеш булалар. Икенчедән, аренда өчен тиешле вакытта түләргә. Өченчедән, продукциянең 20 процентына кадәрен дәүләткә тапшырырга. Кайберләре, килешү буенча, станокларны һәм җиһазларны да яңартырга, егәрлекләрне дә үстерергә тиеш була. Үзләренә киләчәк өченме? Тик килешү срогы – биш елдан да артык түгел бит.

– Ә аннары нәрсә? – дип сорагандыр нэпман арендага бирүчедән.

– Аннарымы? ГПУ (Дәүләт сәяси идарәсе) карар чыгарыр, – дип җавап бирәчәк эченнән генә партияле идарәче. Ягымлы йөзеннән елмаю да балкып китәдер әле, җитмәсә.

1925–1926 елларда арендаланган сигез кун заводы гына да республикага 575 мең вак кун җитештереп бирә. Таткожтрестның барлык заводлары исә – 300 меңгә якынны.

Йә, мондый хәлдә дөнья революциясе идеяләрен ничек тормышка ашырып була, ди?!

«ХУҖАЛЫГЫН ҮСТЕРГӘН ҺӘМ МИЛЕКЧЕЛЕК ЯГЫНА ТАЙПЫЛГАН ӨЧЕН»

Татарстанда НЭП чорының документаль шәһадәтнамәсе – «Коммунистический путь» журналы. 1924 елның октябрь санында БКК (Берләшкән контроль комиссиясе) партколлегиясе тарафыннан партия әгъзалыгыннан чыгарылганнарның исемлеге китерелгән. Иң гаҗәбе – «Ни өчен чыгарылган» графасы. Әйтик, элеккеге иптәшләрнең берсе большевиклар сафыннан «хуҗалыгын үстергән һәм милекчелеккә тайпылган өчен» чыгарылган. Вакыт тагын бер кызыклы документны – уртакул партия хезмәткәре чыгышын саклап калган: «Тормышының бар яклап яхшыруы, шәхси мәнфәгатьләр, матди ягы турында чиксез кайгырту – кайбер сабырсыз иптәшләрне шәхси хуҗалык булдыруга, йортлар, атлар һәм пролетар революция шартларында коммунистка тиеш һәм хас булмаган башка әйберләр сатып алуга китерде. Шуңа бәйле рәвештә кайбер партия әгъзаларының аерымлануларын һәм йомылуларын билгеләп үтәргә туры килә, алар, билгеләнгән вакытны эшләгәннән соң, үзләренең шәхси, гаилә мәнфәгатьләренә тиеш булганнан күпкә артыграк игътибар бирә башладылар».

«Җиңел» акчалар – нэпманнарда, ә менә алар өчен тир түгүчеләрдә – яхшы хезмәт хаклары. Боларга пролетариатның тотрыксыз өлешенең башын әйләндерергә сәләтле буржуаз күңел ачуларны да өстәсәк... Билгеле инде, партия хәтта үзенчәлекле НЭП шартларында да пролетариатта сыйнфый нәфрәт хисе томалануына һәм шәхси милекчелеккә мәхәббәт уянуына юл куя алмый. Хезмәт халкының дошманнары, хәтта алар илнең икътисадын тирән баздан өстерәп чыгаручылар булсалар да, дошман булудан туктамый. Димәк, большевистик идеяләрне пропагандалауны көчәйтү зарур, акыллы һәм көндәлек агитация таләп ителә.

Партия журналы бу эштә алыштыргысыз роль уйный. Татреспубликада 1920 елның 1 декабрендә үк «Вестник областкома РКП ТССР» дөнья күрә («Татарстан» журналының тарихы әнә шуннан башлана да инде. – Ред. иск.), аның оештыручысы һәм беренче редакторы партия өлкә комитетының беренче секретаре Александр Таняев була. 1921 елның сентябреннән журнал – «Спутник агитатора», ә тагын ике айдан соң «Коммунистический путь» дип атала башлый. Татреспублика РКП (б) өлкә комитетының һәм Главполитпросветының әлеге басма органы НЭПның чәчәк аткан чорында чыга...

БЕЗНЕҢ ЗАМАННЫКЫ БУЛМАГАН ГЕРОЙЛАР

Әмма, эш белән ныгытылмаса, хәтта партия сүзе дә капиталсыз



банкирга тиң. Шәхси эшмәкәр белән сәламәт булмаган көндәшлектә дәүләт чигенергә җыенмый. Шул чорның газетасындагы язмадан өземтә: «Икътисадый көрәшкә... бер генә эшче һәм крестьян да битараф карарга һәм читтә торырга тиеш түгел», – дип язып, массаларда ярыш дәртен кыздыралар.

Ярыш дәрте, чыннан да, уяна. Дәүләтнеке булган Бондюг химия заводында, Вахитов исемендәге заводта, «Победа труда» Васильево пыяла заводында, Паратск остаханәләрендә – шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеге үсә. Бондюг химия заводы илнең иң эре һәм алдынгы предприятиеләреннән берсенә әверелә – ул СССРның барлык химия продукциясенең өчтән берен бирә. Дәүләт предприятиеләрендә барысын тигезләү юк диярлек, биредә акча өчен генә түгел – идея өчен дә эшлиләр.

Республикада электр станцияләре төзелә (Ленинның ГОЭЛРО планы буенча), димәк, гамәлдәге егәрлекләрне үстерү, яңа предприятиеләр төзү мөмкинлеге дә барлыкка килә. Большевикларның эксклюзив коралы – мораль яктан күтәрү системасы эшли башлый. Иң яхшы эшчеләр хәзер «Хезмәт Герое» исемен ала. Беренчеләрдән булып – дәүләт заводы коючысы Владимир Бобров, бастыручы Ибәтулла Гыйззәтуллин, электр станциясе машинисты Георгий Герасимов... 1920–1926 елларда бу исем 550 эшчегә бирелә.

Партия илдә хәзер тормышның чын хуҗасы кем булуын һәрвакыт сиздерми генә искәртеп тора.

МАВР ҮЗ ЭШЕН ЭШЛӘДЕ...

Казан, 1927 ел. Шәһәрне хәзер танып булмый. Урамнар буйлап, революциягә кадәргечә, трамвайлар теркелдәп үтә. Вагоннар Суконкадан – Устьега, Академическаядан Вахитов исемендәге заводка кадәр йөри... Заречьега, Восстание бистәсенә автобуслар җибәрелгән. Авыр «фиатлар» атларны өркетә – элек шәһәрдә бер дә автобус булмаган бит. Ә Түбән Кабанда яңа электр станциясенең кызыл кирпеч бинасы калкып чыга – электрлаштыруның беренче карлыгачы, шәһәрнең горурлыгы. Хәзер хәтта шәһәрнең эшчеләр яшәгән читләрендә дә – керосин төтәткечләр генә түгел, ә чын Ильич уты. Казанда гынамы – Яшел Үзән янындагы Норлат авылының да үз электр станциясе бар...

1925 елга Татарстанның сәнәгать җитештерүе күләме сугышка кадәргенең җитмеш процентына җитсә, 1927 елда – аны сизелерлек узып китә. НЭП һәм шәхси капитал үз эшен эшли – җимерелгән икътисад торгызыла, ил халкының тамагы туя. Күптән түгел ачлыктан авыллап-авыллап кешеләрен югалткан Россия 1927 елда чит илләргә өч миллион тонна икмәк сата. Ә аннан соң нәрсә, диясезме? Аннан соң, иптәш Сталин оятсыз рәвештә игълан иткәнчә, яңа икътисадый сәясәт «шайтанга олактырыла». Инде кирәге калмаганга күрә. Татреспубликада яңа җиңүләрне честь биреп сәламләрлек вазгыять урнаша лабаса: әле 1927 елда ук дәүләт файдасына 30 шәхси һәм арендаланган күн заводы конфискацияләнгән иде. 1929 елга сәүдәдәге шәхси сектор инде 29 проценка кими, ә сәнәгатьтә – алты процентка. Бер елдан ул бөтенләй юкка чыгарыла. Сәламәт көндәшлеккә шуның белән чик куела.

Нэпманнармы? Аларның эшен, әлбәттә, әлеге дә баягы ГПУ карагандыр. Нишлисең, алар истәлекләрен яңа буыннарга калдырмаган диярлек.



Бу темага кагылышлы материаллар белән тулырак **100.tatarstan.ru** сайтында таныша аласыз.

ТӘМУГКА ТИҢ ИКЕ ЕЛ



Корбаннар күләме буенча Россиянең Гражданнар сугышындагы югалтуларына тәңгәл һәлакәт Идел буе, Урал, Казахстан, Көнбатыш Себер, Көньяк Украина территорияләрен колачлый. 1921 елда башланган ачлык санаулы айлар эчендә берничә миллион кешенең гомерен өзә. Республика бәла-казаның нәкъ үзәгендә кала.

Ксения Сёмина **әзерләде.**

СОҢАРГАН ЯРДӘМ

1921 елның яз азагында ук күп кенә волостьларда, шул исәптән ТАССРның шактый кантоннарында, ашарга икмәк калмый. Ашлык, орлык запасларын продразверстка отрядлары кырыпсебереп җыеп китә, еш кына кирәгеннән артыгын да тартып ала. «Иртә яздан хәзергә кадәр бер тапкыр да яңгыр яумавы һәм июньдәге эсселек уҗымнарны да, сабан ашлыгын да, шулай ук бакчалардагы яшелчәләрне дә тулысынча көйдереп бетерде... – дип яза 1921 елның июль уртасында Чистай кантоны Ерыклы волосте башкарма комитеты рәисе үзенең докладында. – Ач халык инде күптәннән төрле суррогатлар белән туклана... һәм, киләчәктәге коточкыч хәлләрдән куркып, кая булса да китү ягын кайгырта... Инде хәзер үк Югары Никиткино авылында гына да 28 июньнән 3 июльгә кадәр алты кешенең ачтан үлүе һәм ачлык китереп чыгарган 289 авыру очрагы теркәлде... Ап-ак ябык чырайлы күләгәләрдәй кешеләр үлемгә хөкем ителгәннәрне хәтерләтә...»

1921 елның 18 июлендә Ачларга ярдәм күрсәтү үзәк комиссиясе (ЦК Помгол) төзелә, берничә көннән соң мондый комиссия ТАССРда да оештырыла. Ачлык котырынган төбәкләр корылыктан зыян күрмәгән республикаларга беркетелә. Татарстанны Вологда, Владимир һәм Петроград губерналары тәэмин итәргә тиеш була. Язучы Максим Горький Европа һәм Америка илләре җитәкчеләренә Россиядәге ачларга булышуларын сорап мөрәҗәгать итә. Дөньяның фән һәм иҗат җәмәгатьчелеге вәкилләре Советлар иленә ярдәм күрсәтүчеләр сафын тулыландыра. Алар арасында Альберт Эйнштейн, Анатоль Франс, Бернард Шоу исемнәре бар. Төньякны өйрәнүче танылган тикшеренүче Фритьоф Нансен ачларга ярдәм күрсәтү буенча гомумевропа оешмасын җитәкли. Идел буйлап барып, ул балалар йортларында, хастаханәләрдә, үләргә җиткән авылларда була. Милләтләр Лигасына мөрәҗәгате игътибарсыз калдырылгач, Совет Республикасына Нансен үзе зур суммада акча бирә.

Ачлык хөкем сөргән башка районнардагы кебек үк, 1921 елның көзенә ТАССРда Американың ачларга ярдәм күрсәтү администрациясе, берничә халыкара оешманы берләштергән Нансен миссиясе, Халыкара эшчеләр комитеты, Халыкара балаларга ярдәм күрсәтү берлеге һәм башка комитетлар эшли башлый. Әмма бу ярдәм генә җитми...

ҮЛЕМГӘ ХӨКЕМ ИТЕЛГӘН ТЕРЕЛӘР

1921 елның декабрендә Татреспубликаның 12 кантонын карап кайткан тикшерүче үзенең «Азык-төлек һәм санитария шартлары турында доклады»нда түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Язын республикада, Казанны да кертеп, 3 366 719 кеше яшәгән. Хәзерге вакытта әлеге сан якынча 2 892 200 кешегә тәңгәл. Кимү 14 процентны тәшкил итә...» Докладчы фикеренчә, халыкның нибары 12 проценты гына кышны чыгачак, 2,3 миллионга якын кеше ачлыктан һәм авырулардан үләргә хөкем ителгән.

«Иделнең көнбатыш ярындагы Зөя, Буа, Тәтеш кантоннары ачлыктан бигрәк тә нык зыян күрә... Анда хәл шулкадәр авыр ки, Америка администрациясе һәм Помгол күрсәткән ярдәм генә, шартлар бераз яхшырак булган кантоннардагы кебек, хәтта вакытлыча да җиңеллек китерә алмый... Тиф, бигрәк тә тимгелле

Табиблык-ашату поездына сузылган чират.

тиф, Лаеш һәм Спастан кала, барлык кантоннарда да бик тиз тарала. Күрәсең, Лаеш районында ул басылгандыр, Спаста исә бөтен кеше диярлек аның белән чирләп чыккан инде. Буа кантонында тимгелле тиф аена 300 процентка кадәр арта, күп авылларда халыкның яртысы аны йоктырган инде. Тәтеш турында да шуны ук әйтергә була. Арчада тифның таралышы 400 процентка кадәр җитә, – дип дәвам итә докладчы. – Барлык территориянең 90 процентын үтеп, мин бер генә кисәк булса да ипи яки ат итеннән башка бүтән ит күрмәдем. Күп урыннарда хәтта төп суррогат булган алабутаның да поты 120–150 000 сумга җитә».

«Татреспубликаның 13 кантонында халыкның 85 проценты ачлыктан интегә. Бары 463 755 кеше генә тук була. Калганнары алабута, сөяк оны, балчык һәм башка төр суррогат ашый. Мәче, эт, күсе һ.б.ларның үләксәләрен ашау – гадәти күренеш», – дип яза Помгол рәисе Вознесенский 1921 елның мартындагы докладында. Декабрьдә исә, кешелекнең иң соң чигенә җиткән адәмнәр, инде хайван үләксәләре белән генә түгел, ә кеше мәетләре белән дә туклана башлый, кайчагында хәтта тере кешеләрне дә ашаудан тайчанмыйлар...

КЕШЕГӘ ХАС БУЛМАГАН ФАҖИГА

Ач балаларга ярдәм итү Рус-Америка комитетының Спас кантоны әгъзасы иптәш Бариновның «Әти-әнисе ашаган 7 яшьлек малай мәетен тикшерү мәсьәләсе буенча» хәбәреннән:

«Беренче булып гаепләнүченең каенатасы Монаховтан сорау алынды. Ул 7 яшьлек оныгы – Малов Феофил Степан улының ачлыктан интегүе, зәгыйфьләнүе һәм 1 гыйнвар иртәсендә үлүен раслады:

– Минем Феофилны җирләргә кирәк дигән тәкъдимемә Малов улының мәетен ашарга җыенуын әйтте. Мин, әлбәттә, моңа ышанмадым һәм чиркәүгә киттем, анда руханига Маловның ниятен җиткердем... Чиркәүдән кайткач, мәетнең башы, кул-аяклары булмавын күрдем. Минем: «Кая куйдыгыз?» дигән соравыма, Малов, без хатыным белән аларны пешереп ашадык инде, диде...»

«Татреспубликаның Спас кантоны халкына кичекмәстән ашыгыч ярдәм һәм Үзәктән азык-төлек кирәк. Әгәр ашыгыч ярдәм күрсәтелмәсә, кеше ашау очраклары артачак, үлем-китем турында исә сөйләп торасы да юк инде, Спас кантонына Үзәк алдында чаң сугарга кирәк, дип саныйм...» – дип нәтиҗә ясый Бариновның.

Күп кенә башка кантоннарда да мондый куркыныч хәлләр булып тора. Бу турыда мәгълүмат ТАССР Үзәк Башкарма комитеты каршындагы Ачларга ярдәм күрсәтү үзәк комиссиясенең архив папкасында саклана.

«Февральдән (1921 ел – ред. иск.) 5нче номерлы хәбәр: Сәпәй волосте башкарма комитеты 10 февральдә хәбәр итүенчә, Азнакай авылында гражданин Фәбрулла Фарукин үзенең өч айлык улын суеп ашаган, тикшерү бара».

Югары Байлар авыл советы рәисе Садыйковтан хәбәр: «1922 елның 28 гыйнварында Югары Байлар авылында гражданка Шәмсениса Сәхабиеваның кызы Рәхилә ачлыктан үлгәч, ач ана кызының күкрәк читлеге һәм корсагын ярып, бөтен эчке әгъзаларын казанда пешереп ашаган, аннары үзе дә үлгән. Моны аның балалары – 11 яшь-

Ачлык белән көрәшү өчен ТАССР Үзәк башкарма комитеты тарафыннан «Ачлык белән көрәшүчегә» дигән күкрәк билгесе булдырыла, аңа грамота да өстәп бирелә. «Көрәшче»ләргә һәртөрле таныклыклар белән бүләкләр дә каралган була. Әлеге күкрәк билгесе асылда орден дәрәҗәсенә ия булган.

Идел буендагы караучысыз балаларга медицина ярдәме күрсәтү.

Балалар Казандагы Америка комитетыннан ашау белән тәэмин ителә, 1921–1922 еллар.

Текстта 1921-1922 еллардагы «Известия ЦК РКП(б)» һәм 1921 елгы «Крестьянин» газеталарыннан, 1921–1922 елларда басылган «Коммунистический путь» журналыннан, һәм шулай ук ТАССР Үзәк Башкарма комитеты каршындагы Помгол Үзәк комиссиясенең 1922 елгы архивыннан өземтәләр кулланылды. Материаллар Татарстан Республикасы Үзәк архивыннан алынды.

лек Фәридәбану белән 8 яшьлек Әхмәтгариф карап торган. Әлеге мәетләрне тикшерү өчен, Югары Байлар авыл советының Күзкәй фельдшерлык пунктыннан табиб яки фельдшер чакыртуын сорыйбыз...»

Чистай, Кантон башкарма комитеты, телеграмма: «Күтәмәдә 3 кешене ашауларын хәбәр итәбез җинаять ачыкланган Башкарма комитет рәисе урынбасары Якупов».

ТОРМЫШ ТИГЕЗЛӘМӘСЕ

«Известия ЦК РКП(б)» газетасының 1921–1922 еллар архивыннан: «Иделдә ачлык куәтләнә, 13 миллионлап кеше – республика халкының уннан бер өлеше ачлыктан интегә... Хәзерге вакытка кадәр бик аз яки очраклы гына ярдәм күрсәтелә, анда әле хосусый хәйриячелек формалары өстенлек итә, азык-төлек ярдәме акча ярдәменнән шактый калыша һәм халыкның реаль ресурсларына бөтенләй туры килми... Партиянең төп өндәмәсе – «Ун тук кеше бер ачны ашата» – бернигә дә карамастан үтәлергә тиеш. «Партия түбәндәге бурычларны үтәүне тәэмин итәргә тиеш: һәр эшче үз ихтыяры белән аена 3 фунт акчасын биреп барсын; һәр утыз эшче һәм хезмәткәр бер баланы уллыкка алсын; һәр крестьян ач кешегә ай саен, кимендә, 3 фунт икмәк бирсен; һәр ун йорт бер баланы асрамага алсын... Ачлыкны киметүдә авылның өлеше күбрәк булырга тиеш. Әмма крестьяннар ачларга ярдәм эшенә хәзергә кадәр тиешле дәрәҗәдә тартылмаган...», – дип белдерә 1922 елның февраль азагында РКП(б) ҮК секретаре Вячеслав Молотов.

Бу чорда ТАССРда балалар өчен паек нормасы аена 7,5 фунт (3,4 кг) он һәм 15 фунт (6,7 кг) бәрәңге, олылар өчен 3,75 фунт (1,7 кг) он һәм 15 фунт бәрәңге тәшкил итә. Әмма, шул исәптән ТАССРга да, 1921 елның көзендә 3 миллион пот ашлык, 1922 елда 5 миллион пот чамасы орлык җибәргән шеф губерналарның ярдәме нәтиҗәсендә, көзге чәчү кампаниясе уңышлы үткәрелә. Бу һәлакәт масштабларының кими башлавына өмет уята...

Әмма әле 1922 ел азагында да җитди вазгыять саклана. «Статистика идарәсе 1922 елда ашлыкның тулаем уңышы (ашлыкка әйләндереп өстәлгән бәрәңге белән бергә) 32 775 297 потка җиткән, дип исәпли. Халык әлеге микъдардан 5 000 000 потын уҗым чәчүгә, 3 500 000 потын азык-төлек салымы (!) түләүгә, тулаем алганда, барлыгы 8 500 000 пот тоткан. Санап чыгарсак, 24 275 297 пот кала. Азык-төлек халык комиссариаты нормаларыннан чыгып, халыкның азык-төлеккә ихтыяҗы җан башына 12 поттан дип исәпләгәндә, Татреспубликада яшәүче 2 677 283 кешегә 32 127 396 пот таләп ителә. Ягъни 7 852 099 пот җитешми, һәм сабан орлыгына бернәрсә дә калмый. Халык, кулланумы киметеп, норманы җан башына 7,5 потка гына калдырса, язгы чәчү өчен орлыкны экономияләп була. Әмма бу чара да 4 200 000 поттан артыграк орлык бирә алмый...», – дип яза ТАССРның беренче игенчелек халык комиссары Юныс Вәлидов.

Икмәк, халык нормасы, шулай ук профсоюзлар, армия, авыл һәм ирекле оешмалар күрсәтә торган ярдәм күләме нормаларын үз эченә алган башка тигезләмәләр, гаять күп көч түгеп булса да, нәтиҗәдә чишелә. Әмма ТАССРда халык саны 1926 елда гына «революциягә кадәрге дәрәҗәсенә» җитә – ул чактагы җанисәп республикада 3 369 000 кеше яшәвен күрсәтә...

ТЕЛЕМ МИНЕМ – ДУСТЫМ МИНЕМ
ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН
КАМСКИЙ СУДАК
«ТАТАРСТАННЫ» ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕНДӘ УКЫГЫЗ!
Реклама. 16+

1923–1926



АТЛАР ТЕЛЕН АҢЛАГАН «ТАТАР ЧЕГӘНЕ»

Евгений Сухов һәм ТР ЭЭМ музее, Александр Ефремов фотолары

Хәзер генә ул атны циркта яки ипподромда күреп була, элек ул машина һәм трактор урынына бөтен җирдә кулланылган. Революциягә кадәр дә, аннан соң да бик озак вакыт әле шулай булган. Инде Гагарин космоска очкан, Казанда исә һаман башлары түбән иелгән боек атлар заводтан кибетләргә кайнар икмәк ташыган, ишегаллары буйлап икенчел чимал һәм ашханәләрдән азык калдыкларын җыеп йөргән. Бу җигүле транспорт олаучылары – кояшта каралган, икмәк һәм тирес исе сеңгән какча гәүдәле татарлар – нинди дә булса трест штатында торган. Атны да трест асраган, тик аңа хезмәт хакы солы белән түләнгән…

Автор:
Гадел Хәеров

Татарлар һәм башкортлар элек-электән оста ат караучылар буларак танылган. Мәскәүдә извозчикларны «барабыз» дип йөрткәннәр. Казандагы Печән базарында, шулай ук Бөгелмә, Бәләбәй, Стәрлетамакта бахбайларны көтүләре белән сатканнар. Анда тере товар алырга бөтен Россия сәүдәгәрләре агылган. Биредә нәселле чабышкылар булмаган үзе, нигездә чыдам, талымсыз кыргыз атларын куып китергәннәр – аларның тамырларында Чыңгызхан урдасы Европаны яуларга җилдергән тәбәнәк буйлы монгол «адуу» токымы каны аккан.

«АТЫҢ БЕЛӘН ЭТЕҢӘ ЫШАН, ТИК ХАТЫНЫҢА ЫШАНМА»

Ат телгә алынган татар халык мәкальләре шактый. Татар әдәбиятында да атлар еш очрый. Классигыбыз Әмирхан Еникинең «Җиз кыңгырау» хикәясен ачсак, аның бик яратып авыл атын сурәтләвен күрербез: «... *һәм сары ат, аның кулын тоеп, озын яллы матур башын аккоштай кырынрак бөгеп, кыска аякларын күз иярмәс тизлек белән юлны типчегәндәй вак-вак кына алыштырып, йомры янбашын тибрәтә-тибрәтә юргалап кына элдерергә тотынды*».

Авыл кешесе өчен ат – алыштыргысыз җан иясе ул. «Атсыз» кеше исә – беркем дә түгел. Кесәсендә җил уйнаган хәерче! Үзенә нинди дә булса ат кисәге сатып алмыйча, ул яучы да җибәрә алмаган. Атсыз калу – олы хәсрәт. Аны төнгелеккә абзарга бикләп, этләрне чылбырдан ычкындырып калдырганнар. Алла сакласын, яман кешеләр урлап китә күрмәсен, янәсе. Якын-тирәдә чегәннәр пәйда булса, ат хуҗалары, сәнәк белән коралланып, печән кибәнендә төн кунган. Ярый инде чегән – аңа нәрсә әйтәсең, ә менә үз якташларың ук атыңны урлап далага качса, нишләргә, кая барырга?

Казан губернасының үзенең «татар чегәне» булган. Аның даны еракларга таралган. Шәкүр каракның ни белән шөгыльләнүен хакимият тә белгән, әмма шунысы гаҗәп – аның кайда яшәвен, ниләр майтаруын яхшы белсәләр дә, тота алмаганнар. Бәлки тотасылары килмәгәндер. Урядникның үзенә дә өлеш чыгарганнардыр, күрәсең, югыйсә бу караклар өеренең тотылмас булуын берничек тә аңлатып булмый бит.

Шәкүр – ат караклары нәселеннән. Аның бабасы, әтисе, агай-энеләре, уллары, бертуганнарының балалары... – барысы да ат урлаган. Вазыйфалары төгәл бүленгән: кемдер разведкага бара, кемдер каравылда тора, кемдер урлый, кемдер «товарны» урманга яшерә, кемдер ат сәүдәгәре белән сөйләшә, килешә, кемдер кирәкле кешеләрне сатып ала.

Совет хакимияте генә караклар оясын пыр тузгыта, ниһаять. Бер кизәнүдә юкка чыгара! Гәрчә революциядән соң бик аз вакыт үткән, илдә бөлгенлек хөкем сөргән, җинаятьчелек котырынган, тикшерү органнарыннан иске кадрлары киткән, яңалары әле тәҗрибә туплап өлгермәгән вакыт була. Органнар рәтләп формалашып та бетмәгән мәл бу. Шундый кыска вакыт эчендә аларның Казанны гына түгел, күрше губерналарны да куркытып торган ат караклары бандасының башына җитүе гаҗәп хәл!

АТ ПСИХОЛОГЫ

Әмирхан Еникинең шул ук хикәясен укуны дәвам итәбез: *«Авылдан кырга чыккач, абзыкай дилбегәне миңа бирде. Ат та шунда ук, дилбегәнең кем кулына күчүен сизеп алды булса кирәк, юргалап баруыннан туктап, гади юыртуга күчте. Мин, тарткалап, суккалап карасам да, аны барыбер тыңлата алмадым»*.

Ат чит кешене якын җибәрми, ул сезгә пони түгел. Тешләшә, киреләнә башлый, өйрәтелмәгән айгыр кебек дулап, җайдагын иярдән бәреп төшерә. Кешни, аңа кушылып этләр өрә. Бөтен кешене аякка бастыра! Ә крестьяннар урядникны көтеп тормый бит, шунда ук самосуд ясыйлар. Каракны колга һәм камчылар белән үтерә язганчы яралар. Һәм аларны аңлап та була. Ат карагы хуҗалыктагы иң кыйбатлы малга, туендыручыга нәфесен суза бит. Димәк, шул кирәк аңа...

Шәкүр атлар телен белгән, диләр. Теләсә кайсы атны буйсындыра алган. Колагына нindидер назлы сүз пышылдап, сохари белән сыйлауга ук, тегесе, бер дә киреләнмичә, гашыйк кыз кебек артыннан ияреп тә китә икән. Тавыш чыкмасын һәм эзе калмасын өчен, Шәкүр ат тоякларына киез ката кидерә торган була.

Күбрәк вакыт үткән саен, халык аны яхшы сыйфатларга баета бара. Юлбасар игелекле һәм гадел кешегә

әйләнә. Билгеле, ул ярлыларны таламый (аксак алаша аңа нигә кирәк булсын?), ә менә байларныкын урлый да, фәкыйрьләргә тарата. Менә шундый татар Дубровские килеп чыга. Әмма боларның кайсы чын, кайсы ялган соң?

КАРАК НИЧЕК ӘДӘБИЯТКА КИЛЕП ЭЛӘККӘН?

Казан язучысы Евгений Сухов, Чүти каракларының җинаять эшләрен өйрәнеп, 1990 нчы еллар башында Эчке эшләр министрлыгы (ЭЭМ) архивында берничә ай утыра. Аннары әлеге материаллар, тарихи романга әйләнеп, Татарстан китап нәшриятында басыла. Бу Суховның беренче китабы була, хәзер исә алар инде киштәгә дә сыймый – Мәскәү нәшриятларында миллионлаган тиражлар белән чыккан 130 криминаль һәм тарихи роман өчен саллы гына китап шкафы кирәк. «Алмазы Сталина» дигәне буенча 2016 елда режиссер Борис Казаков фильм төшергән, кайберләре буенча Леонид Каневский алып барган «Следствие вели…» тапшырулары әзерләнде.

Шәкүр карак турында иҗат юлының иң башында – 1994 елда язган Евгений күптән инде Австриядә яши, әмма үзенең туган җирен онытмый. Һәм менә быел җәй мин аның белән очраклы рәвештә Пушкин урамында очраштым. Яшьлек елларын, ул чактагы Казанны, уртак танышларны искә төшердек, аннары җинмин аннан «Шәкүр карак» («Шакур-карак») романы турында сораштым.


Язучы Евгений Сухов.

– Женя, ничек башланды бу мавыгуың? Әлеге «намуслы» разбойник сине нәрсәсе белән җәлеп итте?

– 1992 елда язучы Диас Вәлиев алып барган әдәби остаханәгә (дәресләр «Комсомолец Татарии» редакциясендә үткәрелгән – **ред. иск.**) ЭЭМ матбугат үзәгеннән Әнвәр Маликов килде һәм совет милициясе, тикшерүчеләр турында нәрсә дә булса язарга тәкъдим итте. Әлбәттә инде, ул позитив булырга тиеш иде. Дистәләп кеше теләк белдерде. Архивта эшләү мөмкинлеге тудырылачак, дип ышандырдылар. Җинаять эшләре белән танышырга, дәлил булырдай әйберләрне тотып карарга, тикшерүчеләр белән очрашырга мөмкин иде. Мине ике эш – Шәкүр карак һәм Кормаков бандасы хакындагылары – җәлеп итте. Татарстан ЭЭМ музее директоры Людмила Мещерякова күп кызыклы нәрсәләр сөйләде. Ул җинаять эшләрен бик яхшы белә иде. Сүз уңаеннан, аннары драматург Туфан Миңнуллин да, «Ат карагы» пьесасына материал җыйганда, минем эздән китте. Шул рәвешле карак әдәбиятка үтеп керде һәм «икенче гомерен» башлады.

– Ат карагының җинаять эшендә ничә том иде?

– Күп. Бер кырыклап бик калын папка булгандыр. Банданы закон кысаларында бик каты тикшергәннәр. Зыян күрүчеләрнең гаризалары да, үз гаебен танулар да, шаһитлар күрсәтмәләре дә, карау актлары, сорау алулар да тәфсилләп тупланган. Нәрсәдер машинкада басылган, кайберләре русча һәм татарча (ул чакта гарәп шрифты белән язганнар) кулдан язылган. Андыйларын русчага тәрҗемә иткәннәр. Җинаятьчеләрнең фотосурәтләре дә беркетелгән. Шул көннәр һәм вакыйгалар атмосферасына чумып, мин көннәр буе архивта яттым. Кичкә таба колагыма ат тоягы тавышлары һәм ат карагының сызгыргалап алуы ишетелә башлый иде. Мин әле

Шәкүр Рәхимов бандасы элеккеге Родионов исемендәге Затлы туташлар институты паркында – хөкем эшләре барган вакытта. 1926 ел.

Родионов исемендәге Затлы туташлар институты бинасы.



– Мәчетләр төзегән, ятимнәргә, янгыннан зыян күрүчеләргә булышкан, диләр...

– Булышкан, әмма бу, шуның белән беррәттән, шәкүрнекеләргә 1923 елда Ульяновск губернасындагы авыл хастаханәсен талап чыгарга да һич комачауламаган. Ул чакта алар барлыгы 150 мең сумлык савыт-саба, сабын, урынҗир кирәк-яраклары, күлмәк-ыштан, ашъяулык-тастымал урлый. Димәк, бу гади караклар булып чыга...

– Ул нинди булган? Мөгаен, кулга алынганнан соң, милиция фотографы төшергән сурәтләр аның бердәнбер рәсемнәредер?

– Каракүл папаха кигән, 63 яшьлек чал чәчле мөлаем бер карт, асылда. Какча гәүдәле. Кем икәнен белмәсәң, авыл мулласыдыр, дип уйлап була. Ат урларга барыр алдыннан Шәкүр намаз укый, Аллаһтан ярдәм сорый торган була. Игелек һәм явызлык турында менә шундый үзенчәлекле күзаллау хас була аңа. Сүз дә юк, ул урлашуның зур гөнаһ икәнен аңлаган, әмма туктый алмаган. Караклык аны үзенә суырып алган. Ул инде үзе төзегән, яхшы оешберәр бандитка, әле берәр тикшерүчегә әйләнәм, алар тормышы белән яшим. Өйгә кайткач, «Москва» машинкасында бармакларым авыртканчы таңга кадәр басам... Бик мавыгып эшләдем...

– Син ничек уйлыйсың, Шәкүр – каракмы, әллә халык каһарманымы?

– Әлбәттә, карак! Нәселдән килгән, профессиональ, рәхимсез җинаятьче. Ул вөҗдан газаплары кичермәгән. «Язмышым шундый, нәселебездә бөтен кеше ат карагы, бу «һөнәрне» миңа васыять итеп калдырдылар», – дип әйтә торган булган. Ул башка бернәрсә дә эшли белмәгән. Әйтергә кирәк, Шәкүр әйдаман, лидер, сөйкемле сөякле кеше дә булган. Өйрәтелмәгән айгырны да тынычландыра, теләсә кайсы кешене дә кызыксындыра, үзе артыннан ияртә алган. Салмак кына, ышандыргыч итеп сөйләгән. Гипнозлау сәләтенә ия булган. Аңарда ниндидер бер эчке куәт сизелеп торган. Аны хөрмәт иткәннәр, аның белән санлашканнар. Таҗ кидерелмәгән законлы карак дип әйтергә була! Әлбәттә, фәкыйрьләр ярдәм сораса, ул булышкан. Кемгәдер ун тиенлек, кемгәдер бер сумлык акча яки үз өстеннән салып казакиен биргән, кемгәдер ат та тәтегән. Урланган ат, билгеле. Хәйләкәр булган, шул рәвешле якташларын үз ягына аударган, җинаятендә катнашучы итеп калдырган. Милиция пәйда булса, алар тизрәк хәбәр биргәннәр. Җинаятьчеләр бандасын кулга алырга килгәч исә хәтта сәнәк күтәреп якларга да чыкканнар. Әйе, шулай да булган. Шул вакыттан бирле ат карагының ватанында – Кайбыч районы Чүти авылында – бу бандитны милли каһарманга санийлар. Хөрмәтләп, «Шәкүр бабай», дип йөртәләр!



тырылган структураның тоткынына әйләнгән. Бу гаилә кланы булган, анда читләр кертелмәгән. Чүти якларында берәр чит кеше күренсә, Шәкүргә шунда ук бу турыда җиткергәннәр. Бөтен җирдә үз кешеләре сакта торган – милициядә дә, урланган атларга мөһерле «паспортлар» бирә торган конторaларда да. «Паспортсыз» атны сатуы кыен булган, болай да ярты бәясенә генә биреп җибәргәннәр. Урланган мал белән хәзерге Үзәк универмаг урнашкан урында, Мокрая урамында сәүдә иткәннәр. Ул чакта анда бөтен җир тирескә баткан булган. Яз җиткәч, сасы су әйләнә-тирәгә таралган. Бик яхшы оештырылган җинаятьчел төркем булганга күрә, аларны озак вакыт буе эләктерә алмаганнар да инде. Засада оештыруга ук, шайка ничектер сихерле рәвештә юкка чыга торган булган...

– Тик шулай да эзләренә төшкәннәр бит. Ничек эләктерделәр икән?

– Чекистларның берсе Шәкүр Рәхимовның туганына өйләнгән. Яратыпмы, әллә кемнеңдер кушуы буенчамы, белмим, әмма карьерасының шуннан соң югарыга үрләве хак. Бу туйдан соң Шәкүр каракның капкачына аргамак төшерелгән алтын сәгате аның бандасының соңгы ай һәм көннәрен саный башлаган да инде.

Сөйләшә-сөйләшә Кремль калкулыгындагы элекке онкология хастаханәсенең озынча бинасы янына килеп җиткәнебезне сизми дә калганбыз. Кирмән дивары артындагы бинаның кырый тәрәзәләренә күрсәтеп, Сухов хикәяләвен дәвам итте:

–1926 елның 17 декабрендә аларны нәкъ менә шушында атып үтергәннәр. Ерактагы камерада. Элек биредә төрмә булган. Мин ул камераны җентекләп карадым, өйрәндем. Китап язганда бу мөһим – барысын да ишетеп торган диварларны тотып карау, аңа сөяләп тору... Эш барышын «Красная Татария» газетасы яктыртып барган. Җәмәгатьчелек тә бик кызыксынып күзәткән, билгеле. Миңа хөкем карарын гамәлгә ашырган кешенең адресын да бирделәр. Бу – җинаятьчеләрне эзләү-тикшерү бүлегенең элеккеге башлыгы Мәхмүт абый иде, фамилиясен хәтерләмим (ТАССР ЭЭХК Татцентророзыск башлыгы Мәхмүт Мөхәммәтҗанов. – *Ред.иск.*). Аның янына Арчага киттем. Ул чакта инде 101 яшендә булса да, хәтере яхшы иде. Аның бөтен детальләрне хәтерләве гаҗәпләндерде. Ул вакытта шайканың 78 әгъзасы кулга алынган, 15 бандитка үлем җәзасы бирелгән. Атып үтерү процесссы турында да сөйләде ул миңа. Иртәгә җәза үтәлсе дигән көндә ТатЦИК бинасыннан төрмәгә телефон чыбыгы сузганнар, аның буенча суд карарының гамәлгә ашырылуы турында доклад тыңланылган. Мәхмүт абыйга, төрмә башлыгына һәм прокурорга «Наган» системасындагы револьвер биргәннәр. Барысы да тыныч, эшлекле үткән. Җинаятьчеләрне беркая да алып чыкмаганнар, подвалга төшермәгәннәр, дивар буена тезеп бастырмаганнар, күзләрен бәйләмәгәннәр. Камерада ук атып үтергәннәр. Ишеген ачып, кизү кулындагы телефон аппаратына: «Ат каракларының берничәсе утыра торган камераны ачтык», «Исемлекне тикшерәбез», «Хөкем карарын укыйбыз», – дип хәбәр бирә барганнар. Икенче башта исә тыңлаганнар: «Автономияле Татар Социалистик Республикасының эшче, кызылармияче һәм крестьян депутатлары Советы исеме белән...» Аннары ату тавышы яңгырый, кычкыру, ыңгырашу ишетелә. Каршылык күрсәтергә маташканнарга беренче булып аталар. Шәкүр Рәхимов үзе исә намазлыгына утырып дога укый башлый, аңа өстән, түбәтәенә төзәп аталар. Пуля тай тиресе белән тышланган Коръән китабын тишеп чыга. Җәсәдләрен туганнарына бирмиләр, шәхси әйберләрен, шул исәптән Коръәнне, кайтарып бирәләр. Аларны кеше күрмәгәндә каядыр Казан читенә алып чыгып җирлиләр. Фаразларның берсе буенча, бу хәзерге «Мәскәү – Свердловск» тимер юлы үтә торган чокыр була. Малай чакта без еш кына бу ерынтыда уйный идек. Бер язда, кар эреп, чокыр хасил булгач, аның төбендә кеше сөякләрен күрдек. Мин менә хәзер уйлап куйдым – Шәкүр карак һәм аның әшнәләренең сөякләре булмадымы икән бу?..



КАРА ЮРГАҢНЫ БИШ КАТ ЙОЗАК
АСТЫНА ЯПСАҢ ДА,
БАРЫБЕР УРЛАП ЧЫГАРМЫН...*

– Синең китабыңда уйдырмалар күпме?

– Күп түгел, мин документлардан ерак китмәскә, дөреслеккә хилафлык китермәскә тырыштым. Әмма романның үз законнары да бар бит. Шунлыктан мин Шәкүрнең хатыннарын хыялымдагыча сурәтләдем (аларның фотолары да, тышкы кыяфәтләрен тасвирлаулар да сакланып калмаган), шулай ук банданы саткан кияүнең холкына башкарак төсмерләр өстәдем. Кайбер вакыйгаларны үземчә сурәтләдем. Әмма бик сак кыландым. Кульъязма әзер булгач, ЭЭМ кешеләре аның белән танышырга теләр, дип уйлаган идем, әмма авыр 90 нчы еллар җитте, болганчык чор башланды, аларның әдәбият белән кызыксынырга вакыты калмады. Мин моңа хәтта шатландым да, чөнки кульъязмам цензура иләге аша үтеп кыскармады. Татарстан китап нәшриятына илтеп бирдем. Бераз вакыттан соң кульъязмамның хуплануын хәбәр иттеләр, тик каты тышлыклары беткән икән. Мин йомшак тышлыкка ризалаштым. Романның басылып чыгуын Бауман урамы буйлап барганда белдем. Карыйм – чия төсендәге тышлыкка исемем язылган китапны сатып утыралар. Ул көнне миңа фән кандидатлыгы өчен эш хакын биргәннәр иде, берьюлы биш данә сатып алдым – беренче китабым бит! Барысы да шул китаптан башланды да инде... ■

* «Неуловимые мстители» фильмындагы җырдан.

1922

ЯҢА РЕСПУБЛИКАГА – ЯҢА ТЕАТР

1922 нче ел. Агарту халык комиссариаты Кызыл Октябрь исемендәге Беренче дәүләт үрнәк драма татар театры булдыру турында карар кабул итә. Яңа оешкан ТАССР өчен бу олы мәдәни вакыйга була. Татар мәдәнияте өчен яңа дәвер башланган чор.

Ольга Туманская **әзерләде.**

ТЕРЕ ТАРИХ

...Рояль артында – Салих Сәйдәшев. Аны кабинетка бикләгәннәр! Никадәр генә ялынса да, үгетләсә дә, хезмәттәшләренең күңеле йомшармый – композиторны чыгармыйлар. Тинчуринның «Кандыр буе» музыкаль драмасына вәгъдә иткән партитурасын язмый торып чыгармаячаклар да. Кемнеңдер кинәт сак кына итеп: «Салих абый!» – дип дәшкәне ишетелә. Ишек артында актриса Сара Садыйкова тора, аңа дигән ария әзер түгелме икән, дип белешергә килүе. «Үзең яз!» – дип ачу белән җавап кайтара талчыккан Сәйдәшев. Ә иртәнгә инде ноталар язылган кәгазь битен ала. Уйнап карый да ишек аша гына: «Карале, начар түгел бит!» – дип кычкыра.

Әлеге сюжет татар театрының 110 еллыгына багышланган «Дәрсе гыйбрәттер театр» спектакленең бер өлеше булып киткән, чөнки беренче татар профессиональ труппасы совет республикасына кадәр күпкә элгәре – 1907 елда ук барлыкка килгән. Спектакльнең идеясе Галиәсгар Камал исемендәге театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевнеке. Текстны яшь шагыйрь һәм драматург Рүзәл Мөхәммәтшин язган. Әдәби бүлек мөдире, театр тәнкыйтьчесе, шулай ук татар театры тарихы белгече Нияз Игламов автордаш булган. Без аның белән узган гасырның илһамлы 20нче елларында һәм дәһшәтле 30 елларында булган вакыйгаларны искә төшерү өчен махсус очраштык.

Сүз уңаеннан, Сәйдәшев белән булган әлеге кызыклы вакыйганың чынбарлыкка туры килүе дә бик ихтимал, чөнки Гөлйөзем ариясе – Садыйкованың композитор буларак дебюты. Үз гомерендә ул берничә йөз җыр һәм 18 спектакльгә музыка язачак. Безгә исә әлеге тарих яңа барлыкка килгән республиканың милли театры пионерлары булган кешеләрнең иҗади масштабын күзалларга мөмкинлек бирә.

– Ул елларда татар театр сәнгатенең төп фигурасы, һичшиксез, Кәрим Тинчурин булган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Театрга җитәкчелек итәргә нәкъ менә аны чакыралар. Үзенең абруеннан файдаланып, Тинчурин Казанга революция һәм гражданнар сугышы вакытында төрле шәһәрләргә сибелгән, төрле шәһәрләрдә йөргән беренче театр труппалары «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» артистларын чакырып китерә. Ул елларда татар дөньясы киңрәк һәм бердәмрәк булган,



Кәрим Тинчурин – 1920–1930нчы еллардагы театр сәнгатенең иң күренекле шәхесләреннән берсе.

Фото: Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры музее архивыннан

шуңа да аларның күбесе Әстерхан, Симферополь, Мәскәү, Ленинград, Уфа, Троицк шәһәрләрендә милли труппаларны җитәкләгән. Сәхнә корифейлары белән бергә яңа театрга Салих Сәйдәшев, Һади Такташ кебек яшь талантлар да килгән...

АЗАТЛЫК РУХЫ

1923 елның җәендә бер журналда Кәрим Тинчуринның «Татар театры кайсы юлдан китәргә тиеш?» дигән мәкаләсе чыга. Ул иҗади интеллигенцияне чын мәгънәсендә кузгатып җибәрә, ел дәвамында вакытлы матбугат битләрендә әлеге темага җавап язмалар басыла – кешеләр бәхәсләшә, фикер алыша, тәкъдимнәр кертә... Бүгенге көндә бу турыда фикерләр каршылыгына карамастан, иҗади эзләнүләр, театраль тәҗрибәләр һәм иҗатта ирек чоры була ул.

...Театрда «Шлем» спектакленең премьерасы. Сәхнәдә – «кызылармиячеләр», залда да. Финал! Сәйдәшев маршы – диварлар селкенә. Марш тагын бер кат яңгырый. Тамашачы кызылармиячеләр, хисләренә түзә алмыйча, актер кызылармиячеләрне кочакларга сәхнәгә ыргыла. Әлеге вакыйганы пьеса авторы Габдрахман Минский күзәтеп тора.

20нче елларның репертуары күпкырлы булуы белән шаккатыра. Яңа заман каһарманнары турындагы эшләр белән беррәттән милли спектакльләр дә, рус һәм чит ил классикасы да куела – «Галиябану», «Гамлет», «Отелло», «Явыз Иван үлеме» спектакльләрендә ышандыра белеп уйный торган Хәлил Әбҗәлилов, кайнар канлы Мифтах Әбсәламов, драматик рухлы Мөхтәр Мутин, күпкырлы Гөлсем Болгарская балкый... Сезон саен афишага дистәгә якын яңа спектакль өстәлә. 1925 елда беренче милли опера – «Сания» сәхнәгә куела. Ә аннан соңгы ел үзе бер дәвергә тиң булып чыга: «Тинчурин – Сәйдәшев» дуслыгы нәтиҗәсендә «Зәңгәр шәл» спектакле туа. Ул озак елларга татар театрының бренды булып әверелә.

Шул ук вакытта театрда демократик тамашачы өчен көрәш бара: кичә генә авылдан шәһәргә күчеп килгән, театрдан үзенә нәрсә кирәген аңлап та җиткермәгән тамашачының сәнгати зәвыгын формалаштырасы бар әле. Хәер, бу аңлашыла да, театр үзе дә үзенә күрә бер бүленеш кичерә – беренчелеккә ике эстетик төркем дәгъва итә. Болар – Сул татар мәдәни фронты (СУЛФ) үз канаты астына радикаль сәнгать яклыларны җыйган һәм традицион формалар, пролетар проблематика, вульгар социологизм яклыларны берләштергән уңнар (РАПП).

– Күпмедер дәрәҗәдә әле күптән түгел генә барлыкка килгән татар театр сәнгатендә барысы да новатор булган, – ди Нияз Игламов. – Инкыйлабка кадәрге ачышлардан башлап, Хәрби коммунизм һәм Яңа икътисадый сәясәт чорының мәдәни ихтыяҗларына кадәрге эволюцион юл яклы булган Кәрим Тинчурин һәм СУЛФчы Сөйләйман Вәлиев-Сульва, үзәк юнәлеш тарафдары Евгений Вахтангов шәкерте Гомәр Дәвишев.

ЯКТЫДАН – КАРАҢГЫГА

Әлеге көрәшкә ноктаны... Максим Горький белән Владимир Немирович-Данченко куя. «Инкыйлаб хәбәрчесе» 1934 елда Совет язучылар берлегенең Беренче съездында дистәләрчә еллар буена СССР халыклары мәдәниятенең эзләнүләрен тигезләп торган төп иҗат методы – социалистик реализмның доктринасын яңгырата. Икенчесе исә Горькийның «Дошманнар»ын шундый итеп куя, ул бөтен театрлар өчен канунга әйләнә. Якут театрымы ул, үзбәкнекеме, Таировның камера театры яки Михоэлсның ГОСЭТымы – барысын да МХАТның эстетик параметрларына көйләнгән психологик сәнгать кысаларында «бер сызыктан сөрәчәкләр». Театрыбызны һәлакәткә илтүче әлеге процессның иң югары ноктасы Сталин дәверенең ахырына туры киләчәк...

– Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, 1927 елга кадәр безнең ил мәдәният чыганагы булып торган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Иң яңа, радикаль, авангард идеяләр өстә генә яткан ул чорда. Татар мәдәнияте өчен дә әлеге чор ренессанс дәвере була. Аның кайтавазы утызынчы еллар уртасына кадәр ишетелә, ләкин анда хәлләр катлаулана башлаган була инде...

Антифашистик хәрәкәтнең символы булган «Профессор Мамлок» пьесасы язучы Фридрих Вольфның каләме астыннан нәкъ менә 1934 елда – Гитлер хакимияткә килүгә чыга. Ә 1935 елда инде аны Гомәр Исмәгыйлов татар сәхнәсенә күтәрә, һәм ул зур уңыш белән бара. Шунысы игътибарга лаек: Фридрих Вольф әлеге эшне күргән һәм бик ошаткан.

– Вакыттан алда баручы режиссер-психолог, – Исмәгыйлов турында тәнкыйтьче Нияз Игламов шулай ди. – Ул фашизм белән килешү мөмкин түгел, дип үтә дә җитди,

Бүгенге көндә фикерләр төрле булса да, 20 нче еллар асылда иҗади эзләнүләр, сәхнә экспериментлары һәм фикереңне курыкмыйча иркен итеп белдерү чоры булган. Фотода – труппаның әнә шул мизгелләре.

«Профессор Мамлок» пьесасы үз заманында ук фашистларга каршы хәрәкәт символына әверелгән. Шунысы гаҗәп: ул татар театры сәхнәсендә 1935 елда, басылганнан соң күп тә үтмичә, куела. Фотода – пьесаның авторы Фридрих Вольф һәм спектакльнең режиссеры Гомәр Исмәгыйлев.

Шомлы 1930 нчы елларда Нәкый Исәнбәткә таланты шәркый сюжетлар һәм темалар артына качарга мөмкинлек биргән. «Хуҗа Насретдин»да ул текст эченә бик күп мәгънәләр яшереп калдырган. Фотода Сәхилә ролендә Гөлсем Камская балкый.

тирән спектакль куйган. Шулай да, спектакльне Молотов – Риббентроп Пакты төзелүгә репертуардан алалар. Шул көннән башлап, «фашистларча» сүзе Муссолини режимы, Франко Испаниясе яки Салазарның Португалиядәге тәртипләренә нисбәтле генә кулланыла башлый, Гитлер Германиясе белән бәйле бер дә искә алынмый.

Гомәр Исмәгыйлев репрессияләрдән качып котыла – режиссерның исеме «исемлеккә керүе» турында НКВД хезмәткәрләренең берсе кисәтә – таланты алдында баш июе була. Фанера чемоданын тотып, Исмәгыйлов башта Бохарага, аннан Сәмәркандка күчеп китә, анда перифериядәге үзбәк театрлары тормышында актив катнаша. Бөек Ватан сугышы башлангач, Вольф пьесасы буенча куелган спектакль яңартыла.

ИКЕ ДӨНЬЯ АРАСЫНДА

Совет халкы, гадел җәмгыять идеясе белән илһамланып, йөзләрчә заводлар кора, яңа шәһәрләр, юллар сала, чирәм җирләрне күтәрә – күпләр өчен, чыннан да, «яшәү яхшырак, күңеллерәк» була башлый. Ләкин Архангель зиратына куелган стела безгә башка нәрсәләр турында искәртә...

– 1930 еллар уртасына кадәр Мәскәү, Ленинград, Әстерхан, Орск, Свердловскида – бөтен ил буйлап! – дистәләрчә татар профессиональ дәүләт театрлары эшли, – дип сөйли Нияз Игламов. – Бер-бер артлы аларны яба башлыйлар. Татар театрын көчләп ТАССР чикләренә «куалап» кертәләр. 23 профессиональ театрдан икене генә калдыралар – Казанда һәм Минзәләдә. Сталин торган саен гайрәтләнә бара, һәм бу аның сәясәтенең хәйләкәр бер адымы була – «бүлгәлә һәм хакимлек ит». Күрәсең, милләтләр эшләре буенча халык комиссары итеп нәкъ менә аның куелуы очраклы булмагандыр. Сәясәтчеләрнең берсе дә – аңа кадәргеләре дә, аннан соңгылары да – милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә андый ук зур игътибар бирми. Башка беркем дә тулаем халыкларны сөргенгә озатмый, ил составындагы милләтләрнең территориаль картасын үзгәртми.

Иҗат кешеләре арасында кискен чистарту башлана. Репрессия машинасы татар мәдәнияте әһелләрен берәм-берәм үзенә йота, алар арасында күренекле драматурглар да, талантлы режиссерлар да, актерлар да була. Кәрим Тинчурин, Гали Ильясов, Фәтхи Бурнаш, Мөхтәр Мутин, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Мәхмүт Галәү, Гомәр Исмәгыйлов... Бу шәхесләрнең гаиләләре дә террор корбаны була хәтта. Шундый фаҗигале тарихларның берсе – татар шагыйре Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салиәскарова турында. Шагыйрьне шул елларда эзәрлекли башлыйлар, ә 1940нчы елда лагерьга озаталар. Унбиш ел Луиза иренә посылкалар җибәреп тора, хәтта кан доноры була – аның өчен акча түләгәннәр чөнки.

Репрессияләрдән котыла алганнарның да хәле көнләшерлек булмый. Берәүләр, Тинчуринның якын дусты, композитор Салих Сәйдәшев кебекләр, эшсез калып, очраклы эшләр булганга гына очын очка ялгап яшәргә мәҗбүр була. Театрда калганнарга яңа чынбарлыкта яшәүнең компромисс формаларын эзләргә туры килә. Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат... Алар каләме астыннан чыккан һәр пьеса иң элек органнарның өстәленә кереп яткан.

– Даими рәвештә стресс шартларында эшләргә туры килә аларга, – дип сөйли Игламов. – Һәм ул, аңлашыла инде, иҗади фикерләүне деградациягә китерә, чөнки автор яхшырак итеп языйм, дип түгел, ә репертуар комитеты аша ничек итеп үткәрергә икән, дип тырыша. Риза Ишморат үзе өчен заманчалыкны сайлый – 1930 нчы елларда ул корыч коючылар, чик саклаучылар, танкистлар турында яза. Таҗи Гыйззәт инкыйлабка кадәрге татар авылының укый-яза белмәвен, алпавытларның фәкыйрьләрне изүен, муллаларның һәм им-томчыларның халык җилкәсен кимерүен тәнкыйтьли. Нәкый Исәнбәткә исә талантының масштабы шәркый сюжетлы пьесалар кинаясе артына яшеренергә мөмкинлек бирә. «Хуҗа Насретдин»да ул каһарманнарының гыйбарәләре, андагы юллар арасына күп нәрсә яшерә. Нәкъ шуңа күрә ул бүген дә әһәмиятен югалтмады, ә Ишморат белән Гыйззәт исә, бер-ике әйберләреннән кала, театр өчен югалды дияргә була. Ә алар – әсәрләренең драматик структурасы, һөнәри дәрәҗәсе турында әйтәм – беренче урындагы талантлы кешеләр булган! Кечерәк масштабтагы талантлар турында әйтеп тә торасы юк.

– Сталинны акларга теләүче кешеләр бар, ул шәп менеджер булган, дип раслыйлар, – дип дәвам итә Игламов. – Имеш, репрессия корбаннары турында Солженицын китергән саннар күпертелгән. Бу чыннан да шулай – чынлыкта репрессияләнүчеләрнең өлеше гомуми халык саныннан якынча 1,5 процентны тәшкил иткән.

Фото: Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры музее архивыннан

Ләкин шунысын аңларга кирәк: нинди 1,5 процент бит ул! Аның күпчелек өлеше интеллигенция вәкилләре. Ул репрессияләрнең һәм чистартуларның атмосферасының ни дәрәҗәдә зарарлы булуын да аңларга кирәк: кешеләр караны кара, акны ак дип әйтергә курыкканнар бит.

ТИНЧУРИННЫҢ ЧЕТЕРЕКЛЕ ХӘЛЕ

Заһидә Тинчурина кулында Әстерханнан килгән журнал. Ә анда!..«Тинчурин әфәнде Әстерхан театры чибәрләре арасында» – фото астына нәкъ шулай дип язылган. Әлеге «тәртипсезлек»не күреп, Заһидә (билгеле, башка сәбәп белән!) ире янына юлга чыга. Ләкин шикләрнең урынсыз икәнлеге ачыклана – ул хатынына тугрылык саклый һәм һәрвакыттагыча бик күп эшли.

Әстерхан дәүләт татар драма театрында Кәрим Тинчурин спектакльләр куя. Ул анда 1924 елда ук, аны Казанда «театрның эше канәгатьләнерлек түгел» дип эшеннән бушатуга, китеп бара. Вазыйфасына башка кешене билгелиләр. Нибары бер сезон эчендә театр түбәнгә тәгәри, тамашачысын югалта. Тинчуринны кире кайтырга сорыйлар.

– Мин моны без әлегә кадәр белмәгән берәр тарих белән бәйледер, дип уйлыйм, – дип аңларга тырыша Тинчурин язмышындагы борылышларның сәбәпләрен Нияз Игламов. – Минемчә, Тинчуринны эшеннән азат итү – Гаяз Исхакыйдан алган хатка карата хикимиятләрнең беренче – әлегә «йомшак» формадагы – реакциясе булгандыр дип уйлыйм.

Танылган татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый революциягә кадәрге татар театрында репертуар тоткан автор булган. Аның 11 пьесасы куелган – Хәтта Камалныкы да азрак!

Ул Тинчуриннан өлкәнрәк булган һәм илдә барган вакыйгаларга карата мөнәсәбәте күптән формалашкан. Эмиграциягә дә иртәрәк китәргә өлгергән – кыенлыклар белән булса да, аның каравы ышанычлы юллар белән. Кызы Сәгадәт Тинчуриннар карамагына калган. Күпмедер вакыт узгач аңа әтисе янына күчеп китәргә ярдәм итәләр. Әлбәттә, Исхакыйның рәхмәте зур була, әмма бу рәхмәт Тинчурин өчен җәзага әйләнә.

– Гаяз Исхакый исемен кычкырып әйтмәскә тырышканнар, әйтәләр икән, бары тик тискәре яктан гына, – дип сөйли Нияз Игламов. – Аңа бик күп нәрсәләрне гаеп итеп такканнар, хәтта утызынчы елларда Германиядә яшәвен дә. Фашистлар режимы көч җыйган вакытта. Ләкин бит ул вакытта Берлинда Европадагы иң көчле тюркология мәктәбе оешкан була. Анда яшәр һәм эшләр өчен уңайлы тел мохите булган. Гитлерның да кем икәне бөтен кешегә дә ачык кына билгеле түгел әле ул вакытта. Исхакый Берлиннан 1930 нчы еллар ахырында Төркиягә качып китә. Монда да аның алдан күрүчәнлеге роль уйнаган. Мережковский, Кнут Гамсун, Герхарт Гауптман, Эзра Паунд һәм түбәнрәк дәрәҗәле әдәбиятчылар Гитлер реформалары һәм Өченче рейхның бөлгенә кадәр идеологиясе белән илһамланганда әле бу.

Шулай итеп, 1923 елда Берлиннан Казанга бандероль килеп төшә. Адресаты – Кәрим Тинчурин. Конвертта тюркология җәмгыятенең журналы, анда – Исхакыйның яңа пьесасы. Аның белән бергә авторның кызын кайгыртулары өчен рәхмәт хаты. Тинчурин бу хәбәрне дустыннан яшермәгән. Театрга: «Гаяз абый сезгә сәламнәрен юллый!» – дигән сүзләр белән килеп керә ул. Доносны кем язган – билгеле түгел, ләкин ундүрт ел узгач – ягъни коточкыч 1937 елда – Тинчуринга «халык дошманы» белән элемтәсен исенә төшерәләр, өстәп «Япония файдасына шпионаж»да гаеплиләр. Ни өчен Япония? Ул вакытта Исхакый Япониядә яшәгәнгә.

«БЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР»

Көрәштәшләре һәм остазларын яклап бик азлар гына күтәрелеп чыга. Аның каравы, әле күптән түгел генә бүләкләр биреп, аны икеләтә юбилее белән котлаган кешеләр Тинчуринга пычрак атарга, яла ягарга оялмый.

– «Контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнүче япон шпионы Кәрим Тинчуринны тикшерү» җыелышының беркетмәсен үзем күрмәдем, ләкин аны минем әти укыган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Мөгаен, ул еллар контекстында иң тәрбияле позициядә беренче чакырылыш актерлар гына калгандыр. Мәсәлән, Зәйни Солтанов. «Без моңа ышана алмыйбыз! Безнең белән ул мондый сөйләшүләр алып бармады». Калганнар бертавыштан диярлек Тинчуринны «фаш иткән». Шул вакытта кинәт кенә Гөлсем Камская торып баскан. Ул вакытта инде аның ире – режиссер Гали Ильясов репрессияләнгән була. «Сез нишлисез? Кәрим ага һәрвакыт яхшы кеше булды, ә сез аны хур итәсез, буш сүз сөйлисез!»

Җыелыштан соң актрисаны театрдан куалар – сугыш башлангач кына ул, актерлар җитмәү сәбәпле, фронтта эшли торган бригадага кайта алачак. Тинчурин исә инде күптән теге якта калган...

... «Без кабызган утлар янар алар» – әлеге җыр 1930 нчы елларда бик популяр була. Сүз уңаеннан, җыр – «Кандыр буе» спектакленнән Фәридә ариясе, аны Тинчурин белән Сәйдәшев иҗат иткән. Бу заман шедеврын еш кына радиодан ишетеп булган, хәтта «Маяк»тан да. «Салих Сәйдәшев көе, халык сүзләре!» дип игълан итә торган булганнар. Тинчуринны онытырга тырышканнар, ләкин аның фигурасы шулкадәр зур, аны мәдәни контексттан көчләп юкка чыгару мөмкин хәл булмый.

– Аның рухы барыбер һәркайда сизелеп торган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Күрәсең, Тинчурин бик якты, сөйкемле кеше булган. Бөтен хатирәләр дә шул турыда сөйли. Хәким Сәлимҗанов үзенең хатирәләрендә болай дип язган: «Без үзебезне аның шәкертләре итеп түгел, ә мөридләре итеп саный идек». Ягъни укучылары түгел, ә тарафдарлары. Татар театры өчен драматург озак елларга җитәрлек иҗади энергия чыганагы булды.

Озак вакытлар Тинчуринның үлгән көне дә ялган мөһере астында сакланды – бары тик 1988 елда бөек татар режиссеры һәм драматургның 1947 елда каты авырудан вафат булмавы, ә 1938 елда атып үтерелүе билгеле булды. Кулга алганнан соң бер ел буена аннан күрсәтмәләр таптыралар, әмма сындыра алмыйлар. Атып үтерелгән ноябрь төнендә дистәләрчә мәетнең гәүдәсен Казанның Архангель зиратындагы чокырга илтеп аударалар.

1930 нчы еллар ахырына якынлаша. Аннан соң нәрсә була? Аннан соң – сугыш...

Чулман яры буендагы өр-яңа Сәмруг авылы – Россия киносы өчен уникаль объект. Мондый масштаблы декорацияләрне, гадәттә, бик сирәк торгызалар.



ДӨНЬЯГА ЗӨЛӘЙХА КҮЗЛӘРЕ БЕЛӘН КАРАСАК...

Ерак Себер авылы – Татарстанда. Мондый хәл кинода гына була ала, дисезме? Һәм – хаклы булачаксыз! Старая Пристань дип аталган Лаеш районындагы авылдан ерак түгел, гүзәл Чулман ярында, стахановчылар темпы белән зур төзелеш бара – «Зөләйха күзләрен ача» фильмына декорацияләр әзерлиләр.

Автор:
Ольга Туманская

...Менә килеп тә җиттек. Безне «Зөләйха күзләрен ача» сериалын куючы рәссамның ассистенты Дмитрий Лебедев каршы алды. Күченеп утырган роман геройлары (хәер, кино, дисәк, дөресрәк булыр – авт.) яшәячәк яр буе – кул сузымында гына. Нәкъ китаптагыча ул: «...башта күндәм генә, су буйлатып җәелгән булса, аннан калкулыклар булып таралып китә, калкулыклар тауларга әверелеп, кыя тешләренә барып тоташа, ыржая башлый...»

Актерларны рольләргә беркетмәгәннәр әле, ә менә яр буендагы «Сәмруг авылының» йортлары инде үрчи башлаган.

– Ни өчен нәкъ менә шушы урынны сайладыгыз? – дип сорыйм Дмитрийдан.

– Безнең сюжет буенча Ангара елгасы булырга тиеш бит! Димәк, акбурлы яр буйлары, сөзәклекләр, дигән сүз. Бик күп урыннарны карап йөрдек, бу урын елгадан акбурлы яр күренеп торган бердәнбер җир. Тагын бер охшаш урын Архангельск тирәсендә бар, әмма андагы инфраструктура безгә мондагы дәрәҗәдә төшерергә мөмкинлек бирмәс иде. Анда 100 кешедән торган төркемне һәм җиһазларны, җайланмаларны илтеп җиткерү зур кыенлык тудырачак. Чулман яры – иң кулай урын булып чыкты, без моңа үзебез дә сөенәбез, фильмны Татарстанда төшерүнең үз мәгънәсе бар чөнки.

СӘМРУГ: СЫЛТАМАДА – КОНСТРУКТИВИЗМ

...Дөнья лазареттан һәйбәтләп тапталган сукмак буйлап алга – авылга таба җәелә. Монда өч бура биеклегенә тиң озын кара бараклар калкып утыра; атлас лозунглары ут кебек янып торган агитацион стенд канатларын җәеп салган; ризык исләре белән камап алынган кухня урнашкан серле бинада нидер өзлексез кыштырдый һәм чыжылдый; калкулык башыннан, җиңел генә яулап алып булмастай бастиондай, шомлы комендатура күләгә ташлап тора; ерактарак, чыршыларның зәңгәр ябалдашлары артында, клуб утлары күренә – анда, төн диме, көн диме, үзенең аңкып торган буяулары белән Илья Петрович тылсым тудыра...

Менә ул – Зөләйханың улы Йосыф күзләре аша без күргән дөнья. Булачак декорацияләрнең җәте төсләр белән ясалган иллюстрацияләре беркетелгән стенд каршына килеп басабыз. Борылып карыйбыз да, чагыштырабыз: чынбарлык ни дәрәҗәдә сурәттәгесенә туры килә? Әнә, саргылт төстәге әле тө-

КАМЕРА. МОТОР. БАШЛАДЫК!

СПРАВКА

Гүзәл Яхинаның бестселлерга әверелгән романы буенча крестьяннарны кулаклыкта гаепләп кулга алу, ГУЛАГның махсус авылында кол урынына эшләтү турындагы күпсерияле фильмны тамашачыга «Россия 1» телеканалы тәкъдим итәргә җыена. Фильмны төшерү бәхете «Русское» кинокомпаниясенә тәтегән. Режиссер итеп Егор Атнашкинны билгеләгәннәр. Картинаны августта төшерә башлаячаклар. Зөләйха ролен Чулпан Хамматова уйнарга тиеш.

Фото: Александр Ефремов

зелеп бетмәгән йортларда лазаретны да комендатураны да шәйләргә була, балкып утырган клуб та күзгә чалына. Соңгысы бигрәк тә игътибарны җәлеп итә. Чып-чын конструктивизм өлгесе булган бу бина барлык элементлары белән фильмда күрсәтеләчәк чорны чагылдыра.

– Сөргендәгеләр яши торган авылларда да шундыйларны төзеделәрме икән? – дип тел шартлатам.

– Ә монысы инде сәнгатьнең бер алымы, – дип шәрехли Дмитрий. – Безнең төп бурычыбыз – Сәмругны китапта автор сурәтләгәнчә итеп торгызу түгел. Кадрда ул җете, карауччының игътибарын җәлеп итәрдәй булырга тиеш. Истә калырдай. Әгәр йорт гади бер квадрат кына булса, без мондый эффектка ирешә алмаячакбыз, билгеле. Сюжет буенча, аның эчендә әле кулдан язылган бизәкләр дә бар. Монысын ничек хәстәрләргә, дисезме? Әлбәттә, шулай ук – кулдан!

Бу искиткеч манзаралар сериалның куючы рәссамы Мария Турская эскизлары буенча чынбарлыкка әверелергә тиеш. Мөгаен, рәсамнар белән төзүчеләр командасы алдына килеп баскан иң зур кыенлык авылны конкрет бер урынчалык – Лаеш рельефына (ә ул, әйтүләренчә, шактый катлаулы) туры китерү булгандыр. Мондагы калкулыклар белән тигез җир арасындагы аралыклар кайбер урыннарда 2,5 метрны тәшкил итә икән.

– Гадәттә, декорацияләрне тигез урында, япан кыр уртасында торгызалар, – дип сөйли безгә Дмитрий. – Ә монда, алар торыклы булсын өчен, бертуктаусыз субайлар салырга, бетон җәяргә, нәрсәнедер эретеп ябыштырырга туры килә…

Чулман яры буендагы өр-яңа Сәмруг авылы – Россия киносы өчен уникаль объект. Мондый масштаблы декорацияләрне, гадәттә, бик сирәк торгызалар. Китап елның дүрт фасылын да үз эченә ала, шуңа да «авыл», ким дигәндә, бер ел торырга тиеш. Димәк, «Потемкин авылы» гына килешмәячәк, ә чыпчын җылытылган йортлар калкып чыгарга тиеш бирәдә. Аларда, субайлардан кала, бар да, борынгы заманча: агачтан эшләнгән. Дмитрий сүзләренә ышансак, «Зөләйха күзләрен ача» сериалы декорацияләрен Кырымда төшерелгән «Скиф» картинасы, йә булмаса, бөтенләй дә «Викинг» белән генә чагыштырып була.

Мәйданда даими рәвештә Мәскәүдән килгән тугыз рәссам эшли. Шулай ук – 20 яллаган эшче. Араларында Татарстан кешеләре дә бар, Чувашиядән килүчеләр дә… Фильмны әзерләүчеләр эшчеләрдән бик канәгать. Канәгать булмыйча соң – бер ай эчендә ярты авылны төзеп чык әле син!

– Шартлар җиңел түгел, – ди Дмитрий. – Баштарак һава торышы гел бозылып торды, инде минә эссегә чыдап булмый. Әмма, ничек кенә булмасын, августка эшне төгәлләргә дип торабыз.

Әйе, кояш, чыннан да, яндыра гына! Аннан яшеренер өчен, без урманга юл алабыз.

– Аяк астыгызга карап йөри күрегез берүк, – дип кисәтә мине Дмитрий. – Монда тагын бер проблема бар – зәһәр еланнар. Мин инде уналтыны санап өлгердем…

Һәм менә без тарлавык авызына килеп туктыйбыз. Ул күләгәле сукмагы белән турыдан-туры Чулманга тоташа. Төшү юлының башы – фильм каһарманнарының, кырыс тайгага килеп урнашкач, беренче сыенган урыны булачак – монда балчыктан йорт (землянка) торгызырга җыеналар.

– Кабат агачларны күчереп утыртырга туры киләчәк инде, – дип, авыр сулап куя безнең фильм буенча гидыбыз. – Ә болай, бу иң идеаль урын землянка өчен. Тарлавыкны файдаланачакбыз – землянканың тулы мәйданы 87 квадрат метрны тәшкил итәчәк бит! Ә син ул кадәрне казып кара…

Әлеге объект буенча эшләр октябрь башында старт алачак – төшерүнең иң кызган вакытында. Казуны да актерлар башлап җибәрәчәк – камерага! Ә тәмамлауны инде төзүчеләргә йөкләячәкләр, әлбәттә.

ЧУЛМАНМЫ? АНГАРАМЫ?

…Давыл, әйтерсең, кинәт кенә башланды. Котырып искән җил баштан фуражкасын алып атты. Игнатов уяныл китте, аның артыннан томырылды, караса – әнекәем! –



Бу искиткеч манзаралар сериалның куючы рәссамы Мария Турская эскизлары буенча чынбарлыкка әверелергә тиеш.

Чулманның тынгысыз горур Ангараны ничек «уйнавы» фильмның бөтен атмоферасын хәл итәчәк. Хәзер аның өслеге тып-тын. Әмма барысы да санаулы мизгелләрдә үзгәрергә мөмкин – Чулман да бик үзенчәлекле холыклы елга.

“ – Болар барысы да минем хатирәләремнән алынган, – ди ул. – Мортаза яши торган йорт – ул, нигездә, әбием белән бабамның йорты. Аны романнан икетуган абый-апаларым да шунда ук танып алды!

тирә-юньдә инде дөнья актарыла: офык чайкала, дулкыннар, ак күбеккә батып, күперә, акчарлаклар һаваны ярып шашынып оча, койрыгына ут капкан мәчедәй, матрослар бәргәләнә. Авазлардан ник берсе ишетелсен – давыл барысын да күмеп киткән.

– Елганы төшерегез, – ди Дмитрий безнең фотографка. – Ул бит картинаның төп каһарманы, персонажы!

Чынлап та, Чулманның тынгысыз горур Ангараны ничек «уйнавы» фильмның бөтен атмоферасын хәл итәчәк. Хәзер аның өслеге тып-тын. Әмма барысы да санаулы мизгелләрдә үзгәрергә мөмкин – Чулман да бик үзенчәлекле холыклы елга. Көчле давыллар вакытында аның дулкыннары икешәр метрга кадәр җиртәргә мөмкин, диләр. Ә фильм төшерер өчен сайланган урын, гомумән, «холыксыз», ди, аннан ерак түгел генә Чулман Идел белән кушыла чөнки.

– Әнә, карагыз ул сызыкка, – ди Дмитрий (ә анда, дикъкать белән баксаң, соргылт һава баганасы уйнаклап тора – авт.). – Без 30 май көнен бик яхшы истә калдырдык. Һава эссе иде. Шурпа ашарга гына утыруыбыз булды, кинәт башланды, минсиңәйтим! Котлар калмады...

Һәм ул безгә кәрәзле телефонына төшереп алган шул мизгелләрне күрсәтә. Коточкыч тизлектә офык буйлап, кап-кара атлар табуныдай, болытлар җилдерә. Ерактарак – су өслегендә – өермә кузгала. Икенче бер мизгелдә ул Казан ягына таба томырыла. Ә Чулман өстендә кабат ялтырап кояш балкый...

Сюжет буенча Ангара өстендә купкан давыл «Клара» баржасын батыра. Ә аның эчендә –сөргенгә сөрелгән өч йөз кеше, барысы да, төрмәгә бикләнгәндәй, трюмга ябып куелган. Исәпсез-хисапсыз куллар рәшәткәгә ябышып, аны селки, ачарга омтыла, әмма су барысын да күмеп китә...

Әлеге гаять катлаулы эпизодны Чулманда төшерерләрме, юкмы, әлегә билгесез.

– Бу зур осталык таләп итә торган каскадерлар трюгы, – ди Дмитрий безгә. – Нәтиҗәсе, шулай ук, күптөрле факторлардан торачак – баржа юнәлешеннән дә, каскадерлар бригадасы эшеннән дә...

– Ә «Клара»ны батыру – мөмкин эшме? – дип кызыксынабыз.

– Кадрда – әйе. Калганы инде – кино хәйләсе, – дип, интригага урын калдыра аңгәмәдәшебез.

Сүз уңаеннан, фильм өчен ярардай баржаны әле һаман тапмаганнар. Ә менә фильм каһарманнары дебаркадерга килеп туктый торган катер инде әзер, ди. Берәү генә дә түгел, алар дүртәү икән. Җирле көймә верфьләрендә юлыкканнар. Нәкъ туры килә торганнар, ди, искеләр, әмма әле йөрергә сәләтле икән үзләре.

ТАТАРСТАНДА ТАБЫП БУЛМЫЙ ТОРГАН ТАТАР АВЫЛЫ

...Паласка абынмаска. Диварның уң ягында торган чүкеп ясалган сандыкка яланаягың белән бәрелмәскә. Мич борылышындагы шыгырдый торган тактаны атлап үтәргә. Хатын-кызлар ягын ир-атларныкыннан аерып торган ситсы чаршау артына тавыш чыгармый гына чумарга...

Яхина – детальләргә чиксез зур игътибар бирә, аларны җентекләп сурәтли торган автор. Аның ярдәмендә мин, укучысы, узган гасырдагы татар йортының эчке бизәлеше нинди булганын шунда ук аңлап алам, атмосферасына барып эләгәм.

– Татар көнкүрешен каян шулай яхшы беләсез? – дип сорыйм автордан.

– Болар барысы да минем хатирәләремнән алынган, – ди ул. – Мортаза яши торган йорт – ул, нигездә, әбием белән бабамның йорты. Аны романнан икетуган абый-апаларым да шунда ук танып алды! Балачагымның шактый күп өлеше шунда узды. Казан читендә урнашкан зур йорт иде ул – бакчасы, мунчасы, чарлагы бар. Ә ул чарлакта тау-тау иске-москы өелеп тора. Шунда ук – каклаган казлар, җимеш каклары. Бабам аларны түбәдә август-сентябрь айларында киптерә торган иде... Миңа анда күргәннәрне искә төшерү дә җитте. Бераз гына буяуларны куертып, акцентларны көчәреп, нәрсәнедер кискен бер чиккә җиткереп, ничек кенә булмасын, барыбер дә газиз, балачактан күреп үскән предметларны, тирәлегемне сурәтләдем.

Гүзәл Яхина романында сурәтләгән Юлбаш авылын картадан Россия буйлап эзлиләр. Хәтта Архангельск төбәгендә урнашкан Кимжи исемле искиткеч гүзәл авылга кадәр барып җитәләр. Әмма берсе дә ул булып чыкмый. Миңа бер сорау тынгы бирми: ә Татарстандагы авыллар төшерүчеләргә нәрсәсе белән ярамаган?! Соравыма җавап тиз табыла: алар шулкадәр яңартылган һәм төзек икән, узган гасыр башындагы авылны берничек тә уйный алмыйлар, янәсе.

– Безнең иксез-чиксез илебез территориясендә йорт төзелеше технологияләре бик төрле булган, берсе икенчесеннән ягы-ягы белән сизелерлек дәрәҗәдә аерылып тора, – дип сөйли сериалның куючы рәссамы Мария Турская. – Әлеге аермаларны без һәрбер төбәктә урнашкан агач төзелеш сәнгате музейларында күрә алабыз. Әмма Татарстанда – инде юк. Казанда, шәһәр эчендә, бармак белән генә санарлык агач йортлар сакланып калган. Ә безгә эш өчен атмосферасы булган, тарихилык аңкып торган авыл кирәк бит.

Ахыр чиктә, фильмны төшерүчеләр, тирәлекне үзгәртеп, корылмаларга үзгәреш кертеп, җирле авыл халкын мәшәкатьләп торуны кирәк тапмаган. Татар авылын алар Пермьдәге «Хохловка» музеенда төшерергә карар кылган. Рәссамнар Этнография музеенда тиешле дәрәҗәдә консультация алган – хәзер алар рус ызбасында нәрсәләрне үзгәртергә кирәген белә. Ул татар йортына охшасын өчен, ызба пространствосына тиешле деталь-элементларны өстисе генә кала.



Мөгаен, рәсамнар белән төзүчеләр командасы алдына килеп баскан иң зур кыенлык авылны конкрет бер урынчалык – Лаеш рельефына туры китерү булгандыр. Мондагы калкулыклар белән тигез җир арасындагы аралыклар кайбер урыннарда 2,5 метрны тәшкил итә икән.

– Аермалар җитәрлек, билгеле, – ди Мария. – Әйтик, рус ызбасында пешеренү бик әһәмиятле роль уйнаган, ул шуңа йөз тотып төзелгән дә. Утынны янып торган учакка ташлаганнар – бу мичтә ярымтүгәрәк рәвешендәге ачык урынны күздә тоткан, нәкъ әкияттәгечә. Ә татар өйләрендә пешеренү өчен махсус плитә каралган, анда казан утыртырга мөмкин булган. Утынны исә ишеге ябып куела торган махсус уемтыга урнаштырганнар. Шулай итеп, безгә әзер мичкә модернизация ясап тору кирәкми, югыйсә бу инде татар миче булмаячак. Башка нюанслар да бар. Татарларда ян капка һәрчак төп капкадан сул якта урнашкан, бу ырымйолалар белән бәйле. Хохловкадагы ян капкалар – уң якта. Болар – кайбер мисаллар гына! Барысын да исәпкә алу зарур, исәпкә алмасак, фильмны караган татар тамашачысы шунда ук ялгышларны танып алачак. Җирле халык татар йорты белән рус йорты арасындагы аерманы яхшы белә лабаса. Замана кешесе, әлбәттә, аңлы рәвештә бу үзенчәлекләрне өйрәнмәгән дә булырга мөмкин, әмма аның хәтере ялгышмаячак, ул барысын да «аң төпкеле»ндә саклый. Халык хәтере – ул бик зур нәрсә!

ЧОР: БҮГЕН ҺӘМ КИЧӘ

– Тарихи чор белән эш итү бер үк вакытта җиңел дә, читен дә, – ди Дмитрий. – Бер яктан, мәгълүматка кытлык юк, анысы әйбәт, икенче яктан – без аерым бер материалга береккән. Чөнки тамашачыга ул чор әле һаман да таныш, фильмнар, китаплар аша гына булса да – барыбер. Мисал өчен, без такталарны бары тик кадак белән генә кадаклыйбыз. Әйе, тамашачы бер генә саморез да күрмәячәк кадрда. Ни өчен, дисезме? Сәбәбе гади: бары тик кадак кына яңгырдан соң тутыккан кызгылт-көрән эз калдырачак. Әгәр кайдадыр ул эз булмый икән, аны буяу ярдәмендә кулдан ясарга туры киләчәк, димәк.

Китапта тайга авылына барып җиткәнче озын-озак михнәтле юл процессы сурәтләнгән, аның атмосферасы гаҗәеп җете буялар белән, детальләр аша бирелгән. Без беләбез: Гүзәл Яхинаның әбисе 16 ел гомерен Пит-шәһәрчектә сөргендә уздыра. Зөләйха турыдан-туры аңардан күчереп язылмаган булса да, ул җиде яшьлек Рәйсәнең фактик географик юлын кабатлый.

– Әбием миңа ул еллардагы тормыш-көнкүреш турында еш сөйли иде, – ди Гүзәл. – Җентекләп, тәмләп – ничек җиләк җыюларын, нинди рецептлар куллануларын, бозлы су эчендә торып, нинди җайланмалар ярдәмендә алтын юууларын… Әмма мин әлеге хатирәләрне тиешле дәрәҗәдә файдалана алмадым, чөнки вакытында теркәп барырга башыма килмәгән. Алар әбием белән бергә гүргә инде инде. Шуңа аның истәлекләре белән бәйле бүлекләргә урыны-урыны белән уйдырма да кушылып китә. Миңа музейлар ярдәмгә килде. ГУЛАГ тарихы музее, мәсәлән. Мәскәү тимер юл музеенда мин сөрелүчеләрне күчереп йөрткән вагонны күрдем. Әнә шулай, әйберләргә, җиһазларга орына-орына, максималь рәвештә чорның моделен торгызырга тырыштым. Фильмны төшерүчеләрнең дә ул чорның рухын торгызу кулыннан килер, дип ышанам.

Ә нәрсә кирәк соң моның өчен? Тәҗрибә, ди Дмитрий. Мәсәлән, агачны картайтуның бик күп төрле ысуллары бар икән. Берничә сәгать эчендә алар яңа гына төзелгән йортны «ике йөз еллык тарихы» булган раритетка әйләндерә ала икән. Иң мөһиме – аны дөрес итеп файдалану, ягъни йортка җан кертү. Кадрда ул декорация генә булып күренмәсен, ә чып-чын яшәлгән урын төсмерен алсын өчен, декораторларга әле сукмакны кайдан ничек саласын да, чүлмәкне кайсы җиргә эләсен дә, нинди почмакка пәрәвез тарттырасын да хәл итәргә кирәк булачак.

– Мин беркайчан да бер генә чыганак белән чикләнмим, – ди Мария Турская. – Материалны җыю этабында искиткеч игътибарлы булырга кирәк: вакытның сулышы нинди булуын тоемлар өчен, фотографияләрне җентекләп өйрәнү, детальләргә аерым бер игътибар бирү сорала. Тарих нәкъ менә аларда яши. Шуннан син инде үзеннән-үзе кирәкле стильне тоя башлыйсың. Билгеле бер предметны, интерьерны, костюмны, бинаны күрүгә, шунда ук тәгаен беләсең: барамы бу фильм өчен, әллә юкмы.

Шул ук вакытта рәссамнар кат-кат ассызыклый: аларның төп бурычы – чорны бар нечкәлекләрендә торгызу түгел. Төп бурычлары – билгеле бер тарихи эпоханың образы белән атмосферасын тудыру.

«МИНЕ ХАЛЫК ЯРАТТЫ...»

Мин аның белән беренче тапкыр 17 яшемдә «Казан утлары» редакциясендә таныштым. Үзем шигырь язгалап маташсам да, китапларын яттан белсәм дә, очрашуларда күргәндә никтер барып сүз катарга кыенсына идем. Ә танышкан көнне, без кечкенәдән укып үскән «Роберт абый», әле әдәби мохитнең ни икәнен дә күзаллламаган балага кирпеч кадәрле авыр, калын, саллы китабын бүләк итте. Ул гына да түгел, автограф урынына китапка тиз генә шигырь дә язып куйган булып чыкты.

Анда мондый юллар бар иде:
Бер канатың – мәхәббәттер,
Берсе – балачагың.
Син бит әле белмисең дә
Ниләр булачагын.

Әнә шул «булачаклар» булган еллар шаукымында никтер Роберт абый белән бер дә рәхәтләнеп гәпләшеп утырырга туры килмәгән икән. Бу хатаны төзәтергә ниятләдек тә күрештек әле. Сүзне аның үзенә бирәм.

– Бүген шигырь укымыйлар, дигән фикер белән килешмим. Шигырь дә укыйлар, чәчмә әсәрләрне дә. Әмма әдәбиятта сыйфат төшенчәсе шактый какшады һәм «яхшы» белән «начар» арасындагы чикләр югалды. Әхлакый-эстетик критерийлар да башка хәзер. Бездә шигърият, һәрвакыттагыча, алдынгы булып бара әле. Кемнәр басыла, барысын да укып барам, газета-журналларны, элеккеге матур гадәт буенча, өйгә яздырып алабыз. Инде менә сезнең буынның да үзгәрешләрен күзәтеп киләм. Сез башкарган эшләрнең нәтиҗәсен күреп сөенәм, киләчәгебезгә ышанарак төшәм. Һәрчак шулай

Фото: Ната Смирнова

булган: өлкән буын үзләреннән соң килгән яшьләргә ышанып, күңелләренә тынычлык урнашырга тиеш. Кызганыч, прозада аксыйбыз без, замана укучысын канәгатьләндерә алырдай, бүгенге торышыбызны яктыртып күрсәтердәй яхшы повесть-романнар кирәк. Татар теленең хәле мөшкел заманда телебез белән кызыксындыра алырдай әсәрләр туса, аңа ихтыяҗ аз гына булса да артыр иде. Әдәби тәрҗемәгә дә карашым элеккечә булып кала бирә – русча укый алганда, ул нигә кирәк, дибез, кирәк, чөнки ул телне камилләштерә, аны баета, яңарта.

Менә сезгә бер букет пиннек!

Инстаграм – безнең психологик көзгебез. Анда барысы да аермачык күренеп тора: нәрсә белән яши кеше, кем булып кыланырга тырыша, ниләр белән кызыксына, нәрсәләр ошый аңа, нәрсәләр ошамый. Заманнан артта калмас

Безнең Шәммәт кәҗәсе.
Күзләре бигрәк моңсу…

өчен теркәлдем дә, ошап китте. «ВКонтакте» челтәре күбрәк яшьләр контингенты өчен булса, Фейсбукта акыл сатып утыру соралса, Инстаграм – нәкъ минеке. Монда фото һәм бераз гына, күңел өчен, текст булса, бик җитә. Ә мин фотога төшерергә балачактан яратам. Инстаграмда минем язылучыларым шактый, алар да шул ук минем публикам бит. Җитмәсә, мин хәзер пенсиядә, вакытым бар, ә укучыларың белән аралашу өчен замана тудырган мөмкинлектән ник әле баш тартырга, ди?

Рәхмәт сүзен кем яратмый, мин дә яратам. Шәрехләрдә дә, личкага да күп язалар. Минем аудиториям – ул, башлыча, укытучылар. Барысын да укып барырга тырышам, җавап бирәм. Күңелең белән сизәсең инде, бераз гына салпы якка салам кыстырганнарын да, майлап җибәргәннәрен дә… ләкин бит ишетүе рәхәт! Шулай да рәхмәткә генә алданып әллә кем булып йөрү әкәмәт булыр иде. Үземне үзем беләм: минем бик күп җитешсезлекләрем дә бар, үземә ошамый торган якларым да. Инстаграмдагы сурәттә генә ул күренми, ә тормыш – икенче… Кеше, ни кызганыч, камил зат түгел, әмма аңа камиллеккә ирешим дип яшәү мөмкинлеге бирелгән.

«Роберт такмак яза инде ул» диючеләрнең дә, мине яратмаучыларның да барлыгын бик яхшы беләм. Бу сүзләр яшьрәк чакта кәефемне кыра иде, хәзер инде күнектем, көлеп кенә карыйм. Әмма каләмдәшләрем арасында кемнәрдер яратмаганда, дошман күргәндә дә, мине халык яратты. Шуңа укучыларыма бик рәхмәтлемен! Бу зур бәхет язучы өчен. Ә каләмдәш дусларга килгәндә, алар минем иҗатыма артык берьяклы гына карыйлар шикелле, бәяләп бетермиләр. Бәлки, әйбәт белмиләр, укымыйлардыр да…

Мәктәпләрдә хәзер дә көтеп алалар, гел чакырып торалар. Мин инде хәзерге укучыга әйтер сүзем бармы икән, искергәнмендер, шәт, дип барам да, канәгатьлек хисе кичереп кайтам. Бала кайсы заманда яшәсә дә, бала ул! Аның борчулары да, куркулары да, сөенечләре дә – шул. Бары тирәлек, атрибутика гына алышына. Минә бүгенге балаларга нәрсә язасың, алар искене укымый, без аларга кызыклы түгел, дип аптырыйлар. Имеш, айфоннар, мультиклар, уеннар булсын да, вәссәлам… Алай була алмый, ул бит тере җан иясе! Кеше хис-тойгыларын алыштырырдай машина әле уйлап табылмаган җир йөзендә… Әгәр син баланың эчендәге әнә шул психологик халәтне сурәтли аласың икән, димәк, син барлык заманнарда да кызыклы булырдай әсәр тудырырга сәләтлесең.

Классика ни өчен классика дип атала? Чөнки ул мәңгелек темаларны күтәрә, һәрчак кешенең үзәгендә кайнаган хисләргә килеп кагыла. Балалар әдәбиятындагы классик әсәрләр дә – нәкъ шундыйлар.

Без «йолдызлар» арасына килеп эләктек. Минем буын 60нчы елгылар сәхнә тоткан елларда килеп керде әдәбиятка. Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхимнәр… һәрберсе үзе бер планета иде! Ул мәйданнарда шигырь укып җибәрәләр, ул җыелышларда фикер әйтәләр… Без 40 яшькә кадәр яшь шагыйрьләр булып йөрдек, күпмедер дәрәҗәдә аларның күләгәсендә югалыбрак та калдык хәтта. Әмма, шуңа да карамастан, һәрберебез үз юнәлешен, юлын тапты. Зиннур Мансуров, мәсәлән, шагыйрь, публицист булу белән генә чикләнмичә, күп еллар дәвамында мәртәбәле басманы җитәкләде, Марсель Галиев иҗатында үзенә генә хас «ниша»ны тапты… Мин исә балалар әдәбиятына кереп киттем һәм шуның белән оттым. Рәшит Бәшәр дигән язучыбыз бар Чаллыда, ул да балалар әдәбиятын сайлады, «Мәйдан» журналын чыгару эше белән мәшгуль… Ә аннан шигърият мәйданына Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмнәр килде…

Шагыйрь Зөлфәт депутат-шагыйрь Роберт Миңнуллинны очраткан да:

– О-о-о, татар совет шагыйре Роберт Миңнуллин! – дип исәнләшә икән.

Роберт Миңнуллинның моңа бер дә исе китмәгән:

– Юк, Зөлфәт, ялгышасың! Татар Дәүләт Советы шагыйре Роберт Миңнуллин! – дип җавап кайтарган.

«Роберт ул хәйләкәр, астыртын» дип уйлаучылар бар. Бу кешеләр мине белми, димәк. Табигатем буенча мин бик оялчан (яшь чакта ул сыйфат бигрәк тә көчле иде, комплекслар да өстәлә бит әле тагын, җитмәсә), йомыграк кеше, артык чәчрәп чыкмыйм. Гап-гади бер авыл малае инде, дөресен генә әйткәндә. Ә хәйләкәрлеккә килгәндә, хәйлә тормыш иткәндә бик кирәк нәрсә инде ул, азмы-күп-

Автор:
Луиза Янсуар

ме безнең барыбызда да бар. Миндә дә башкаларныкыннан артыграк та түгел, ким дә түгелдер, дип уйлыйм.

Миңа юмор һәрчак юлдаш булды. Юмор кешене тормыштагы бик авыр чакларда коткара ала. Ул, шулай ук, үзенә күрә бер саклану чарасы да. Дәүләт Советында эшләгәндә, катлаулы хәлләрдә атмосфераны җиңеләйтеп җибәрергә еш ярдәм итте. Мин анда булган кызыклы хәлләрне «Дәүсовет мәзәкләре» дигән исем астында китабыма да кертеп җибәрдем.

Табигатьне бик яратам. Аның кечкенә генә могҗизаларына да соклану сәләте биргән миңа Ходай. Бу да шул балалыкның бер чагылышыдыр инде. Инстаграмдагы сәхифәмдә дә шуңа табигать күренешләре, манзаралары күп. Хайваннар, кош-кортлар…. Без шулар арасында үстек бит, алар безгә кече туганнар кебек якын. Ничә еллар шәһәрдә яшәсәк тә, барыбер авылча беркатлырак, гадирәк итеп, әмма алга карап фикер йөртәбез. Безне ул авыл психологиясе бик яхшы саклап килде бүгенгәчә.

Оныкларым матур итеп татар телендә сөйләшә. Әби-бабалары, әти-әниләре аша аларга табигый рәвештә күчкән тел ул. Монда әллә ни гаҗәпләнерлек гайре табигый нәрсә юк, бу гадәти норма. Аңлыйм, аларга үз телләрен саф итеп, матур итеп шәһәр мохитендә саклап калу җиңел булмас, дөнья да үзгәреп тора. Әмма без аларга ана телләрен тапшырдык – бу безнең бурычыбыз иде.

Гомер буена риясыз дус була белгән бер гаҗәеп кешене беләм. Ул – безнең уртак танышыбыз Рәдиф Гаташ. Аның беркайчан да, беркем белән дә хөсетле яшерен ниятләр, максатлар белән аралашканы, кемгәдер яраклашканы булмады. Ихласлык, эчкерсезлек үрнәге ул минем өчен. Һәм бик ярдәмчел кеше дә. Никадәр яшьләргә канат куйган, ярдәм иткән зат, аның хәерһахлы мөнәсәбәтен миңа да яшьтән татырга насыйп булды.

Мин остазлардан уңдым. Әтисез үскән малай буларак, өлкәнрәк абзыйларга, авторитетларга тартылу көчле иде. Бәхет елмайды – әдәбият дөньясына килеп кергәч, Шәүкәт Галиев белән Илдар Юзеев мине үз канаты астына алды. Озак еллар дәвамында аларның ярдәмен тоеп яшәдем, зур мәктәп булды ул.

> **“ – Кеше, ни кызганыч, камил зат түгел, әмма аңа камиллеккә ирешим дип яшәү мөмкинлеге бирелгән.**

Балалар язучысы балалар өчен түгел, ә баланың үзе булып язарга тиеш. «Балалар өчен» язганда, син өстән карыйсың, арада киртә кала, ә «бала булып» язганда, син шул стихиягә кереп күмеләсең. Бер караганда, кыен да түгел бит: балачакка кайтасы да, кичерешләрне яңартасы гына… Шәүкәт абыйда әнә шул үзенчәлек бар иде. Шуңа да аның Шәвәлиен без, үзебезне күргәндәй, якын иттек, яраттык. Аннан соң мин дә бу юнәлешне дәвам иттем. Без әнә шул «бала халәтенә кереп» язу ысулын камил дәрәҗәгә җиткерергә тырыштык.

Безнең балалар әдәбияты ул чакта дөнья дәрәҗәсендә иде. Мин моны мактанып әйтмим, факт буларак кына билгеләп узасым килә. Чөнки аны еш кына танып җиткермиләр. Әйтик, заманында, мин Роза апа Хафизованың «Кирлемән маҗаралары»н тәнкыйть итеп чыккан идем. Ләкин бүгенге әсәрләр белән чагыштырганда, ул иң яхшылар рәтендә саналыр иде. Ә бит әдәбият балаларга ана телендә килеп керергә тиеш!

Без, Башкортостан ягыннан килгән егетләр, чиста лириклар. Әйтик, Есенин кебегрәк. Барыбыз да – табигать кочагында тәгәрәп үскән гади авыл малайлары, кыяфәтебездән үк кем икәнлегебез күренеп тора. Ни күрәбез, тоябыз-кичерәбез, шуны язабыз. Әнгам ага да шундый иде, Наҗар ага да, әлеге дә баягы Рәдиф абый да, миннән яшьрәкләрдән, әнә, хәзер Марат Кәбиров шигърияте шундый. Мин үземнең лирик иҗатымны кыерсытылганрак, бәяләнеп җитмәгәнрәк итеп тоям.

Мин үземне, курыкмыйча, җырлар шагыйре дип атый алам. Искиткеч талантлы, зәвыклы, үз һөнәренең остасы булган композиторлар белән дә, башкаручылар белән дә эшләү бәхете тәтеде миңа. Шуңа да хәзерге җыр сәнгате өлкәсендәге хәлләргә инде хәтта бәя бирүне дә кирәк тапмыйм. Безнең эстрада хәзер туйлар алып бара торган тамада дәрәҗәсендә. Ул үзен халык таләбенә җавап бирәм, ул көткән продукцияне бирәм, дип юатырга тырыша. Әмма ялгыша һәм үз тамашачысына зур зыян эшли. Үз зәвыгы булмаган, белеме аксаган (йә бөтенләй булмаган!) затлар ничек итеп халыкка нидер бирә алсын. Шуны бирә алмаганга, ул бушлыкны ырдый-бырдый белән тутыра һәм акча эшли. Бүгенге көндә җыр өчен текст язучылар да, көй тудыручылар да профессиональлек төшенчәсенең ни икәнен дә белми. Алар үзләре җиңел генә сырлап ташлагач, башкалар да шулай итә, дип исәпли.

Акча хакимлек иткән урында цензура көчсез. Бүгенге җыр индустриясендә хөкем сөргән ситуацияне бары тик зәвыклы сәнгать әсәрләренә шулай ук акчаны арттырып кына ирешеп була. Бер бәя икенчесен капласа, менә шул очракта булырга мөмкин кан алмашу.

Мине кәнәфи бозмады. Шөкер, бүгенгә кадәр дөньяга балаларча сокланып карау сәләтемне саклап кала алдым. Бәлки, миңа язучылык, бигрәк тә балалар өчен язуым, булышкандыр. Шагыйрьлегем. Шигърият бит ул әллә нинди тылсымнарга ия.

Җырдагыча, «без биш бала үстек әнкәй белән, тик үсмәдек җылы кочакта…» Әнкәй безгә ата да булды, ана да. Ул бик булдыклы һәм гадел кеше иде. Мин аның партия җыелышларында торып басып, ялкынланып, ясаган чыгышларын хәтерлим. Ул чын күңеленнән совет дәүләтендә безнең гадел, хөр яшәвебезгә ышана иде. Безне дә тәртипле, гадел булырга өйрәтеп үстерде. Иң беренче чиратта кеше булыгыз, ди иде. Әтисез дә үскәч, борчылгандыр. Шөкер, беребез дә тормыш арбасыннан төшеп калмадык, ким-хур булмадык, аның йөзенә кызыллык китермәдек. Әнкәй – бөек кеше, мин аңа гомерем буена рәхмәт укыйм, баш иям! Ул минем гомерлек музам, дисәм дә ялгыш булмас. Ул илһамландырып язган җырларым гына да күпме.

Дәүләт җыелышлары гадәттә билгеле бер сценарий буенча бара. Әлбәттә, җитди, көнүзәк мәсьәләләрне хәл иткәндә, ул сценарий кысаларыннан чыгып та китәлә, әмма барыбер тәртип сакланырга тиеш. Әгәр һәркем үзенекен теләсә ничек кычкырып утырса, ул, аңлашыла да, тулы бер анархия булыр иде. Аннан, син кайсы фир-



Роберт Миңнуллин җәмәгате Клара ханым белән.

кагә карыйсың, шунысы да мөһим. Син аның генераль линиясенә каршы килердәй сүз сөйләп утырмыйсың инде.

Депутатмы ул, төзүчеме, редакция хезмәткәреме, шагыйрь – беренче чиратта, шагыйрь. Ул үзенең төп магистрале ни икәнне беркайчан да онытмый, бәлки теләр дә иде, әмма оныта алмый. Чөнки табигать аны шундый итеп яраткан.

Без сәясәттә булган елларда күп эшләр эшләнде. Асылда, ул дәүләтчелегебезне кайтарган, мөстәкыйль курс алган тулы бер эпоха булды. Хәзер безне, ул елларда депутат булучыларны, пыр туздырып сүгәләр. Ләкин дәүләт эше, кабинет эше – ул күзгә күренми торган вак һәм четерекле хезмәт. Аның турында урамга чыгып кычкырып та йөреп булмый, чөнки син вазыйфаңа һәм оешмаңа хилафлык китерәсең, бу юридик яктан законга да сыешмый хәтта.

Әчми башлагач, ярты дустан колак кактым. Бер әңгәмәдә мин шулай дигән идем, аны язып та чыктылар. Дөресен генә әйткәндә, дуслык ул – бик шартлы төшенчә. Тормышның төрле этапларында кеше янәшәсендә төрле кешеләр була, син үзең дә кем беләндер якынаясың, кемнәндер ерагаясың. Кеше тормышны иярләп барган чакта, дәрәҗәсе, даны, акчасы булганда, аның янында дуслар күп була. Ә чын дусларны тормышның кискен борылышларында һәм гомернең көзендә беләсең.

Кешенең бәхете өендә булырга тиеш. Барасы килеп торган эшеннән кич кайтасы да килеп торсын ул. Депутат вакытта, өйгә кайтып та керми, командировкаларга йөрдек. Гаиләнең йөге Клара җилкәсенә төште. Хәзер икебез дә пенсиядә. Балалар үсеп кеше булды, оныклар бәхетен дә татыдык. Вакыт бар, рәхәтләнеп, иркенләп иҗат ит, яз, дигәндәй. Клара авылга әнкәсе янына кайтып китәндә, үзең генә калгач – гомумән, коммунизм. Әмма, юк кына бит, язып булмый ул юкта, кулдан эш китә.

Бер-береңнең камилрәк сыйфатларын сеңдерергә өйрәнергә кирәк. Гаилә тормышы ул шундый нәрсә – син анда үзеңнең асылыңны берничек тә яшерә алмыйсың. Әйтәм бит: адәм баласы, ни кызганыч, камил түгел. Гел начар якларны гына күреп торса, беркем дә беркем белән яши алмас иде. Ә минә берендә булмаган әйбәт сыйфатларны үзләштерергә омтылсаң, яки аларга соклану белән карый башласаң, яшәргә була. Бик матур итеп була яшәргә.

БЕЛЕШМӘ

Роберт Мөгаллим улы Миңнуллин – 1948 елның 1 августында Башкортостанның Илеш районы Нәҗәде авылында туа. Балачак һәм үсмер еллары Шәммәт авылында уза. Мәктәпне тәмамлагач, Уфа сәүдә-кулинария училищесына укырга керә. Берничә айдан туган авылына кайтып китапханәдә, аннары колхозда эшли. Ике ел «Маяк» исемле район газетасында әдәби хезмәткәр вазыйфасын башкара. Иҗат белән ныклап шөгыльләнүе дә шул елларга туры килә.

Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыганда Роберт Миңнуллин талантлы шагыйрь булып танылa. «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» газеталарында, «Казан утлары» журналында, «Идел» альманахында шигырьләре басыла. 1972 елда ул яшь шагыйрьләрнең 5нче Бөтенсоюз фестивалендә катнаша. Михаил Львов, Валентин Сорокин кебек танылган рус шагыйрьләре аның иҗатын уңай бәяли.

Университетны тәмамлагач, Роберт Миңнуллин «Яшь ленинчы» газетасында корреспондент булып эшли башлый. Лирик шигырьләр белән беррәттән, балалар өчен дә яза. Балалар шигырендә беренче булып өлкәннәр һәм балалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясындагы четерекле проблемаларны калку итеп чагылдыра алуга ирешә. Тәнкыйтьчеләр фикеренчә, моңарчы балаларныкы дип саналмаган темаларны да нәниләр поэзиясенә нәкъ менә Роберт Миңнуллин кертеп җибәрә. Ул балалар әдәбиятына, балалар язучыларына багышланган мәкаләләр яза, мәктәпләрдә очрашулар уздыра.

Роберт Миңнуллин лирик-фәлсәфи шигырьләре, публицистик язмалары белән дә билгеле язучы. Тәҗрибәле журналист һәм редактор. Шулай ук гомеренең күп елларын иҗтимагый-сәяси эшчәнлеккә багышлаган депутат та. Озак еллар дәвамында «Казан утлары» журналында – бүлек редакторы, җаваплы секретарь, Татарстан телевидениесендә – баш редактор, «Яшь ленинчы» («Сабантуй») газетасында мөхбир, баш редактор булып эшли. 1995–1999 елларда – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәни һәм милли мәсьәләләр комиссиясе рәисе, 2000–2004 елларда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары вазыйфаларын башкара.

Роберт Миңнуллин – Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортостан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре. Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Абдулла Алиш, Республиканың Муса Җәлил, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты. Шулай ук Башкортостан Республикасының Фатих Кәрим исемендәге һәм Халыкара Х.К. Андерсен исемендәге премияләр иясе.

Роберт Миңнуллин палатада ята. Авыру иренә карый да Клара ханым авыр сулап куя: «Их, Роберт, болай ярамый иде бит инде!» Тора-тора да тагын шул ук сүзләрне кабатлый. Тора-тора да тагын кабатлый. Артык күпкә киткәч, Роберт Миңнуллин түзми:

– Соң, мин дә үз гомеремдә бер ярамаган эш эшләргә тиештер бит инде? – дип кырт кисеп куя.

АЛТЫН УРДА ХАННАРЫ

Алтын Урда цивилизациясе һәм Алтын Урда дәүләтенең татарлар тарихында тоткан роле турында журналыбызның узган елгы 9–10 нчы саннарында язган идек инде. Ә хәзер шушы дәүләт белән идарә иткән ханнар турында бераз мәгълүмат биреп китәргә кирәк дип саныйбыз.

Автор:
Фаяз Хуҗин

АЛАР – БЕЗГӘ, БЕЗ АЛАРГА ЛАЕКМЫ?

Максатыбыз бит безнең, хәтерләсәгез, ике мең елдан артык тарихы булган халкыбыз арасыннан чыккан мәшһүр шәхесләр турында сөйләп, шуларга шәһәребез мәйданнарында, паркларда һәйкәлләр кую мәсьәләсен күтәрү дә әле. Алтын Урда ханнары бу хөрмәткә лаекмы?

Бик авыр һәм четерекле сорау бу. Алтын Урда (рәсми исеме – Җүчи Олысы) монгол-татарлар тарафыннан төрле илләрне, халыкларны басып алулар, йөзләгән калаларны яндырып-җимереп җир йөзеннән мәңгегә юкка чыгарулар, искиткеч кан коюлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән дәүләт ул. Соңгы елларда монгол-татар яуларының тискәре нәтиҗәләрен киметеп күрсәтергә омтылучы галимнәр төркеме барлыкка килде. Бәлки, чыннан да, Чыңгызхан оясыннан чыккан яугирләрнең вәхшилекләре элегрәк бераз арттырып күрсәтелгән булгандыр. Әмма аларның күбесе бит тарихи документлар белән расланган фактлар. Кабат исегезгә төшереп үтәм: монголларга кадәрге Идел Болгарындагы 100дән артык шәһәрнең бары тик 20се генә, 600ләп авылның 100гә якыны гына Алтын Урда чорында яшәвен дәвам иткән. Һәм иң аянычы – Болгар дәүләте үзенең суверенитетын югалткан. Без еш кына Казан ханлыгын яулап алган Явыз Иванны сүгәргә, барлык хәсрәтләрнең аннан башланганын расларга омтылабыз, әмма бит аңа кадәр Идел

Җучи хан

Болгарына кылыч тотып Чыңгыз онығы килә. Аның сәясәте тарихта шулай ук берьяклы гына шәрехләп һәм бәяләп булмый торган прецедент.

Әйе, сүз дә юк, монгол ханнары – Алтын Урда цивилизациясен тудыручылар. Әмма ул цивилизация татарларның гына мирасы түгел, ул мираска казахларның да, үзбәкләрнең дә, кырым татарларының да, башка төрки халыкларның да хакы бар. Алтын Урда бишегендә бердәм татар халкы барлыкка килде һәм үсте, диләр. Ай-һай… Чынбарлыкта исә хәзерге татар халкы башлыча элек болгарлар яшәгән җирдә формалашкан (хәзерге Татарстан, Сембер, Самара, Пенза, Мордовия, Пермь җирләре).

ЧЫҢГЫЗХАН – ТАТАРМЫ?!

Соңгы елларда тарихта, Чыңгызхан – татарлар нәселеннән чыккан шәхес булырга тиеш, дигән фикер урнаша бара. Димәк, без барыбыз да, Тимучин-Чыңгызхан кебек үк, баскын татарлар кавеменнән булып чыгабыз алайса? Мантыйкка сыя бу, тик фактлар белән генә раслыйсы бар. VI–VIII гасырлардан ук язма чыганакларда телгә алынган татарларны монголларга кадәр үк берничә дәүләт тоткан халык дип атыйлар. Моның да нигезе бар, әлбәттә (XIII–XIV гасыр фарсы тарихчысы Фазлуллаһ Рәшидетдиннең «Җамигъ әт-тәварих» әсәрендә якынча шулай диелә). Әмма ни өчендер бу дәүләтләрнең берсе дә чагыштырмача күптән түгел генә дөнья күргән 7 томлык «Татарлар тарихы»нда урын алмаган. Нindирәк дәүләтләр алар, кайсы җирләрне биләп торганнар, шәһәр-башкалалары булганмы, ханнары кемнәр? Бу турыда берәү дә белми, хәтта шул ук Рәшидетдин дә.

Кыскасы, инде аңлагансыздыр, мин, болгар бабаларыбызны онытып, хәзерге татарларны монгол яулары белән килгән татарлардан килеп чыккан, дип исбатларга омтылучы сәясәтчеләр яклы түгел. Шул ук вакытта, тарихыбыздагы Алтын Урданың урынын да инкарь итәргә ярамый, дип саныйм. Бу турыда киләчәктә дә язылыр әле.

Хәтер шундый нәрсә инде ул: еллар узган саен тарихи шәхесләргә бирелә торган бәя, заманга яраклаштырылып, үзгәреп тора. Александр Македонский – Шәрык илләрен канга батырган бөек илбасар. Наполеон Бонапарт – шулай ук бөек шәхес, гөнаһлары күптән онытылды инде. Явыз Иванга Россиядә узган ел һәйкәл салып куйдылар. Соңгы рус патшасы Николай II не («Канлы Николай») изгеләштерергә омтылалар. Миллионлаган совет кешеләренең җанын кыйган Сталиннан яңадан «сөекле юлбашчы» ясамакчылар… Һәм менә Чыңгызхан – канәчкеч җиһангир һәм акыл иясе. Аңа да һәйкәл куярга кирәк, дип җан атып йөрүчеләр табылып тора. Бәлки, чыннан да, шулай кирәктер?

ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ХАКИМЕ БУЛАСЫҢ КИЛСӘ…

Чыңгызхан (чын исеме Темучин) 1155–1162 еллар тирәсендә монгол бае Есүгәй гаиләсендә туган. Әтисе үлгәннән соң (имеш, аны татарлар үтергән) бөтен монгол кабиләләре өстеннән хакимлек итү өчен көрәш башлый. 1204 елда соңгы көндәше, найманнар башлыгы Таян-ханны җиңеп, 1206 елгы корылтайда бердәм Монгол иленең ханы – Чыңгызхан дип игълан ителә. Илдә «Яса» кануннары кертелә, әле һуннар чорыннан ук килә торган хәрби-административ система урнаша, һәрберсеннән аерым санда сугышчылар бирә торган берәмлекләр – «унлыклар», «йөзлекләр», «меңнәр», «төмәннәр» билгеләнә. Чыңгызханның төп максаты – дөнья халыклары хакиме булу. Көчле һәм каты тәртипкә нигезләнгән гаскәр төзелә. 1207–1211 елларда Чыңгызхан армиясе Себер һәм Көнчыгыш Төркестан халыкларын (бурятлар, якутлар, ойротлар, кыргызлар, уйгурлар) буйсындыра, 1217 елда Кытайның Хуанхэ елгасыннан төньякта яткан җирләре басып алына, 1219–1221 елларда Урта Азия халыклары буйсындырыла. 1223 елда Калка елгасы буендагы сугышта рус-кыпчак гаскәрләре җиңелә, әмма Самара Дугасы янында булып үткән болгар-

Чыңгызхан

Фотолар автордан алынды

лар белән сугышта монгол-татарлар беренче мәртәбә үзләре җиңелү ачысын татыйлар. Аның каравы, Чыңгызхан 1227 елда Си-Ся (тангутлар) дәүләтенә каршы сугышны җиңү белән тәмамлый. Шул ук елны ул гүр иясе була.

Күргәнегезчә, Чыңгызхан ул – бердәм Бөек Монгол дәүләтен төзүче һәм гомерен сугыш эшенә багышлаган талантлы полководец. Әйе, Чыңгызхан башлап җибәргән хәрби сәясәт нәтиҗәсендә дөнья картасы тамырыннан үзгәрә.

Бату хан (Батый)

БОЛГАРГА – ЯРЛЫК АЛЫРГА...

Азиядә һәм Европада башланып киткән сугышларны Чыңгызханның уллары, оныклары дәвам итә. Аларның берсе – **Бату хан (Батый).** Ул – Чыңгызханның оныгы, Җучиның улы. Чама белән 1207 елда туган. 1227 елда әтисе үлгәч, аның Олысын (яулап алынган җирләрен) мирас итеп ала. Бөтенмонгол корылтае карары нигезендә Батуны Җучилар ыруының башлыгы һәм Көнчыгыш Европа илләрен яуларга җибәреләчәк гаскәрләрнең башкомандующие итеп билгелиләр. 1229 елда Батый гаскәрләре, Көньяк Урал, Түбән Идел буйларына чыгып, кыпчак һәм саксин җирләрен басып алалар. 1232 елда Идел Болгарстанына яу оештырыла, әмма Биләр тирәсендә аларны кире борылырга мәҗбүр итәләр. 1236–1237 елларда Батый сугышчылары кыпчакларны буйсындыралар, Идел Болгарстанын һәм аның башкаласы Биләрне (Бөек шәһәрне) тар-мар итәләр, аннан соң Русь кенәзлекләренә таба юл тоталар, бер-бер артлы аларны да җиңелүгә дучар итәләр. 1240 елда Киевны алганнан соң, Батый гаскәрләре Көнбатыш Европага ыргыла. Венгрия, Польша, Чехия, Болгария территориясендә уңышлы сугышлар алып бара.

1241 елның ахырында, Үгәдәй каан (каган – бөек хан) үлгәннән соң, Бөек Монголия империясенең яңа каанын сайлаячак корылтайга чакыру килгәч, Батый, Көнбатыш Европада сугыш хәрәкәтләрен туктатып, кире Түбән Иделгә әйләнеп кайта, Монголиягә барудан баш тарта һәм биредә яңа дәүләт – Җучи Олысын төзү эшләренә чума. Үзенең ставкасы итеп Батый хан Болгарны сайлый, әмма башкала сыйфатында Түбән Иделдә Сарай исемле шәһәргә нигез сала (Сарай әл-Мәхрүсә, хәрабәләре хәзерге Әстерхан тирәсендә).

Батый ханның 1242–1256 еллар эчендәге эшчәнлеге башлыча тыныч шартларда үтә. Ул, туып килүче дәүләтнең киләчәге турында кайгыртып, аның эчке һәм тышкы сәясәтенә кагылышлы мәсьәләләрне хәл итә, басып алынган җирләр белән идарә итү системасын эшли. Җирле халыкларга еллык керемнең 10 проценты күләмендә салым салына, элеккеге Болгар җирләре һәм рус кенәзлекләре белән идарә итүчеләр өчен ярлык системасы кертелә. Рус кенәзләре хан кулыннан ярлык алыр өчен Болгарга килергә тиеш булалар. Батый хан Рим папасы, Әрмән патшасы, Сөлҗекләр солтаны белән дипломатик сөйләшүләр алып бара, яңа дәүләтне халыкара таныту өчен көрәшә. Шулай да ул әле тулы мөстәкыйльлеккә ирешә алмый, Бөек Монгол кааныннан бәйле булып кала, еллык керемнең билгеле бер өлешен Каракорымга җибәреп барырга мәҗбүр ителә. Батый хан хакимияте чорында Алтын Урданың (Җучи Олысының) якын киләчәктәге икътисадый һәм хәрби куәтенә нигез салына.

Әмма безнең тарихыбызга Батый Идел Болгарстаны дәүләтен җимерүче сыйфатында кереп калган. Болгарларның монгол-татар баскыннарына каршы Баян һәм Җик җитәкчелегендәге баш күтәрүләре дә Батый хан идарә иткән чорга туры килә (1238–1244 еллар тирәсе).

Фотолар автордан алынды

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕККӘ ЮНӘЛЕШ АЛЫП...

1256 елда, Батый хан үлгәннән соң, Бөек Монгол кааны Мунке тәхеткә аның өлкән улы Сартакны – бердәм Монголия империясе тарафдарын утырта. Тик яңа ханга озак идарә итәргә туры килми, шул ук елны Каракорымнан Сарайга кайтып барышлый аны үтерәләр. Мунке каан тарафыннан тәхеткә тәгаенләнгән Сартакның улы Улакчы да хан тәхетендә берничә ай гына утырып кала. Ул да, әтисе кебек үк, төрле юллар белән тәхеткә омтылучы Бәркә оештырган җинаятьчел төркем корбаны була.

Җүчи ханның улы **Бәркә,** өлкән туганы Батый белән бергә, 1236–1242 елларда Идел Болгарстанына, рус кенәзлекләренә һәм Көнбатыш Европа илләренә каршы сугышларда катнаша. Аңа Төньяк Кавказ далаларын олыс итеп беркетәләр. Ул да, абыйсы Батый кебек үк, Җүчи Олысының Бөек Монгол империясеннән аерылып чыгуы өчен көрәшә, мөстәкыйльлек тарафдары була. Батый хан әле үзе исән вакытта ук энесенә, аның хакимлек итәргә яратучан холкын сизеп, шикләнебрәк карый, тиешле олысын да Сарайдан ераграк җирдән бүлеп бирә. Әлбәттә, бу шикләнүләр нигезсез булмый: Бәркә тәхеткә 1257 елда Батыйның улы Сартакны, оныгы Улакчыны һәм Баракчин исемле хатынын үтереп килә.

Шулай да Алтын Урда дәүләтендә Бәркә хан тарафыннан үткәрелгән һәм илнең куәтен арттыруга юнәлтелгән эчке сәясәтне уңышсыз дип бәяләп булмый. Мәсәлән, шәһри Болгарда Җүчилар тамгасы белән, ләкин әле һаман да Бөек Монгол кааны исеменнән беренче Алтын Урда акчалары сугыла башлый, яңа акча-үлчәү нормалары кертелә. Илдә салым җыю системасын камилләштерү максатында халык санын алу үткәрелә, бу эш баскаклар тарафыннан башкарыла. Яңа шәһәрләр калкып чыга, һөнәрчелек үсә, күрше дәүләтләр белән сәүдә мөнәсәбәтләре җайга салына.

Бәркә хан Алтын Урда халыклары арасында ислам динен таратуга, мәчетләр төзелешенә, дини мәктәпләр ачуга да нык игътибар бирә. Сарай даирәсендә ерак Шәрык илләрендә укып кайткан югары белемле дин әһелләре күренә башлый. Шул ук вакытта илнең башкаласы Сарайда православие епархиясе дә барлыкка килә.

Бөек Монгол империясеннән бәйле булып калса да, Бәркә хан мөстәкыйль тышкы сәясәт үткәрә. 1258–1259 елларда ул Литвага һәм Польшага яу оештыра, 1262 елда инде Монголия империясеннән аерылып чыгарга өлгергән Хулагу ханга каршы сугыш башлый. 1263 елда Төньяк Азәрбайҗан территориясен басып ала. Алай гына да түгел, Бәркә хан гаскәрләре Византия башкаласы Константинопольгә һәм Болгариягә кадәр барып җитәләр. Сугышлар барышында Бәркә хан Сөлҗек төрекләре һәм мәмлүкләр Мисыры белән килешүләр төзергә дә өлгерә. 1266 елда Кавказ аръягы халыкларына каршы оештырылган яудан кайтканда вафат була.

Җүчи Олысының хан тәхетен Батый ханның оныгы **Мәнгу-Тимер** яулап ала. Ул Бәркә ханның Монгол империясеннән аерылып чыгу сәясәтен дәвам итә һәм бу өлкәдә зур уңышларга ирешә. Нәкъ менә Мәнгу-Тимер вакытында Алтын Урда/Җүчи Олысы, ниһаять, мөстәкыйль дәүләткә әверелә: Болгарда һәм башка шәһәр үзәкләрендә Алтын Урда акчалары Җүчилар тамгасы белән, ләкин Монгол империясенең бөек ханы исеме урынына Мәнгу-Тимер исеме куеп чыгарыла башлый. Каракорымга салымнар җибәрү дә туктатыла. Шулай итеп, Алтын Урда дәүләтенең оешу чоры чирек гасырдан артык вакытны ала.

«РӘХИМ ИТЕГЕЗ, БАЛАЛАР!»

6 июньдә Гүзәл Яхина Казан Ратушасында үзенең яңа китабын – «Дети мои» әсәрен тәкъдир иткән иде. Казанда аның иҗатын яратучылар шактый күп булып чыкты – Ратуша залында алма төшәр урын да юк иде. «Мин аны тәмамладым, хәзер китап мөстәкыйль үз тормышы белән яши башлады, укучылары арасына сәяхәткә китте», – дип ассызыклады аның авторы. Әйтергә кирәк, «мөстәкыйль тормыш» белән яши башлаган китап инде сатылу буенча беренче китап феноменын кабатлап та килә.

Автор:
Луиза Янсуар

ЯЗУЧЫ ҺӨНӘРЕ ҺӘМ ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК ТУРЫНДА

Без Гүзәл Яхинаның икенче романын өч ел буена көттек. Монысы да бестселлер булырмы, юкмы? Өч ел аның беренче романына гашыйк булган укучылар һәм фанатлар өчен, бәлки, бик озак вакыт булып тоелгандыр. Әмма авторның үзе өчен – алай түгел, билгеле. Чөнки шушы өч ел эчендә ул Россия тарихындагы тагын бер фаҗигале сәхифәне өйрәнү белән мәшгуль булды: Идел буендагы немец колонияләре тарихын.

Матбугатта һәм җәмәгатьчелектә аның исемен уйнатып, «беренче роман феномены ул әле уңыш турында сөйләми» диючеләргә, асылда, Гүзәл Яхина күтәргән пластлардан бигрәк, аның образы кызыклы. Укучыларга исә – ул сөйләячәк тарих. Ә менә әдәби барыш һәм торыш турында уйланучыларга, әдәбиятның кеше аңын формалаштырудагы әһәмиятле роленә инанганнарга – барлык аспектлары да. Гүзәл Яхина феномены бүгенге көндә, чыннан да, бик күпләрне дулкынландыра – кем ул, каян килеп чыкты да ни өчен әле шулай кинәт кенә популяр булып китте? Еш кына аны әйбәт пиар аркасында «йолдыз»га әйләнде, дип күрсәтергә тырышалар. Мин «йолдыз» сүзен әдәбиятка кагылышлы куллануны гомумән әдәпсезлек билгесе дип саныйм. Чөнки башка барлык профессиональ сәнгать тармаклары кебек әдәбият та (сүз массачыл, бер көнлек, шактый түбән ихтыяҗларга җавап бирә торган продукция турында бармый, гәрчә кулланучыларның кайсыдыр катламына нәкъ менә шунысы гына хаҗәт булса да – авт.) – зур хезмәт нәтиҗәсе. Текст тудыру – ул катлаулы һәм акыл белән сәләтне эшкә җигеп, зур тырышлык сарыф итеп башкарылган процесс. «Тырышлык», бәлки, иң әһәмиятле компонентларның берседер. Шуңа да әле икенче генә китабын әзерләп чыгарган язучының үз һөнәренә җитди каравын һәм искиткеч хезмәт сөючән булуын исәптән алып ташларга тиеш түгелбез. Архивларда утырып, һәр тарихи фактны энә күзеннән үткәреп, җентекләп тикшереп, кыйпылчыклап җыю – бу «йолдызлык» күренеше түгел, ә профессиональлек дигән сүз.

Фотолар: fotostarina.ru, eksmo.ru сайтларыннан алынды

Гүзәл Яхинаның беренче романы «Зөләйха күзләрен ача» кебек үк, «Дети мои» әсәре дә Елена Шубина редакциясендә басылып чыкты. Әсәр 2018 елдагы Тоталь диктант вакытында укылды.

«ИГЕЛЕКЛЕ ТУФРАК», ЯКИ ҖИРДӘГЕ ҖӘННӘТ – УЛ НИНДИ?

Архивлардагы документлар белән эш итеп, фактларны анализлап, чорның картинасын тудырырга мөмкин, әлбәттә. Әмма бу коры фактларга корылган картина гына булачак. Ә бит кешеләр эмоцияләр, иллюзияләр, хыялөметләр белән яши. Без һәммәбез дә – туктаусыз рефлексиядә. Гүзәл Яхина әсәрендә, архивариусларча төгәллек белән бергә, кеше психологиясенә дә зур урын бирелүе белән очрашабыз. Соңгысына басым ясаганда, Гүзәл аң төпкеленә, бездә борынгыдан килгән кодлар, символлар, архетиплар яшәгән катламга мөрәҗәгать итә. Бу катлам, асылда, бик күп тышкы факторларны да билгели. Чөнки тарихны әнә шул кодларны йөрткән аерым бер кешеләр һәм алардан җыелган коллективлар яза. Ә инде архетиплар, калкып чыгып, массага тәэсир итә башлагач, алар үз эшен тәгаен башкара.

Әйтик, Совет системасы урнашкан дәвердә дә барыбер империя булудан туктамаган, хәтта тагын да хәтәррәк төсмер алган Россия формациясендәге «Он» дигән фигураның роле турында сөйли безгә Яхина әсәрендә. Билгеле инде, Сталинга ишарә икәнлегеи аңлыйбыз. Әмма бер үк вакытта бу символ тагын да киңрәк периферияга һәм мәгънәви катламнарга ия – ул гомумән Юлбашчы, тарихның кайбер бормаларында актуальлеге көчәйгән Мәңгелек диктатор буларак та укыла ала, билгеле бер милләтләрнең Табыну объекты, үзе китереп чыгарган Уйдырмасы буларак та. Кемнеңдер каты кулына сусау – моның Россия массачыл үзаңындагы үзгәрешсез калган бер психологик сыйфат икәнлеген аеруча калкытып күрсәтә автор. Шуңа ул аны исемнәр кушып билгеләп торуны да зарур тапмый, бу коллективның тәгаенләп куйган кемедер – императормы, генсекмы, президентмы, рейх хуҗасымы... Әби патша кайчандыр: «Рәхим итегез, балалар!» – дип каршы алган килмешәкләр дә Россиянең әлеге үзенчәлеген танырга мәҗбүр. Гәрчә, аерым бер утраучыктагы сыман, Россия империясе үзәгендә бөтенләй башка чынбарлыкта яшәсәләр дә.

Безгә тәкъдим ителгән тариххрониканың башында әсәрнең төп герое – шульмейстер Бах – көннәр буе колонистларның балаларына югары немец телендә дәрес укыта, кичләрен Гётены укуга багышлый, немец музыкасын тыңлый, еракта калган тарихи ватаны турында уйлана. Көндәлек тормышта бил бөгеп хезмәт итүче башкаларның, бәлки, тарихи хәтер турында уйланырга анык кадәр мөмкинлеге дә калмыйдыр, әмма Бах шуңа да аерым бер, үзгә зат. Аның һәр иртәдә билгеле бер вакытта чаң сугып халыкны уятуы, йокыга әйдәп кичке тугызда янә чаң кагуы – болар күп нәрсә турында сөйли. Ә йокы алдыннан Бах үзләренең тарихын теркәп калдырган борынгы хроникаларны укый.

Хроники переселения германских крестьян в Россию повествовали о днях, когда по приглашению императрицы Екатерины первые колонисты прибыли на кораблях в Кронштадт. Бах дочитал уже до момента, когда монархиня самолично является на пристань – поприветствовать отважных соотечественников: «Дети мои! – зычно кричит она, гарцуя перед строем озябших в пути переселенцев. – Новообретенные сыны и дочери российские! Радушно принимаем вас под надежное крыло наше и обещаем защиту и родительское покровительство! Взамен мы ожидаем послушания и рвения, беспримерного усердия, бестрепетного служения новому отечеству! А кто не согласен – пусть нынче же убирается обратно! Гнилые сердцем и слабые руками в российском государстве – без надобности!..»

Һәм менә бу зур пафос белән кабул ителгән яңа Адәм белән Хәвалар, Идел ярында тормыш корып җибәреп, Россия туфрагына тамыр җәяргә сүз бирә. Һәм – җәяләр дә. Алай гына да түгел, ул туфракны тире һәм каны белән ашлап та киләләр. Тик без онытмыйк: күңеле белән һаман да немец теленең матур борылышлары, немец әдәбиятының шомлы-куркыныч та, искиткеч сокландыргыч та персонажлары арасында гомер кичкән, чынбарлыкка кайтып-китеп кенә йөргәләгән Бах кебекләргә вазгыятьне анализлау һәм аны акылга сыйдырырга тырышу сыйфаты да бирелгән бит әле. Һәм менә Бах белән романның башка каһарманнары күз алдыннан сугыш, түнтәрелеш картиналары уза башлый, Идел буендагы ачлы-туклы, адым саен хәтәр янап торган тормыш аларны үз зилзиләсе эченә бөтереп ала. Бах Бертуган Гриммнарның персонажлары белән чынбарлыктагы затларның арасында, нигездә, аерманың әллә ни зур булмавына инана.

Уен элементына, ироиягә һәрчак нечкә, үтемле төсмер бирергә сәләтле Яхина юкка гына Кларапы «фройлян Гримм» буларак тәкъдим итми безгә. Әлеге кызны укытырга күрше колонияләрнең берсенә махсус чакыралар Бахны. Андагы ситуация Гнаденталь («игелекле туфрак» дигән мәгънәгә ия – авт.) колониясендәгенекеннән аерыла: халыкны анда Бах кебек агартып яшәүче юк чөнки. Нәкъ менә Клара образы аша Идел буендагы колонистларның күпчелегенә хас кузаллау моделен ирештерә безгә автор. Ә чагыштырып карасак, ул безнең бүгенге киң масса тарафыннан тирәлегебезне күзаллау моделеннән әллә ни аерылмый:

Девица, при всей нежности ее голоса и деликатности в общении, была невежественна, как африканская дикарка. Из всей географии она твердо знала о существовании лишь двух стран, России и Германии, а также одной реки – Волги; причем река эта, по Кларину разумению, соединяла оба государства, так что из одного в другое можно было переместиться при помощи плавательных средств. Остальной мир представлялся Кларе темным облаком, окружающим известные земли, – дальше родного волжского берега познания девицы не простирались... Вопрос же о конфигурации Земли и наличии в космических высях прочих планет привел Клару в полное смущение. Об астрономии на хуторе Гримм и не слыхивали. Как, впрочем, и о Гёте с Шиллером.



Бах яза, яза, яза... ә сабый көннән-көн тернәкләнә бара... Әкренләп үзе язган чынбарлык-әкиятләрне бәләкәй кызга – Анчега сөйли башлый элеккеге шульмейстер...

Он так и не понял окончательно, для чего неутомимому Гофману потребовались сказки. Уяснил только, что заметки о настоящей жизни потеряли прежнюю ценность. Отныне Гофман ждал от него – вымысла...

ЧЫНБАРЛЫККА КҮЧКӘН ӘКИЯТЛӘР

Ахыр чиктә, куркуга һәм рефлексиягә корылган, югары культураны саклауны төп яшәү рәвешенә әверелдергән интеллигенция вәкиле булган каһарманыбыз, ни кызганыч, зур зилзиләләргә каршы торырдай булдыклы һәм китап геройларыча куркусыз зат булып чыкмый. Буржуаз сословиенең кануннарын җиңеп чыгып, нәселенә, классына каршы барган Клара, аңа зур өметләр баглап килсә дә, өметен өзә. Ә аннан үз эченә бикләнеп яшәгән, тормышы рефлексиягә бирелеп узган, ләкин күңеле белән этик, эстетик категорияләрнең сагында торган Бах өчен этәргеч көч булып әверелә.

Дөнья дилбегәсен дә үз кулларына эстетик яктан әллә ни нечкәлеккә, зәвыкка ия булмаса да, нәфес, дәрт, яшәүгә омтылыш, яулап алу рухы ташып торган «яңалар» ала. (Совет хакимиятенең ыжгырып торган көче нәкъ менә «искелек»не себереп түгүгә нигезләнгән була да, беләбез.) Менә алар, тантанасын яшермичә, сөрән сала: «Радуйся, дядя! А то ведь так и помрешь, не узнав! Республика нынче родилась – советская республика немцев Поволжья!..» Менә шушындый абсурд детальләр, сюрреалистик, психоделик борылышлар белән Бахның эчке дөньясын параллель яссылыкта куеп күрсәтеп бара автор. Бу ике дөнья берберсен тудыра да, юк та итә, яңадан яшәртә дә... Борылышларның берсендә тоташ поэзия белән яшәгән Бахка сөйгәнен дә «яңалар» кулына мәсхәрәгә тапшырырга туры килә. Әмма һәр яманның яхшы ягы, һәр яхшының яман әверелеше барлыгын исбат иткәндәй, нәкъ менә шул вакыйга Бахның хроникер булып китешен дә тәэмин итә. Аңа эти, укытучы, остаз булу бәхетенең дә кыска гомерле мизгелләрен татып калырга мөмкинлек бирә.

Некоторые колонисты решились бежать от этой непонятной жизни: самые прыткие и бесстрашные добрались до Америки, самые настойчивые и пронырливые – до исторической родины; большинство же, промаявшись по лагерям беженцев в Белоруссии, Украине и Германии, стеклось обратно в Гнаденталь – все реки текут, как известно, в Волгу.

Так он и жил, этот новый Гнаденталь, который теперь полагалось называть советским: полуразвалившаяся колония, полуотчаявшиеся жители, полуголодный скот. Лица людей были иссушены нуждой и тоской...

Менә шушы ачлык хөкем сөргән, зилзилә булып сугыш, инкыйлаблар сөреме үткән туфракта, яңа туган сабый белән берьялгызы калган Бах, әллә тилергән, әллә, киресенчә, акылның кеше аңы ваемлый алмый торган катламына күчкән сәер зат – Бөкре Гофман белән бергә борынгы немец мәкальләрен туплый башлый. Гнаденталь-ның тарихын яңабаштан яза бу икәү. Аларның икесенең дә «Идел буе немцы» дигән исем йөртүче затның асылына төшенәсе килә. Гофман Бахка бу тарих өчен стаканлап сөт белән түли. Ә сөтне башкача ничек юнәтәсең ди ачлык хөкем сөргән «игелекле туфрак»та?!

Ә безгә боларны нигә сөйли Гүзәл Яхина? Иллюзияләргә корылган, көч куллануга, халыкны изүгә нигезләнгән дөнья моделеннән безнең әле һаман да арынганыбыз юк, дияр өченме? Курку, корбанлык фәлсәфәсен канылбызга сеңдергәнбез – шуны күрсәтәсе килепме? Ә бәлки, әнә теге, заманында Булгаковның «Мастер и Маргарита» романына эпиграф булып киткән Гёте тәгъбирен күздә тотыптыр: «Я – часть той силы, что вечно хочет зла и вечно совершает благо».

БЕЗНЕҢ ҖӘРӘХӘТЛӘР – КАЙДАН?

Фольклорга, милли архетипларны үзендә саклап килгән риваять-легендаларга мәхәббәтем көчле булганга, бәлки, минем үземә Гүзәлнең алар белән эш итүе, һәм, әйтергә кирәк, виртуозларча эш итүе ошый. Хронотопны уңышлы сайлавы. Ул һәр очрашуда, интервьюсы вакытында кабатларга ярата: «XX йөзнең 20–30 нчы еллары – совет хакимияте урнашу дәвере. Бу чор миңа һәрвакыт кызыклы иде. Миңа калса, безнең халыкның бик күп тирән күңел җәрәхәтләре шул чорда уелып калган. Һәм без әле ул травмалар белән һаман да яшибез, котыла алмыйбыз».

Идел буе немецлары турында роман язуы турында белдергәч үк, Гүзәл Яхинаның яңа әсәренә карата кызыксыну бермә-бер көчәйде. Дөрес, безнең әдәби-мәдәни җәмәгатьчелек аңардан башканы өмет итә бирә әле – «татарча» темаларны күтәрүен. Әйтик, нишләп ул Идел буендагы ачлык турында, татарның күренекле шәхесләре хакында язмый, ник ул татар архивларында казынмый? Әмма бу очракта Гүзәл мәсьәләгә ачыклыкны әлеге дә баягы Ратушадагы очрашу вакытында кертеп узды: «Мине татар

Фотолар: fotostarina.ru, eksmo.ru сайтларыннан алынды

язучысы дип түгел, ә Казан язучысы дип атауларын кулайрак күрәм. Ә Казан белән бәйле тема... минем өчен бик нәзберек тема, бәлки, кайчан да булса аңа алынырмын. Әлегә әзер түгелмен. Ни өчен немецлар турында язуыма килгәндә, мин җентекләп немец телен өйрәндем, немец мәдәниятен азмы-күпме беләм, шуңа да аларның Россия контекстындагы, бигрәк тә Идел буендагы язмышына бәйле әсәр язасым килде. Бу романымда шул чорның тарихи полотносын күпмедер дәрәҗәдә чагылдыра алсам, максатыма ирешкәнмен, димәк. Без тарихны тоташ бер линия буларак кына күзаллыйбыз, әмма тарих ул – чатырман. Андагы тамырлар һәм ботаклар бер-берсенә тоташып, укмашып беткән...»

«Дети мои» әсәрендә дә шулай: Мёбиус тасмасы буйлап йөрисең гүяки. Автор фактларны, реалистик детальләрне китереп бирә дә, каһарман Бахның календарьдә язылмаган эчке вакытына алып кереп китә, аның аша без инде югарыда әйтелгән Гримм әкиятләренә дә килеп чыгабыз, Гёте символларына да, шул тирәлектә таралган диалектларга һәм риваятьләргә дә. Төсләр, исләр, камашып, аңкып, күзгә һәм борынга килеп бәрелә. Бах белән аның көндәлек сәфәренә чыкканда, аякларга Идел ярының ләме ябышып кайткандай була, аның авырлыгын физиологик яссылыкта сизәсең хәтта. Совет мифы белән әкият арасында йөрийөри, укучы бермәлне гомумән реаль вакыт дигән төшенчәне җуя, чайкалып куя – әйтерсең, аны кемдер аңгырайткан, кемдер аның хәтерен агулаган. Әнә шул эффект чынлыкта тулы бер халык хәтере белән нәрсә эшләгәннәренә ишарә ясый да, айнып китәсең. Бу үзенә күрә бер психоделика аша катарсиска китерү ысулы, дияр идем. Әдәбиятта, әдәбият белеме фәнендә бүген «галлюциноген реализм» дигән төшенчә популяр кулланылышта, Гүзәл Яхина очрагында ул ирексездән телгә килә. Ә бит көндәлек тормышның психоделикасы белән әкият дөньясы, фольклор психоделикасы искиткеч дәрәҗәдә якын, бер уйласаң.

Тарих полотносына чигеп куелган кечкенә кешеләрнең фаҗигасе турында да, «Он» шикелле гигант күләгә ташлап тормыйча гына кылган каһарманлыгы турында да бу роман. Һәм, әлбәттә, курку турында. Ул куркуның кырку да, татлы да тәме, Бахның бакчасында, сараенда өелеп яткан алма тәмен хәтерләтеп, тынга килеп каба да, хәтта мин, инде XXI гасыр вәкиле дә, сискәнеп китәм. Ә аннары Ноябрьнең торгынлыкка күчкән сулышына җитеп, бөтенләй абынам. Минем генетик хәтерем абына, ягъни.

Рәхим итик, без, балалар, «игелекле туфракка», дип, әсәрнең үзенә күрә кисәтү булуына ишарә итәсе килә. Әйе, икенче төрле кисәтү, «Тайгак кичү», «Афәт», «Колыма хикәяләре», «Архипелаг ГУЛАГ»лар рухындагы түгел... Әмма Бахның үзеннән соң балаларына калдырырга теләгән хроникасында без аларның мифологик төеннәрен аермачык күрәбез. Гомеренең яртысын эндәшмичә, сөйләшмичә уздырган шульмейстерның һичбер тарих дәреслекләреннән укып өйрәнеп булмастай календарена күз төшерү дә комачауламас.

КАЛЕНДАРЬ ЯКОБА ИВАНОВИЧА БАХА

1918 – Год Разоренных Домов
1919 – Год Безумия
1920 – Год Нерожденных Телят
1921 – Год Голодных
1922 – Год Мертвых Детей
1923 – Год Немоты
1924 – Год Возвращенцев
1925 – Год Гостей
1926 – Год Небывалого Урожая
1927 – Год Плохих Предчувствий
1928 – Год Спрятанного Хлеба
1929 – Год Бегства
1930 – Год Возмущения
1931 – Год Большой Лжи
1932 – Год Большой Плотины
1933 – Год Большого Голода
1934 – Год Большой Борьбы
1935-1938 – Годы Вечного Ноября, Годы Рыб и Мышей

Әсәрнең эпилогында Гүзәл Яхина кыскача гына тарихи белешмә бирә: «Якоб Иванович Бах 1938 елда кулга алына һәм 15 елга хезмәт лагерьларында эшләргә хөкем ителә. 1939 елда аны этап белән Казахстан АССРның Караганда лагерена җибәрәләр. 1946 елда ул, башка 11 тоткын белән бергә, шахта җимерелгәндә, таш һәм балчык астында калып һәлак була». Аның «балалары» – Клара белән Васьканың язмышына эпилогта шулай ук урын бирелгән.

«БЕЗ УЛ – БЕЗ УКЫГАН КИТАПЛАР»

Балачакта миңа иң зур тәэсир ясаган китапларның берсе – Николай Кунның «Борынгы Греция мифлары һәм легендалары» китабы. Бу фантастикага тиң китап балачагымны билгеләде. Чын мәгънәсендә кеше язмышлары энциклопедиясе, зур тәҗрибә бирә торган китап ул. Андагы мифларның әхлакый мантыйгы миңа – ул чактагы совет баласына, пионеркага – аңлашылып бетми иде, китапны кайта-кайта, бик кызыксынып укыдым.

Яраткан китаплар кешенең яшенә бәйле дип уйлыйм. Кайчандыр бу Бертуган Гриммнарның әкиятләре белән легендалары җыентыгы иде. Аннан Александр Дюманың «Граф Монте-Кристо»сы җәлеп итте. Үсә төшкәч, яраткан китаплар исемлегенә Эрих Мария Ремаркның « Три товарища»сы, Федор Достоевскийның «Идиот»ы өстәлде... Бүген яраткан авторларым: Людмила Улицкая, Евгений Водолазкин һәм Алексей Иванов.

Кайта-кайта укыган китабым – Кларисса Пинкольның «Бегущая с волками» китабы. Авторы – Юнг мәктәбенең дәвамчысы булган психоаналитик. Пинколь мифның бүгенге көндә безнең тормышыбызда тоткан әһәмияте турында яза. Әкиятләрдәге архетиплар әле бүген дә яши, безгә тәэсир итү көчен дәвам итә.

Иң соңгы тетрәндергән әсәр – Джонатан Литтеллның «Благоволительницы» романы. СС офицеры исменнән бара бәян. Каһарман Икенче Бөтендөнья сугышы чорында Германия армиясе белән Европа аша Советлар Союзына үтеп керә. Без аның «яһүд мәсьәләсе»ндә соңгы карар кабул итүдә, концлагерьлар төзүдә, кешеләрне юкка чыгаруда ничек катнашканын күрәбез. Романны яшь кенә немец авторы язган, шунысы гаҗәп! Ничек ул материалга шул дәрәҗәдә тирән үтеп керә алды икән, белмим, чөнки текстны укыганда чәчләрең үрә тора!

Сезгә дә укырга тәкъдим итәм. «Рус Букер»ын алган Елена Чижованың «Время женщин» әсәрен. Өч әбинең бер кечкенә кызны ничек тәрбияләп үстерүләре турындагы романда тулы бер эпоханың чагылышын күрергә мөмкин. Чөнки әбиләр әле революциягә кадәр үк туып, бер гасырны кичкән затлар. Менә дигән тел белән язылган чын мәгънәсендә затлы интеллектуаль проза өлгесе.

Хәзер укый торган китабым – Александр Талаланың «Миф и жизнь в кино» дигән сценарий осталыгы буенча дәреслеге. Искиткеч тирән китап, автор сюжет корылышында мифларның ничек кулланылышын күрсәтә. Талал китабы беренче чиратта сценарий язучыларга юнәлтелгән булса да, уйдырма белән эш итүче теләсә кайсы иҗатчыга кызыклы тоелыр. Биредә минем өчен гаять әһәмиятле булган мәсьәләгә зур игътибар бирелә: автор текстында миф белән чынбарлыкның бәйләнеше ни дәрәҗәдә? «Дети мои» романын язганда, аңа еш мөрәҗәгать иттем. Кайбер сорауларыма җавап та таптым, дәлилләр дә.

Без ул – без укыган китаплар. Нәкъ менә алар безнең нинди булуыбызны билгели.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

МАХСУС ПРОЕКТ

— 33нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Наил Маганов, «Татнефть» ГАҖнең генераль директоры, июльдә үзенең 60 яшьлеген билгеләп үтә

Юбилеегыз яңа идеяләр һәм иҗади проектларыгызны тормышка ашыру өчен этәргеч булсын!

Александр Лаврентьев,
ТР Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе президенты

Алексей Пахомов,
ТР Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе генераль директоры

Хөрмәтле Наил Өлфәтович!

Татарстан Республикасы Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе, республиканың директорлар корпусы исеменнән Сезне 60 яшьлек юбилеегыз белән ихлас котлыйбыз!

Хезмәт юлыгыз – олы казанышлар һәм әһәмиятле нәтиҗәләргә ия юл. Без Сезне тирән белемле инженер, җитештерүне оста итеп оештыручы талантлы җитәкче буларак беләбез.

Бүген, әйдәп баручы дөнья нефть компанияләренең берсенә җитәкчелек итеп, Сез республиканың социаль-икътисадый торышын ныгытуга зур өлеш кертәсез.

Бала чактан ук туган җирегез – нефтьчеләрнең данлы шәһәре Әлмәтнең рухын үзегезгә сеңдереп, профессиональ карьерагызны гомерлеккә Татарстанның нефть сәнәгате белән бәйләгәнсез. Һәм бүген туган республикабызда Сезнең җитәкчелектә нефть табу күләме туктаусыз үсә.

«Татнефть» ГАҖгә җитәкчелек итү – Сезнең язмышыгыздагы мөһим һәм мәгънәле чор булып тора. «Татнефть» һәрвакыт Татарстанның горурлыгы булды һәм шулай булып кала да. Ул – халыкара дәрәҗәгә, заманча администрациягә, биниһая зур техник потенциалга, меңләгән хезмәткәрне туплаган профессиональ коллективка ия булган әйдәп баручы югары технологияле дөнья компанияләренең берсе. «Татнефть», мәдәни һәм спорт проектларына, фәнгә, шулай ук яшьләргә һәм ветераннарга даими ярдәм күрсәтеп, чын-чынлап социаль юнәлешле оешма буларак, үз тарихын кадерләп саклый һәм традицияләрне дәвам итә. Һичшиксез, тотрыклы эш һәм уңышлар – Сезнең һәм фикердәшләрегез командасының зур казанышы.

«Татнефть» ГАҖ һәм Ассоциация арасында урнашкан эшлекле һәм нәтиҗәле мөнәсәбәтләрне без югары бәялибез.ТР ПСА эшчәнлегенә керткән зур һәм әһәмиятле өлешегез өчен без Сезгә рәхмәтле. Нәтиҗәле хезмәттәшлегебезнең дәвам итәчәгенә ышанабыз.

Хөрмәтле Наил Өлфәтович, Сез юбилеегызны тормыш һәм иҗат көчләрегез чәчәк аткан хәлдә каршылыйсыз. Юбилей датасы Сезнең өчен яңа идеяләрне, профессиональ планнарны һәм иҗади проектларны тормышка ашыру өчен этәргеч булыр, дип ышанабыз. Сезгә сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телибез!

Фотолар ТР Предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясеннән алынды

Реклама

Альберт Шиһабетдинов,
«ТАИФ» ААЖ генераль директоры

Ихтирамга лаеклы игелекле эшләр

Хөрмәтле Наил Өлфәтович!

60 яшьлегегез уңаеннан ихлас котлауларыбызны һәм иң изге теләкләребезне кабул итегез!

Борынгы һиндларның бер зирәк гыйбарәсендә: «Башкалар рәхәте өчен елгалар ага, башкалар рәхәте өчен агачлар җимеш бирә, башкалар рәхәте өчен игелекле кешеләр яши», – диелә. Бу сүзләр, Наил Өлфәтович, турыдан-туры Сезгә кагыла, Сез бөтен гомерегезне җиңел булмаган, әмма җәмгыятькә бик тә кирәкле өлкә – нефть сәнәгатенә багышлагансыз, туган җиребез хакына, яраткан республикабыз хакына хезмәт итәсез. Югары җаваплылык хисе, искиткеч булдыклылык, максатчанлык һәм хезмәт сөючәнлек – бу сыйфатларның барысы да Сезгә үз профессиягезне вагы-төягенә кадәр тоярга ярдәм итә. Сез скважиналарны тикшерү буенча оператор хезмәтеннән башлап, Россиянең иң эре нефть компанияләренең берсе – «Татнефть» җитәкчесенә кадәр биниһая зур хезмәт юлы уздыгыз!

Югары дәрәҗәдәге профессионал, иң катлаулы хәлләрдә дә дөрес карарлар кабул итә белүче тәҗрибәле һәм зирәк җитәкче, мәгърифәткә, спортка, фәнгә, мәдәнияткә һәм сәламәтлек саклауга ярдәм итү өчен көчен һәм акчасын кызганмаучы меценат, вакыт чынбарлыгын тоя белүче актив һәм ихтыяр көченә ия шәхес һәм, ниһаять, туган җиребезнең чын патриоты – Сез Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең профессиональ җәмәгатьчелегендә зур абруйга һәм ихтирамга ия!

Сез, Наил Өлфәтович, һич арттыруларсыз, яңа биеклекләргә һәм максатларга омтыла белүче кеше. Минемчә, нәкъ шушы туктаусыз омтылышыгыз Сезгә һәрвакыт яшь, заманча рухлы һәм уңышлы булып калырга ярдәм итәдер. Сезне якыннан белүчеләрнең барысы да югары җаваплылыгыгызны һәм, барыннан да элек, үз-үзегезгә таләпчәнлегегезне югары бәяли. Мондый сыйфатлары җитәкчегә бурычларның күләмен һәм дәрәҗәсен дөрес бәяләргә ярдәм итә, җир асты байлыклары белән эшләүнең барлык катлаулылыклары турында нефтьчедән башка тагын кем белсен!

Предприятиенең бөтен тарихы дәвамында тупланган традицияләрне саклаган хәлдә, Сез «Татнефть» ГАҖ ышанычлы, динамик үстерү курсын дәвам итәсез, һәм компания бүген заманча, халыкара танылган күпфункцияле холдинг үрнәге – Татарстан Республикасының нефть сәнәгате флагманы булып тора. Бүген «Татнефть» ГАҖ һәм Сез, бу компаниянең генераль директоры буларак, күп игелекле эшләрнең чагылышына әверелдегез: «Татнефть» ГАҖ ярдәме белән республика бистәләре һәм шәһәрләренең йөзе үзгәрә, кече һәм урта бизнес үсә, районнарда мәктәпләр һәм балалар бакчалары, стадионнар һәм мәдәният йортлары калкып чыга, ахыр чиктә – Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең икътисады үсә. Наил Өлфәтович, әлеге игелекле эшләрегез өчен рәхмәт Сезгә!

Юбилеегыз көнендә Сезгә профессиональ компетентлыгыгыз, актив тормыш позициягез, «Татнефть» ГАҖнең динамик үсеше, Татарстан һәм Россия икътисадының алга китеше һәм чәчәк атуы, илебез халкының тормышын яхшырту хакына искиткеч зур көч куйганыгыз өчен тагын бер кат рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез!

«Татнефть» ГАҖ һәм «ТАИФ» Компанияләр төркемен озак еллар дәвамында партнёрлык мөнәсәбәтләре бәйләп торуы да бик күңелле, һәм мин ышанам, киләчәктә дә әлеге бәйләнешләр яраткан Татарстаныбыз хакына, Россия хакына ныгый һәм үсә барыр.

Наил Өлфәтович, Сезгә чын күңелдән бәхет һәм иминлек, ныклы сәламәтлек һәм актив озын гомер, һәр нәрсәгә позитив караш, яңа иҗади уңышлар өчен бетмәс-төкәнмәс энергия һәм барлык игелекле эшләрегездә һәм башлангычларыгызда уңышлар телим!

Үзегезгә һәм якыннарыгызга – тынычлык, игелек һәм муллык насыйп булсын!

Реклама Фото «ТАИФ» ААЖ матбугат хезмәтеннән алынды.

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ генераль директоры

Яңа планнар һәм бурычлыр

Хөрмәтле Наил Өлфәтович! «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ коллективы исеменнән Сезне 60 яшегез белән котлыйм. Бүген «Татнефть» – иң эре нефть табу үзәкләренең берсе, алдынгы тәҗрибә мәктәбе, нефть-газ тармагы өчен генә түгел, бөтен ил өчен югары квалификацияле кадрлар әзерләү урыны. Шунысы мөһим: бүген компания коллективы, үткәннәрдәге традицияләрне саклап, киләчәк өчен эшли. Җитештерүнең заманча технологияләре, хезмәтне оештыру ысуллары һәм стратегияләре уңышлы үстерелә һәм гамәлгә кертелә, социаль өлкә мәсьәләләре хәл ителә. Болар барысы бергә ил икътисадын нефть-газ ресурслары һәм эшкәртүдән алынган продуктлар белән тәэмин итүдәге катлаулы мәсьәләләрне уңышлы хәл итәргә мөмкинлек тудыра һәм республикабыз, аның халкы өчен югары икътисадый нәтиҗәлелеккә ирешә. Монда, һичшиксез, Сезнең дә аерым хезмәт өлешегез бар. Сез стандартларга иярмичә эшлисез, туктаусыз туып торган әһәмиятле тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен һәм проблемаларын хәл иткәндә, конструктив һәм уйланылган проектларга юл ярып, яңа юллар һәм элемтәләр эзли беләсез. Бу, әлбәттә, безнең компанияләрнең партнёрлык мөнәсәбәтләренә дә кагыла. «Татнефть»не һәм «Түбән Кама Нефтехим»ны күпьеллык хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре бәйләп тора, һәм без аның киләчәктә дә нәтиҗәле дәвам итәчәгенә шикләнмибез.

Сез җитәкчелек иткән компания Россия ягулык-энергетика комплексында әйдәп баручыларның берсе. Һәм ул киләчәктә дә шушы позицияләрен саклап калыр, дип ышанабыз.

Һәр яшәгән көнегезнең кызыклы вакыйгалар белән тулып торуын телибез! Яңа кыю планнар һәм бурычларны уңышлы хәл итегез! Сезгә һәм Сезнең зур нефть гаиләсенә сәламәтлек, бәхет һәм иминлек юлдаш булсын!

Реклама Фото «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ матбугат хезмәтеннән алынды.

Сайланган эшкә хезмәт итү

Танылган һәм абруйлы топ-менеджер, сәясәтче, җәмәгать эшлеклесе, галим, меценат – бу исемлекне тагын да дәвам итеп булыр иде. Әмма аны бүген тагын бер статус тулыландырды – ул юбиляр булды. Һәм мин «Аммоний» акционерлык җәмгыяте коллективы һәм үз исемемнән әлеге уңайдан Сезне ихлас котлыйм, Наил Өлфәтович!

Максатчанлык, даими профессиональ үсешкә омтылу һәм принципиальлек кебек шәхси сыйфатларыгыз Сезгә нефть табу операторыннан башлап, илдәге иң эре нефть компанияләренең берсе – «Татнефть» ГАҖнең генераль директоры дәрәҗәсенә кадәр юл үтәргә ярдәм иткән. Татарстанда Сезне компаниянең барлык стратегик мәсьәләләрен дөрес хәл итә белүче талантлы җитәкче һәм лидер буларак беләләр.

Сезнең тормыш юлыгыз – бер тапкыр сайланган эшегезгә фидакарь хезмәт итүнең ачык үрнәге. Татарстанда Сезгә булган хөрмәт – күркәм сыйфатларыгыз: эшлеклелек, әхлаклылык һәм Сез җитәкчелек иткән компаниянең барлык республика халкы өчен көн саен кылган игелекле эшләренең нәтиҗәсе.

Бу юбилей – ихлас хөрмәтебезне белдерү өчен өстәмә мөмкинлек бирүче күңелле бер сәбәп.

Без Сезгә туктаусыз алга баруыгызны, изге ниятләрегезне уңышлы тормышка ашыруыгызны телибез. Сез кыла торган игелек үзегезгә дә рәхмәт булып әйләнеп кайтсын. Сәламәт, бәхетле һәм уңыш юлдаш булсын!

Тимур Алиев, «Аммоний» АҖ генераль директоры

Фото «Аммоний» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды.
Реклама

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ КАЙЛАРДА САТЫЛА

КАЗАН

«МИР ПРЕССЫ – РЕГИОН» ҖЧҖ

«ДЕЙЛИ» КИБЕТЛӘРЕ

К. Маркс ур., 59
Н. Ершов ур., 78
Зорге ур., 93
«Тукай мәйданы» метро станциясе
Н. Ершов ур., 1 а («Корстон»)
«Горки» метро станциясе
Белинский ур., 4
«Җиңү проспекты» метро станциясе
Чуйков ур., 69
Парк ур., 6
Короленко ур., 81
Фрунзе ур., 5
Мусин ур., 68 б
Лаврентьев ур., 9
Даурия ур., 40

«ТАТАР КИТАП НӘШРИЯТЫ» ТР ДУП

Декабристлар ур., 2
Бауман ур., 19
Бауман ур., 29/11

«ГОРПЕЧАТЬ» ЯАҖ

Фрунзе ур., 7
Пушкин ур., 2
Сахаров ур., 13
Межлаук ур., 15
Ямашев пр., 49
Вишневский ур., 2
Н. Назарбаев ур., 47
Н. Назарбаев ур., 63
Восстание ур., 83
Кави Нәҗми ур., 7
К. Цеткин ур., 17/20
Восстание, 23 / Декабристлар ур.
Копылов ур., 5/1
Адоратский ур., 29
Максимов ур., 34/24
Липатов ур., 5
Достоевский ур., 74 а
Себер тракты, 7
Декабристлар ур., 189
Татарстан ур., 72
Даурия ур., 36
Даурия ур., 23
Автовокзал
«Казан Оргсинтез»
Горький шоссесы / Можайский ур.
Н. Ершов ур., 53
Кошевой ур., 16
Декабристлар ур.,178 а
Восстание ур., 56
Айдаров ур., 8 а
Окольная ур., 23
Себер тракты, 34
Декабристлар ур., 102
Челюскин ур., 31
Краснококшайская ур., 164
Максимов ур., 4
Ш. Усманов ур., 12
Гвардейская ур., 42
Батыршин, 16 / Коләхмәтов ур.
Революция ур.
Ильич ур., 30
Попов ур., 7
Беломорская ур., 73
Газовая ур., 9
Декабристлар ур., 115
Н. Назарбаев ур., 35
Черноморская ур., 3
Восстание ур., 6
Калинин ур., 73
Мәүлетов ур., 17
Гагарин ур., 22
Гагарин ур., 12
Халитов ур., 34 ж
Белинский ур., 9
Фучик ур., 72
Тынычлык ур., 33
Карбышев ур., 13
«Океан»
Чуйков ур., 38
Н. Ершов ур., 32
Гвардейская ур., 38
Чехов ур., 6
Халезов ур., 21
(Дәрвишләр бистәсе)
Короленко ур., 89
Декабристлар ур., 150

«ТАТАРСТАН ПОЧТАСЫ» ФПЭИ ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕ

Сахаров ур., 27
Мәүлетов ур., 9
Забайкальская ур., 3
Маршал ур., 25
Һ. Такташ ур., 75
Мехчылар ур., 3
Бауман ур., 37
Меридиан ур., 14
Әмирхан пр., 10 а
Максимов ур., 2
Салмач, Тынычлык ур., 6 а
Адоратский ур., 29 а
Адоратский ур., 12
Мусин ур., 68
Гаврилов ур., 40
Җиңү пр., 17
Ю. Фучик ур., 34
Кремль
Нокса авышлыгы, 1
К. Маркс ур., 44
Яңа аэропорт
Татарстан ур., 11
К. Цеткин ур., 33
Фрунзе ур., 1
Айдаров ур., 22
Декабристлар ур., 191
Юбилей ур., 1/43
Вишневский ур., 14
Волгоград ур., 22
Шатура ур., 155
Качалов ур., 95
«Оргсинтез» заводы
Беломорская ур., 1
Карьер, Нокса ур., 29
Мирный, Яңа Дәүләкәй ур., 16 а
Нагорный, Круговая ур., 12
Павлюхин ур., 116
Рәхимов ур., 33
Ирек мәйданы, 1
Черноморская ур., 3
Петровск, Үзәк ур., 1
Тынычлык ур., 45
Гвардейская ур., 42
Яңа Юдино ур.,140
Красиков ур., 8
Завокзальная ур., 57
Альберт Камалиев ур., 12
Беломорская ур., 73
Зур Урам, 11
Я. Гашек ур., 1
Дәрвишләр бистәсе,
Краевая ур., 8 а
Товарищеская ур., 28/70
Б. Заречная ур., 22
Кадыш, Калинин ур., 1
Кремль
Оренбург тракты

Реклама 16+

Ринат Закиров, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе, августта үзенең 70 яшьлеген билгеләп үтә

Республикабызга һәм татар халкына фидакарь хезмәт итүче

Васил Шәйхразыев, ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шурасы рәисе

Хөрмәтле Ринат Зиннур улы!

Сезнең 70 яшьлек юбилеегыз – ул Татарстан һәм татар халкы тормышында мөһим вакыйга. Гап-гади авыл гаиләсендә хезмәт сөючән булып чыныгып үсеп, инженер-химик һөнәрен алганнан соң, Сез бөтен гомерегезне идарә итүгә, мәдәниятккә һәм кеше тәрбияләүгә багышладыгыз. Үзегез сайлаган барлык юнәлешләрдә дә иң югары үрләргә күтәрелдегез.

Сезнең яшь буынны тәрбияләүдә, педагогика буенча кандидатлык диссертациясен яклауда, иҗат берлекләре, мәдәният, сәнгать хезмәткәрләре, эшкуарлар белән эшләүдә, яңа оешмалар үстерүдә туплаган тәҗрибәгез «Казан» милли-мәдәни үзәген оештыру, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетын җитәкләү елларында тулысынча ачылды. Сез, татар халкы тарихын өйрәнеп, милли җәмгыятьләрнең эшен куәтләдегез. Бөтендөнья татар конгрессы каршында оештырылган авыл эшкуарларын, татар яшьләрен, туган якны өйрәнүчеләрне, татар хатын-кызларын берләштерүче җәмгыятьләр эшчәнлегенә көч бирдегез. Дин әһелләре белән милли җәмәгатьчелекнең хезмәттәшлеген җайга салдыгыз, эстрада, музыка, хореография коллективларын үстердегез. Бу гамәлләрдә Сез үзегезнең милләт юлында фидакарьлек һәм дәрт белән эшли алуыгызны исбатладыгыз һәм исбатлап киләсез.

70 яшьлек юбилей көннәрегездә Сез Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә яшәүче татар җәмгыятьләренә ярдәм итүегез һәм аларны туплавыгыз белән горурлана аласыз. Россия Федерациясенең һәм чит илләрнең дистәләрчә дәүләтләрендә Татарстан Республикасы һәм Татар конгрессы ярдәмендә мәдәниятне, мәгърифәтне үстерү, кадрлар әзерләү, яшь буынның милли үзаңын, милләттәшләрнең хакимият һәм икътисад вәкилләре арасында багланышларын ныгыту кебек мәсьәләләрне хәл иттегез.

Катлаулы һәм җаваплы урыннарда озак еллар дәвамында эшләп, Сез һәрвакыт максатчан хәрәкәт иттегез, халкыбызга ярдәм итү өчен барлык көчегезне һәм тәҗрибәгезне кулландыгыз.

Хөрмәтле Ринат Зиннур улы, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы, коллективы һәм үз исемемнән Сезне 70 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм! Корычтай нык сәламәтлек һәм тормышыгызда бәхет-шатлык телим!

Фото Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасыннан алынды.

Фәхретдин Канюкаев,
«Дуслык» Самара төбәк иҗтимагый иҗат оешмасы президенты

Фотолар «Дуслык» Самара төбәк иҗтимагый иҗат оешмасыннан алынды.

Бабаларыбыз мирасын саклап

Хөрмәтле Ринат Зиннур улы!

Күркәм бәйрәмегез – 70 яшьлек юбилеегыз уңаеннан иң изге теләкләребезне кабул итегез. Татар халкы кайларда гына яшәсә дә, аларны һәрвакыт рухи мәркәзебез Казан һәм Бөтендөнья татар конгрессы берләштереп торды һәм киләчәктә дә берләштереп торачагына шигем юк.

Милләтебезгә кагылышлы төрле катлаулы хәлләр, мәсьәләләр туып кына тора. Ләкин сезнең зирәк акылыгыз, күпьеллык тәҗрибәгез барлык авырлыкларны җиңеп чыгып, әби-бабаларыбыз тоткан кыйблага хыянәт итмичә, туры юлдан тайпылмыйча, һәрчак алга хәрәкәт итәргә ярдәм итә.

Сезнең җитәкчелек астында Казанда ел әйләнәсендә иң алдынгы татар эшмәкәрләре, дин әһелләре, хатын-кызлар, төбәк тарихын өйрәнүчеләр, татар яшьләре һәм милләтебезнең башка бик күп асыл ул-кызлары җыела, алар Татарстанда туплаган тәҗрибәне төбәкләргә алып кайтып, үз белемнәре белән бүлешә, милләтебезнең якты киләчәге өчен тырыша. Федераль Сабантуй, Европа Сабантуе, Бөтенроссия авыллары Сабантуе, Ык буе авыллары Сабантуе, «Татар кызы» бәйгесе һәм башка бик күп төрле мәдәни һәм фәнни җыеннарыбызның чишмә башында Сез торасыз. Әлеге чараларның һәрберсенең хакимият һәм халкыбыз тарафыннан хуплап кабул ителүе сезнең булдыклы һәм үз эшегезгә бирелгән зат икәнлегегезне раслый. Милләтебез өчен көч куюыгызны, тырышлыгыгызны күрсәтә.

Хөрмәтле Ринат Зиннурович, Сез безнең күбебез өчен үрнәк булып торасыз. Татар халкында «хезмәтенә күрә – хөрмәте» диләр. Башкарган эшләрегез сезгә карата хөрмәтне иң югары дәрәҗәгә җиткерде. Гомер бәйрәмегез белән тәбрик итеп, Сезнең киләчәктә дә армый-талмый милләтебез яшәеше өчен сау-сәламәт булып хезмәт итүегезне телибез, тигезлектә һәм муллыкта яшәргә насыйп булсын.

БАРҖЫНЫ СЫЕНДЫРГАН **КИЧКЕТАҢ**

Ерак юлга кузгалдык – Әгерҗе районына. Һәм... әкияти бер почмакка юлыктык. Монда аюлар умарта ояларын урманга алып йөгерә, ә аяк астыңа карап атламасаң, кара елан чагарга мөмкин икән. Серле, шомлы, фаҗигале тарихлы Кичкетаңда тагын әллә ниләр күрдек.

Автор:
Руфия Фазылова

БАРҖЫНЫ САГЫНУ...

Кичкетаң – Әгерҗе районының иң зур авылларының берсе. Казаннан килгәндә юл өстендә кала ул. Аннан соң Әгерҗе шәһәренә тагын 60 чакрым барырга кирәк әле. Кичкетаңда бүген 462 кеше яши, 362 хуҗалык бар. Бер ун еллап элек халык саны тагын да күбрәк булган. Ә 1970 нче елларга кадәр Кичкетаңда ике йөзләп кенә хуҗалык саналган. Бер ай дигәндә авылда йөзләгән йорт калкып чыккан. Авылның космик тизлек белән артуы сәбәбен Кичкетаң авылы җирлеге башлыгы Зөлфәт Нуриев аңлатты:

– 1970 нче елларда Түбән Кама сусаклагычы төзелгәч, бу җирлектәге кайбер авыллар су басу зонасына эләкте. Минем туган авылым – Барҗы да шундый бәхетсез язмышка дучар ителде. 1970 елда Барҗыдагы барлык йортларны сүтеп, Кичкетаңга күчердек, хәтта зиратны да...

Зөлфәт абыйның тормыштагы иң зур фаҗигасе ата-бабаларының каберен казып яңа урынга күчерү була. Хәер, аның өчен генә дә түгел. Авылның йөзләгән кешесе үзенең якын туганнарының сөякләрен җыеп, яңа урынга илтеп җирли.

– Ул вакытта биредә ниләр булганын күз алдыгызга да китерә алмыйсыз, – дип сүзен дәвам итте авыл җирлеге башлыгы. – Картлар яшәгән йортларын сүттермәс өчен теше-тырнагы белән каршы килде, үкереп еладылар, тиргәделәр. Күбесен өйләреннән үгетләп, ялварып дигәндәй чыгардылар. Һич күз алдыннан китми: гомер иткән нигезләрен ташлап киткәндә, халык йортларының бүрәнәләрен кочаклап елады. Ахырзаман алды кебек булды...

Ул чакта яңа йорт салырга дәүләт һәр гаиләгә акча бирә. Яшьрәкләр, Кичкетаңда яшиселәре килмичә, Әгерҗегә, башка авылларга китеп йорт сала. Шулай да Барҗының күпчелек кешесе Кичкетаңга килеп төпләнә.

– Адәм баласы ияләнә икән, – ди Зөлфәт Нуриев. – Әлбәттә, туган авыл һаман да төшләргә керә. Тик Кичкетаң да якын инде. Урыны әйбәт, юл өстендә. Су белән проблема булмады, тиз арада газ керде, туфрагы уңдырышлы. Юллар салынды, урта мәктәп, мәдәният йорты эшли. Берничә кибет бар. Ә табигате... Бездәге кебек матурлык Татарстанда бүтән юк.

НӘСЕЛЛЕ УМАРТАЧЫЛАР

Керпе дә баласына «йомшагым» дигән. Авыл җирлеге башлыгының: «Бездәге кебек матурлык юк», – дип әйтүен шулайрак кабул иткән идем. Бактың исә, Зөлфәт абый арттырмаган: биредә искиткеч гүзәллек. Чит ил кешеләре дә: «Соң бу бит Швейцариянең бер почмагы!» – дип сокланып киткән, имеш.

Кичкетаң авылы башыннан аз гына читтә атаклы умартачылар ихатасы бар. Аталы-уллы Иван һәм Володя Гончаровлар шәхси эшмәкәр булып теркәлгән.

Биш гектар җирне махсус умартачылык өчен рәсмиләштергәннәр. Якынча өч йөз баш умарталары бар. Гончаровлар җитештергән балны Әгерҗедә генә түгел, Мәскәү, Санкт-Петербург кебек зур шәһәрләрдә дә беләләр.

Иван дәдәй безне табын корып каршы алды. Ачык күңелле, рәхәт кеше. Милләте буенча удмурт булуына карамастан, татарчаны да яхшы белә.

Фото: Александр Ефремов

2

1

– Гомер буе татарлар арасында яшәп, ничек татарча белмисең, – дип куйды.

Гончаровларның умарталыклары әкият бакчасын хәтерләтә: йорт, мунча, зур гына веранда һәм шунда ук йөз баш умарта оясы тезелеп киткән. Сул якта – күл, анда аккошлар, кыр үрдәкләре йөзә, көймә дә бәйләп куелган. Ә мондагы хуш исне берничек тә язып аңлатып булмый: бал белән чәчкә, үлән, тагын әллә ниләр бергә кушылган исерткеч тә, ләззәтле дә бер хуш ис ул. Ә мондагы матурлык... Менә шундый вакытларда журналның телевидение кебек мөмкинлекләре югына үкенеп куясың...

– Мондый җирдә эшләү ардырмыйдыр? – дим Иван дәдәйгә.

– Бал кортлары болай да кешегә көч бирә, – ди умартачы. – Әйтмәгәнем булсын, аруның, авыруның ни икәнен дә белмибез.

Гончаровлар кортларның «Среднерусская» төренә өстенлек бирә. Безнең климат өчен яхшы икән үзләре.

– Хәзер читтән кайтарылган кортлар да күп, тик алар усал, кышны да авыр чыгалар, – диде умартачы.

Иван дәдәй үзен белгәннән бирле кортлар янында. Кортларга бер күз төшерүгә барысын да аңлап ала: бал җыяларммы, яшь ана аерылып чыгарга җыенамы, чирләмиләрме һ.б. Алма алмагачыннан ерак китмәгән – Володя да әтисе юлыннан юнәлгән. Хәер, егетнең хәтта әтисен уздырып ятуы икән: кортчылык буенча яңа алымнар өйрәнә, аларны тәҗрибәдә куллана.

– Ижевск авыл хуҗалыгы академиясенең умартачылык факультетын тәмамладым, – диде Володя. – Әти кортларны караса, минем өстә бал сату, базарны өйрәнү. 300 баш умартаның балын урнаштыру бик җиңел түгел. Инде эш җайланды, дисәм дә була, үзебезнең даими сатып алучыларыбыз бар, күпләп озатабыз.

Володя пенопласттан бал кортларына яңа төрле оя ясый башлаган. Ул бик җайлы, җиңел икән. Кортлар яңа ояны тиз үз иткән. Агач ояга караганда, төрле авыруларга каршы да яхшы икән.

– Умартачылык та бер урында гына тормый, заманча эшләргә өйрәнергә кирәк, – диде яшь белгеч.

Володя узган ел гаилә корган. Әти-әнисе белән бер түбә астында матур гына яшәп яталар. Туры килүен кара: яшь килен дә умартачылар нәселеннән. Кортларны ирле-хатынлы бергә карыйлар икән. Гончаровларның планнары зурдан. Балны махсус савытларга тутырып сатуга чыгарудан башлап, туристлар өчен махсус комплекс булдыруга кадәр.

– Күпләп сатканда балның өч килосын 1 мең сумнан алалар, – диде Володя. – Ә базарда ул мең ярым тора. Әлбәттә, без дә килолап сата алабыз. Тик ул вакытны күп ала. Димәк, безнең өчен иң отышлысы – күпләп сату. Һәрхәлдә – әлегә. Якын шәһәрләр белән элемтә булдырып, балны савытларга тутырып сатасы иде. Алай отышлырак булачак. Ә ял итү үзегенә килгәндә, күреп торасыз: биредә табигать искиткеч. Балык тотам дисәң, суы бар, гөмбә җыям дисәң – урманы. Мунча кереп, яңа аертылган бал белән чәй эчеп, шашлык кыздырып, су коенып ял итүне оештырырга бөтен мөмкинлекләр бар. Зур булма-

3

1. Атаклы умартачылар – аталы-уллы Иван һәм Володя Гончаровлар шәхси эшмәкәр булып теркәлгән.

2,3. Йөз баш умарта оясы тезелеп киткән. Сул якта – күл, анда аккошлар, кыр үрдәкләре йөзә, көймә дә бәйләп куелган.

Кичкетаңда әдәбиятка гашыйк, табигатьне яратучы әниле-кызлы Рәйсә апа Зарипова һәм Рәмзия Җиһангәрәева белән таныштык.

ган күркәм йортлар салырга гына кирәк. Монысы инде – киләчәк эше, Алла боерса!

Гончаровлар кызык хәл дә сөйләде: баксаң, алар хуҗалыгында аю – еш кунак икән. Әгерже тайга урманнары белән чиктәш, шуңа кышын йоклаучы дүрт аяклы җанварлар шактый еш очрый. Аю умарта оясын күтәреп ала да урманга чаба, мәсәлән. Аннан умартачылар буш ояны барып алалар. Дүрт аяклы «дошман», ояны ачып, кәрәзләрен җиргә алып аткан һәм балын ашаган була икән. Тик умартачылар моңа үпкәләми: «Бал барыбызга да җитә», – дип елмаештылар.

Умартачылар ихатасында тагын бер куркыныч җан иясе бар – кара елан. Дөрес, без аны күрмәдек. Ләкин хуҗалар кара елан белән көн саен диярлек очраша икән.

– Өстенә басмасаң, тими ул, куак астында тыныч кына йоклап ята. Аяк астыңа карап йөрергә генә кирәк, – диделәр.

«БЕЗ – ХЫЯЛЫЙЛАР...»

Кичкетаңда әдәбиятка гашыйк, табигатьне яратучы әниле-кызлы Рәйсә апа Зарипова һәм Рәмзия Җиһангәрәева белән таныштык. Рәмзия апа җирле шагыйрә икән – өч китабы дөнья күргән. Шигырьләр янында берничә хикәясе дә бар. Аның иҗат җимешләре «Әгерже хәбәрләре» район газетасында еш басыла, әйтүләренә караганда.

Барҗы җыры

Туган туфрак тарта, диләр,
Туган нигезләр – изге.
Иж суының чал дулкыны
Аерды, авыл, безне.

Ятим калган авылымда
Җиргә ятып җил елый.
Буш нигезләрне тигезләп,
Кар ява, буран улый.

Иж дулкыны ярга түгел,
Бәгырьгә кага икән.
Бәхетле яшьлек еллары,
Гел истә кала икән.

Барҗы диеп йөрәк әрни,
Сагыну сагышы микән?
Читтә узган гомерләрнең
Узып барышы микән?..

Рәмзия Җиһангәрәева

– Безнең гаиләдә матур традиция бар – туган көннәргә, бәйрәмнәргә бер-беребезгә шигырь бүләк итәбез. Үзебез чыгарып. Моннан да кадерле бүләк була алмый, минемчә. Мин, мәсәлән, үземне белгәннән бирле туганнарга шулай шигырь чыгарам. Әлеге матур гадәт әнидән күчте. Ул хыялый безнең. Хәер, мин әле аны да арттырдым бугай: җаен еш кына урманга барып, кошлар сайраганын тыңларга яратам, агачлар белән «сөйләшеп» кайтам...

Без барган көнне дә Рәмзия апа урманнан кайткан иде – каен җиләге җыйган. Үзе әйткәнчә, илһам шулай килә икән.

Миңа гади авыл кешесенең үз акчасына китап чыгаруы кызык тоелды. Ни дисәң дә, лаеклы ялга чыккач, өч китап бастыру – шактый мәшәкатьле эш.

– Күпләр шулай гаҗәпләнә, – диде Рәмзия апа. – Беренчедән, китапларның тиражы зур түгел, йөзләп кенә. Шуңа да әллә ни зур акчалар китми. Шигырь, хикәяләремне туплап, китап итеп бастыру – якыннарымның теләк-тәкъдиме иде. Матди ярдәмне дә алар күрсәтте. Әнием дә булышты. Ә иң сөендергәне – аның укучылары бар. «Туган авыл сагышы» китабын читтә яшәүче авылдашларым өйгә килеп-килеп сорый. «Синең китап Барҗыны сагынуыбызны баса», – диләр.

Ул китабын Рәмзия апа безгә дә бүләк итте. Авторның шигырьләрендә туган якка мәхәббәт, гомер, тормыш фәлсәфәсе турында уйланулар ята. Ә төп игътибар – Барҗы авылына. Рәмзия апа өчен Кичкетаң туган авылы түгел, аның балачагы Барҗыда калган.

– Ел саен язны көтеп алам, – диде җирле шагыйрә. – Карлар эрегәч, бер төркем авылдашлар белән Барҗы җиренә барабыз. Һәркем үзенең нигезенә утырып дога кыла. Су басарга тиеш булса да, туган авылыбызга кадәр су килмәде. Әти-әниләр утырткан алмагачлар ел саен шау чәчәккә күмелә. Шуның хуш исенә исереп, күзләр шешенгәнче елап кайтабыз. Туган нигезен сагынып, авылдашлар әллә кайлардан килә.

Гаҗәп бу адәм баласы: Кичкетаңда гаилә корып, балалар үстерсә дә, Рәмзия апа һаман туган авылы – Барҗысын сагына, аңа мәдхия кыла. Хәер, ул гына түгел, йөзләгән авылдашлары кендек каны тамган нигезен сагына.

«АТ ТА ЮК КҮРГӘЗМӘГӘ!»

Рәмзия апа белән әнисе Рәйсә апа Зарипова янына юнәлдек. Туксан ике яшен тутырган әби ялгызы яши икән.

– Әнинең безнең янга киләсе килми, – диде Рәмзия апа. – Югыйсә энем дә, улым да гаиләсе белән Кичкетаңда яши. Өлкән яшьтә булса да әни үзен-үзе йөртә әле, Аллага шөкер.

Рәйсә апа, чынлап та, картлыкка бирешмәгән. Кергәндә үк үзе утырткан биш төп кыяр, помидор, бер буразна бәрәңгесе белән «мактанып» алды. Ишек алдында ук чәчәкләр шаулап утыра.

– Барысын да үзең утырттыңмы? – дим әбигә.

– Үзем. Балалардан бер кыяр, ике помидор сорап йөреп булмый бит, – дип куйды.

– Без аны сорамаса да китерәбез дә, юк, үзенең бакчада кайнашасы килә, – диде Рәмзия апа.

Рәйсә апа өч бала – бер кыз, ике ул үстергән. Ун ел элек улы, килене, оныгы машина белән суга төшеп фаҗигале төстә вафат булганнар.

– Ике балалары калды, алар өчен үзәк өзелүләрне белсәң, сеңлем,- дип Рәйсә апа кайгылы истәлекләре белән уртаклашты. – Рәхмәт яусын, ул балаларга барысы да ярдәм итте. Оныкчыгым, югары белем алып, кияүгә чыкты. Тормышлары матур, Аллага шөкер. Ә оник Мәскәүдә, бишенче курста укый әле. Бик башлы егет, «5»кә генә укыды.



Рәйсә апа, чынлап та, картлыкка бирешмәгән. Кергәндә үк үзе утырткан биш төп кыяр, помидор, бер буразна бәрәңгесе белән «мактанып» алды. Ишек алдында ук чәчәкләр шаулап утыра.

50 елдан артык педагогик стажы булган Зәки Шәех улы Фәррахов, туган авылы турында «Кичкетаңым – гүзәл ягым» исемле китап нәшер иткән. Анда мондый юллар бар:

«Иван Грозный Казан ханлыгын басып алганнан соң, халык, чукындырудан качып, төньяк-көнчыгышка – Малмыж, Вятка буйларына, Кукмара тирәләренә һәм көньяк-көнбатышка – Уфа далаларына качарга мәҗбүр була. Кичкутан тирәсенә килеп урнашкан татарлар Казан тирәсеннән Вятка елгасы буена, Кукмара тирәсеннән бу якларга килеп чыккан татарлар булырга тиешләр. Авыл бөтен яктан кара урман (чыршы, нарат агачлары) белән әйләндереп алынган була. Халык, су булмагач, өскә таба – Изге Чишмә тирәсенә күтәрелә. Ә ул җирдә удмурт кабиләләре яши. Алар аучылык белән шөгыльләнә, бигрәк тә кыр кәҗәләре күп булган, диләр. Татарлар килеп урнашкач, удмуртлар, авылдан 15 километр ераклыктагы Ләле авылына күчеп китә (хәзер Удмурт Республикасы, Алнаш районы). Татарлар, удмуртлардан калган авыл атамасы – Кәч-котум («кәҗәне тот») исемен Кичкутанга алыштыра. Тик авылның исеме 1970 нче елларда янә үзгәртелә: Кичкутаннан Кичкетаңга әйләнә. Яңа исем татарчарак та, матуррак та тоела.

Тагын шунысы да кызык, Кичкетаңнан ерак булмаган удмурт авылы кешеләре, нигездә картлар, авылны иске исемдә – Кәчкотум дип йөртә».

Рәйсә апаның 10 оныгы бар, шуның берсе генә кыз. Һәм барысы да «5» билгеләренә генә белем алган икән. Әби бу турыда бик тәмләп, горурланып сөйләде.

– Хәзерге балаларга бөтен мөмкинлекләр дә бар, күз тимәсен, – диде Рәйсә апа. – Безнең балачак авыр булды. Әти, биш баласын калдырып, 1937 елны тиф авыруыннан үлеп китте. Безне аякка бастырыр өчен әни барысын да эшләде. Урыны оҗмахта булсын!

Рәйсә апаның да шигырьләр китабы бар. 90 яшьлек юбилеена оныклары бастырган. Әле бүген дә шигырьләр, мөнәҗәтләр иҗат итә. Шуларның кайберләрен безгә дә укып күрсәтте.

– 30 июньдә Баржы авылында таш кую мәҗлесе була, – диде Рәйсә апа. – Авыл инде үзе булмаса да, аннан кеше өзелми. Бездән соң килгән буыннар, Баржы дигән авыл булганын белсеннәр, дип, әти-әнисе шул авылда үскән бер егет таш эшләткән. Шул вакыйга уңаеннан шигырь чыгардым, мәҗлестә укырмын дип торам.

– Ә Кичкетаң? – дим әбигә. – Аңа багышлап шигырьләр язасызмы соң? Кайсын карама, бөтен кеше Баржы, ди...

– Әлбәттә, Кичкетаңга багышлап язган шигырем дә бар. Инде кырык елдан артык бирегә яшибез, авылны бик яратам. Кичкетаңда бәхетле яшәдек без, муллык белән. 1964 елга кадәр колхозда хезмәт көне тулсын, дип, бушка дигәндәй эшләдек. Аннан соң гына кешегә эшләгәне өчен түли башладылар. Монда күчеп килгән вакыт – 1970–1980нче еллар иң рәхәт вакыт.

Хәер, әби бүгенге тормышыннан да зарланмый. «Бөтен нәрсә бар, кранны ачасың, су, газ килә», – ди. Гел хәер-догада ул. Тик әби авылларның бетеп баруына борчыла:

– Авылда күргәзмәгә генә булса да атлар юк. Фермалар да бетте. Хәзер хуҗалыкта да техника – мотоблоклар эшли. Коръәндә әйтелгән: «Ахырзаман алдыннан кеше бөтен нәрсәне тимердән эшләтер», – дигән. Менә шуңа бара дөнья, күрмибез генә...

...Кичкетаңда бик озак булдык. Ерак юлга чыгасы бар, дип, китәргә ашыгабыз, ә карар әйберләр, үзенчәлекле кешеләр күп. Тырыш гаиләләр дә җитәрлек. Һәр йортта диярлек мал асрыйлар һәм берне генә дә түгел. Сыер асраучылар буенча Кичкетаң авылы Әгерҗе районында беренчеләр рәтендә икән. Үз эшләрен башлаган кешеләр дә шактый. Шәхси пекарня ачкан Татьяна Бакланова белән таныштык. Көненә 60 ипи, күмәч, өчпочмак, төрле бәлешләр пешерәләр икән...

Кичкетаң башка авыллардан шул ягы белән аерыла – кырык ел элек биредә яңа тарих башланган. Һәм ул эре хәрефләр белән языла бара, якты төсләр белән өретелгән. Алга таба да шулай булыр, дип ышанайык.

АЙ КӘЕФЕ: БИЕКТАУЛАРЧА

16000нән артык кеше, шул исәптән «Татарстан» редакциясе дә, Биектау районында узган «Иске Казан түгәрәк уены» Республика фольклоры фестиваленең икенче гала-концертын тамаша кылды.

Автор:
Алия Хәйретдинова

БИЕКТАУЛАРЧА КУНАКЧЫЛЛЫК

Бәйрәм кунакларын төрле милләт вәкилләре табадан гына төшкән кайнар коймак, хуш исле үлән чәе, Биектауның иркен болыннарыннан җыелган каен җиләге, каз һәм рус мичендә пешкән кәбестә ашы белән каршы алдылар. Һәм, әлбәттә инде, җыр-бию белән дә. Бер сүз белән генә әйткәндә, күңелгә якын, таныш әйберләр, әмма алар заман шаукымы аркасында еш кына арткы планда онытылып кала.

– Әлеге фестиваль, саекмас чишмә кебек, безнең милли мәдәниятне туендырып тора, буыннар алмашын тәэмин итә. Республиканың көче, егәре муниципаль районнар ирешкән казанышлардан гыйбарәт бит. Республиканың гомуми уңышлары фонында Биектау районы да лаеклы урын били, – дип сәламләде кунакларны һәм авылдашларын Биектау районы башлыгы Рөстәм Кәлимуллин.



БИЕКТАУНЫҢ КИЛӘЧӘГЕ

Киләсе елга инде Биектау районы илкүләм «Түгәрәк уен»ның рәсми мәйданына әйләнәчәк. Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов сүзләренә караганда, фестиваль мондый югары бәяне оештыручылар һәм Биектау районы халкының тырышлыгы белән алган, чөнки аны «бурыч куйдың да хәл ителде» диеп кенә уздырмыйлар монда. Елмаюлар – ихлас, кунакчыллык – халыкның күңелендә. Уңыш сере менә нәрсәдә».

– Мәдәният, спорт һәм милли традицияләрнең уңай синтезы буларак, әлеге бәйрәмнең киләчәге якты булырга тиеш. Тарихыбызны сакларга кирәк. Ә мондый бәйрәмнәр күпмилләтле, әмма бердәм гаилә булып яшәүче Россияне тагын да бердәмрәк, көчлерәк итә! – дип бәяләде фестивальне Марат Әхмәтов.

Шушында ук һөнәр осталарын да бүләкләделәр. Авыл һәм кыр хезмәтчәннәренә – аерым игътибар. Авыл хезмәтчәннәре арасында «Битаман» хуҗалыгы механизаторы Әхәт Хәлиуллин һәм «Татарстан» агрофирмасының сыер савучысы Рәсимә Островская чемпион булды.

Фото: Алия Хәйретдинова

БИЕКТАУ ҖӘННӘТЕНДӘ

Тантаналы өлеш тәмамлануга, фольклор ансамбльләрнең чыгышлары башланып китте. «Ижар» мари коллективының күз явын алырлык костюмнары һәм дәртле чыгышы күпләрне биюгә дәртләндерде.

– Бизәкләр күбрәк булган саен матуррак. Костюм мари милләтен күрсәтә, аның байлыгы турында сөйли! – дип тәмләп сөйли биючеләр костюмнарының нинди мәгънәгә ия булуы турында.

– Кәеф шәп, эмоцияләр – уңай. Илебезнең күпмилләтле халкын бердәм, ныклы гаиләгә туплый торган бәйрәм булуына куанабыз, – дип шәрехләделәр Биектау районы Айбаш мәдәният йорты коллективына йөрүчеләр бәйрәмнең мәгънәсен. «Гөлҗамал» коллективы яшь әле, дүрт кенә ел эшли, әмма алар «Түгәрәк уен» фольклор фестиваленең финалисты булырга да өлгергәннәр инде. Алар өчен гала-концертта катнашу халык алдында имтихан тотуга тиң икән:

– Биектауның җәннәт почмагында кебек сизәбез үзебезне. Монда халык бик кунакчыл, бик җылы каршылыйлар. Күңел сөенә!

БИЕКТАУ КЕЛӘМЕНДӘ

Иң озак көттергән вакыйга– көрәш – үзәк мәйданда башланып китә. Татарстан районнарыннан килгән танылган көрәшчеләр Биектау келәмендә очраша. Татарстан спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов әйтүенә караганда, спортчылар гадел көрәш алып барырга сүз биргән.

– Алдан ук җыелып, көрәшчеләр белән гадел көрәшү турында сөйләштек. Алар безгә чын гадел көрәшне күрсәтергә вәгъдә дә итте.

Һәркем яратып карый торган көрәш, чыннан да, мавыктыргыч тамаша булды. Төп бүләк – автомобиль, аның өчен һәм батыр исемен яулау максаты белән Булат Мусин, Азат Нурмөхәммәтов һәм Раил Нургалиев көч сынашты. Биектау егете Раил Нургалиев җиңде.

– Көндәшләр көчле булып чыкты, – ди Раил. – Бөтен Татарстаннан иң көчле көрәшчеләр җыелган иде. Эссе һава торышына карамастан, барыбыз да лаеклы көрәште. Һәм мин абсолют батыр калдым!

Яңа автомобиль һәм алтын мөгезле тәкә җанатарларның алкышлары астында абсолют батырга тапшырылды. Башкача була да алмый иде!

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Безнең Инстаграмда –
«Татарстан»ның йөрәге!

Реклама 16+